ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№11 (406)
НОЯБРЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

КАЗАНЫБЫЗ УҢАЙЛЫ БУЛСЫН ӨЧЕН ТЫРЫШАБЫЗ!

4 612750 670011

№11 (406)
НОЯБРЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Фәнзилә Җәүһәрова,
Николай Крушинин, Мария Ермакова, Наилә Хәйретдинова,
Айдар Шәйхин
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова,
Айдар Мөшәрәпов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Марат Рәхимов,
«Казметрострой» АҖ генераль директоры.
Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-2339
Басарга кул куелды: 17.11.2025
Чыгу көне: 21.11.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ТАБИГЫЙ БУЛЫП КАЛУ БӘХЕТЕ

Матур йөзләр, идеаль фигуралар, күз явын алырлык табигать манзаралары, ягымлы, йомшак гына яткан күләгәләр, тылсымлы яктылык... Бу ялтыравык купшылыкка корылган тормыш сурәте безне бар яктан уратып алган, әйтерсең, озакламый үзенең тыгыз боҗрасына кысып, тынсыз ук итәчәк. Әмма бер кимчелеге булмаган, ясап куелган матурлык – ул чын матурлык түгел. Андый матурлыкны хәзер күз ачып йомганчы ясалма фәһем хәстәрләп бирә.

Күпләр, аны кулланып, табигый матурлыкларын «тәртипкә китерә», һәм менә аватаркалардан безгә ясалма гүзәлләр бага. Журнал тышлыклары белән телевизор экраннарыннан да – шулай. Без, күрәсең, аларның чын икәненә ышанырга тиеш...

Ясалма табигать кочагында ясалма йөзләр ясалма елмая, ә авызлары тулы – энҗе-мәрҗәндәй ясалма тешләр ялтырый... Вакыт-вакыт әле алар, ясалма рәвештә терелеп, инде күптән бакыйлыкка күчкән туган-тумачалары белән, ясалма куанышып, ясалма кочаклашырга да керешә...

Бу ясалмалык «эпидемия»се, спираль буенча әйләнеп, тарала да тарала, инде шәһәр-бистәләрне генә түгел, ә чынбарлык әле чын булып калгандай тоелган авылларны да биләп ала. Күңелсез, иптәшләр! Туйдырды. Бизәксез, купшы булмаган, табигый, чын үзебез сагындырды. Чын булганда, үзебезнең ни дәрәҗәдә кызыклырак, җанлырак, газизрәк, ниһаять, кешелеклерәк икәнебезне онытып барабыз түгелме?

«Татарстан»ны укыгыз – һәм чын бәхетнең бу ясалма тирәлектә үзегез булып калу икәненә янә бер мәртәбә инаныгыз.

Сезнең һәрвакыт табигый редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2026 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1998 сум 00 тиен китереп бирешле,
1939 сум 20 тиен соратып алганда.
2026 елга ТР буенча язылу бәясе:
3995 сум 90 тиен китереп бирешле,
3878 сум 29 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барысы тик ТАТАРСТАНДА



ШАНДОР ИСЕМЛЕ ТАУ

Шандор тавы. Татарстанның Шөгердәге бер тавы әнә шулай атала.
Аңа бу исемне биредә яшәп киткән Америка кешесе хөрмәтенә
биргәннәр. Ласло Шандор – АКШ тан килгән геолог, ул нефть сәнә-
гате белән шөгыльләнә. Безнең якларга 1877 елда килеп чыга. Кы-
зык өчен түгел, билгеле, ә кара алтын эзләп.
Сөйләүләре буенча, бу урыннарны арендага алыр өчен халыкны
бер елга җир салымыннан азат итәргә вәгъдә бирә. Авыл бәйрәмнә-
рендә әле тагын акчаны учлап-учлап кешеләр өстенә сибә торган
була... Америкадан килгән хәзинә эзләүче бу урыннарда биш сква-
жина бораулый, әмма кара алтынга кадәр барыбер төшеп җитми.
Шөгер тирәсендә зур нефть катламнары ятканлыгы ачыктан-ачык
үзен сиздереп торса да. Бу урыннарның алтын бәһасенә торганын
раслау йөзеннән, Ласло Шандор акционерлар җәмгыяте төзергә дә
омтылып карый – барып чыкмый.
Ахыр чиктә, ул тәмам бөлгенлеккә төшә һәм 1881 елда Шөгердән
китә. Дистә еллардан соң гына ачыклана: Шандор нефть ятма-
ларыннан берничә адым ераклыкта гына тукталып кала һәм бу
проектка аптыраганнан кул селтәгән булып чыга. Аның иң тирән
скважинасы нефтькә кадәр нибары ике йөз метр ярым тирәнлеккә
төшеп җитә алмый кала.
1943 елның июлендә исә ТАССРда – Шөгер янында беренче нефть
фонтаны атыла...

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Без бергә! Без булдырабыз! Без, һичшиксез, җиңәчәкбез!
Татарстан Рәисе 2026 елга нинди бурычлар билгеләде

14. «Әлеге карарны кабул итүчеләрне хөрмәтләп, каршыларында баш иям!»,
яки Ни өчен метро төзелешенә ышанмаганнар

16. Дөньяда иң кыскамы? Юк, иң яше!
Ни өчен Казан метросының киләчәге якты

24. Алтын басулардан аш өстәленә кадәр
Сыйфатлы ипинең сере нәрсәдә

игелекле эшләр

32. Тугыз бала, унҗиде онык һәм оныкчык...
Нәсимә Гайфетдинова иң зур байлык турында

36. Үзенчәлекле балаларның әнисе
Тормышның асты-өскә килгәндә нишләргә

40. Сугыш чоры балалары
Күп балалы ана ничек туган ягына кайтып җитә алган

44. Кеше капиталы
Аны ничек арттырырга

мәңгелек кыйммәтләр

66. Онытылмас исемнәр
Хәлил Әбелханов кем булган

70. Әдәби карта
Заһидә Бурнашева язмышы турында нинди фикерләр яши

74. Китап киштәсе
Тинчурин театры артистлары нәрсәләр укый

78. Татарстан авыллары
Миңгәрдә ничә музей бар

86. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Печниковлар йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълумат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: Александр Ефремов

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

08.10

Винай Кумар, Һиндстанда Россиянең Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле, – Казанда, «TIME: Россия – Һиндстан. Үзара нәтиҗәлелек» форумының эшлекле иртәнге ашында:

– Казанда безнең консуллыкны ачу – берничә атналык эш. Ул инде киләсе айда ук эшли башлаячак. Татарстан – инвестицияләр өчен бик уңайлы төбәк. Хезмәттәшлек өчен шактый зур мөмкинлекләребез бар, шулай ук биредә бик күп һинд студентлары белем ала. Нәкъ менә шуңа Казан яңа консуллыклар ачылырга тиешле ике шәһәрнең берсе итеп сайланды.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

13.10

Пхувонг Ункхамсэн, Лаосның Сәясәт һәм милли идарә академиясе рәисе:

– Бүгенге Казан белән мин укыган замандагы (1983–1988) шәһәр арасында – бик зур аерма. Кыенлыкларга карамастан, сезнең икътисадның барлык тармаклары зур тизлек белән үсә. Сезнең матур шәһәрегездә 37 ел булмадым. Эшлекле сәфәрнең беренче көненнән үк үзгәрешләрнең зурлыгын күрәм һәм сизәм.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

04.10

Марианна Савон, Россиянең джаз, соул- һәм фанк-җырчысы, – «Джазовая Казань» XII Халыкара фестиваль ачылышында:

– Казан федераль әһәмияттәге тагын да зуррак мәдәни үзәккә әверелеп бара. Джаз юнәлешендә дә, поп-музыка юнәлешендә дә. Биредә үз мәдәни үзенчәлегегез булуы шәп. Россиянең күпмиллэтле бай тарихы бар. Миңа, яртылаш кубалы буларак, бу, әлбәттә, бик кызыклы һәм мөһим, чөнки рус кешеләре – бу бик зур төсләр палитрасы. Татарстан да искәрмә түгел.

Фото: Роман Кручинин / ТАСС фотохост-агентлыгы, tatarstan.ru, «Голос на Первом канале» тапшыруыннан кадр.

игелекле
эшләр

акыллы
гамәләр/

мәңгелек
кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гарәп һәм һинд журналистлары Казанга **нигә** килгән

ТР икътисады **ни өчен** тотрыклы үсеш күрсәтә

Татарстан Рәисе **кем** каршында башын ия

Марат Рәхимов **ни өчен** БАМны Казан метросына алыштыра

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: БЕЗ БЕРГӘ! БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ! БЕЗ, ҺИЧШИКСЕЗ, ҖИҢӘЧӘКБЕЗ!

2026 елда Татарстан Республикасы Рәисенең ТР Дәүләт Советына Юлламасыннан

Татарстан алга таба үсешен дәвам итә, күп кенә социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча алдынгылар сафында. РЕСПУБЛИКАНЫҢ БАРЛЫК УҢЫШЛАРЫ ҺӘМ КАЗАНЫШЛАРЫ – КҮПМИЛЛӘТЛЕ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БЕРДӘМ ХЕЗМӘТЕ НӘТИҖӘСЕ. Башлангыч һәм проектларыбызны гамәлгә ашыруда системалы төстә ярдәм итүләре өчен илкүләм лидерыбыз – Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга һәм РФ Хөкүмәтенә рәхмәтле.

ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫ ТЫЛ ТУРЫНДА

Махсус хәрби операция зонасында батырлык һәм кыюлык белән хәрби бурычларын үтәгәннәре өчен 17 татарстанлы Россия Герое исеменә лаек булды. Ни кызганыч, шуларның сигезенә бу исем вафат булганнан соң бирелде. 3 285 якташыбыз Батырлык ордены белән һәлак булганнан соң бүләкләнде. Туган илебез өчен гомерен биргән фидакарьләребез мәңгегә хәтеребездә сакланачак. Аларның батырлыклары – чын каһарманлык һәм Ватанга тугрылык үрнәге.

Гаиләләренә социаль ярдәм чаралары, шулай ук кайгырту һәм игътибар күрсәтүне тәэмин итеп, Ватанны саклаучыларыбызга ныклы таяныч булдыру – бик мөһим бурыч. «Ватанны саклаучылар» фондының Татарстан Республикасы буенча филиалына республика Хөкүмәте һәм парламенты, башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасының Махсус хәрби операция ветераннары ассоциациясе һәм Ватан сугышчылары гаиләләре комитеты белән берлектә бу эшне даими күзәтчелектә тотарга кирәк.

Махсус хәрби операция ветераннары һәм анда катнашучылар өчен илебез Президенты күрсәтмәсе нигезендә республикада гамәлгә ашырыла торган «Батырлар. Герои Татарстана» кадрлар программасы зур кызыксыну уятты. Аларның һәрберсе, туган илгә тугры хезмәт итү һәм ватанпәрвәрлек үрнәге буларак, Татарстанның үсешенә үзеннән өлеш кертер, дип ышанам. Төрле чорларда Ватанны саклап көрәшкән һәм тылда тырыш хезмәт куйган һәркемгә олы ихтирам йөзеннән 2026 елны Татарстанда Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итәм.

Татарстанлылар, йөрәкләре кушканча, хәрбиләребезгә, аларның гаиләләренә, фронтка һәм шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә гуманитар ярдәм күрсәтәләр. Бу мөһим эштә катнашкан һәркемгә олы рәхмәтемне җиткерәм. Гомумән алганда, кешеләргә ихластан булышлык күрсәтү бүген аеруча зур әһәмият алды. Шуңа бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында ирекледәр хәрәкәтен үстерүгә өлеш керткән өчен» мактау билгесен, шулай ук ТР Рәисенең «Игелекле Татарстан» премиясен гамәлгә кую турында карар кабул иттек.

Бүгенге көндә Ватанны саклаучыларның, тыл хезмәтчәннәренең, күренекле фән эшлеклеләренең батырлыгын һәм кыюлыгын ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә юнәлтелгән проектлар аша популярлаштыру, төрле яшьтәге һәм төрле карашлы кешеләргә аңлаешлы контентны булдыру һәм тарату гаять мөһим. Моннан тыш,

Фото: ТР Рәисе матбугат хезмәте

дошманнарның тарихны бозып күрсәтү омтылышларын кискен төстә туктатырга һәм халыкка дөреслеге расланган һәм тикшерелгән мәгълүмат кына җиткерергә кирәк.

ХАЛЫКАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТУРЫНДА

Илебез җитәкчеләре күрсәтмәсе буенча Татарстан БРИКС, ШОС һәм Евразия икътисадый берлеге кысаларында берләшү процессларында актив катнаша, якын чит илләр, ислам дәүләтләре, Кытай, Һиндстан, Азия һәм Африка илләре белән хезмәттәшлекне үстерә килә. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum», «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек», Kazan Digital Week халыкара икътисадый форумнары, Глобаль яшьләр саммиты, Энергетика һәм Нефтьгаз-химия форумнары кебек еллык зур чаралар уздырылу республиканың халыкара икътисадый һәм гуманитар элемтәләрен шактый киңәйтергә ярдәм итә. Бу әһәмиятле вакыйгаларның гамәли нәтиҗәләр бирүен киләчәктә тагын да арттыра барырга кирәк.

Татарстан ислам дөньясы белән, шул исәптән «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме юнәлеше буенча да, өзлексез эш алып баруны дәвам иттерә. Партнёрлыкка нигезләнгән (ислам) финанслау чараларына таянып, уртак инвестиция проектларын гамәлгә ашыру – хезмәттәшлегебезнең мөһим юнәлешләреннән берсе. Казанда AAOIFI ислам финанслары стандартларын эшләү буенча төп халыкара оешманың беренче вәкиллеге үзгән ачу турында карар кабул ителде, ул Россиядә һәм БДБ илләрендә партнёрлык финанслары базарын киләчәктә дә үстерүнең әһәмиятле институты булачак.

ИКЪТИСАДТА ПЕРСПЕКТИВАЛЫ ПРОЕКТЛАР ТУРЫНДА

Запасларының күпчелек өлеше эшкәртелгән файдалы казылмалар чыганакларында эшләп, «Татнефть» компаниясе тотрыклы рәвештә елына 28–30 млн тонна нефть чыгара. «ТАНЕКО» Европада иң яхшы нефть эшкәртү комплексларының берсе санала, елына 17 млн тонна нефть эшкәртеп, ул үзенең үсешен дәвам итә. Быел илебездә җитештерелгән җиһазлар һәм катализаторлар кулланылган икенче гидрокрекинг җайланмасы эшли башлады. Бу исә үтәкүренмәле нефть продуктларының чыгышын 90 процентка җиткерергә мөмкинлек бирде.

Бүгенге көндә «Татнефть», шул исәптән цифрлы нигезгә корылган чишелешләр, биотехнологияләр һәм альтернатив энергетиканы куллануга кертү хисабына да, күппрофильле инновацияле компания буларак үсеш кичерә, терефталь кислотасы, полиэтилентерефталатлар һәм метионин җитештерү, шулай ук бөртеклеләрне тирәнтен эшкәртү буенча масштаблы проектларны гамәлгә ашыруны планлаштыра.

«СИБУР» республикада эзлекле рәвештә инвестиция проектларын гамәлгә ашыра. «Түбән Кама нефть химиясе» компаниясендә ЭП-600 олефин комплексы, «Казан органик синтез» предприятиесендә елына 50 мең тонна егәрлекле гексен-1 производствосы, 250 МВт егәрлекле пар һәм газ җайланмасы эшли башлады. Моннан тыш, «Түбән Кама нефть химиясе» һәм «Казан органик синтез» арасында магистраль этиленүткәргеч яңартыла, нигез полимерлар өчен катализаторлар производствосы төзелә, бу исә технология ягыннан бәйсезлекне тәэмин итәчәк. Киләсе елда Казанда «СИБУР»ның алдынгы химиянең төп юнәлешләре буенча фәнни тикшеренү үзәген ачу планлаштырыла.

Технологияләренең катлаулылыгы ягыннан «ТАИФ-НК» компаниясе дөньядагы топ-20 нефть эшкәртү заводлары сафында һәм эшкәртелә торган нефтьнең һәр тоннасыннан үтәкүренмәле нефть продуктлары чыгышы буенча алдынгылыкка чыкты. Компания Түбән Каманың нефть эшкәртү заводы территориясендә чималны тирәнтен эшкәртүнең илдәге технологияләрен эшләү өчен фәнни-тикшеренү үзәген төзи.

«Аммоний» компаниясе узган елда берничә яңа производствоны файдалануга тапшырды, үз тарихында рекордлы күрсәткечкә – 2 млн тонна продукция алуга иреште, «Аммоний-2» эре инвестиция проектын гамәлгә ашыруны дәвам итә.

> Төрле чорларда Ватанны саклап көрәшкән һәм тылда тырыш хезмәт куйган һәркемгә олы ихтирам йөзеннән 2026 ЕЛНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ХӘРБИ БАТЫРЛЫК ҺӘМ ХЕЗМӘТ ФИДАКАРЬЛЕГЕ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТӘМ.

> Соңгы 5 елда республика икътисадында тотрыклы үсеш күзәтелә. СТРАТЕГИЯ-2030 ДА КАРАЛГАН ТУЛАЙ ТӨБӘК ПРОДУКТЫНЫҢ КҮЛӘМЕН 5 ТРЛН СУМГА ҖИТКЕРҮ БУРЫЧЫ, 2024 ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА ИСӘПЛӘГӘНДӘ, ИНДЕ АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ. Республика икътисадының киләчәктәге үсешенең нигезен нефть, газ һәм химия комплексы тәшкил итә.

Машина төзү комплексында «КАМАЗ» инвестиция проектларын, шул исәптән электробуслар, пилотсыз автомобильләр, водород тематикасы буенча проектларны эзлекле төстә гамәлгә ашыруын дәвам итә. К5 буыны автомобильләрен һәм пассажир транспорты модельләр рәтен эшләп чыгару производствосын киңәйтү автогигантның бурычы булып кала. Илнең автомобиль тармагындагы кыенлыкларны исәпкә алып, федераль үзәк белән берлектә республиканың автомобиль төзү сәнәгате предприятиеләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләсен хәл итүне карарга кирәк.

Казан авиация заводында яңартып кору эшләре дәвам итә. Быел төп сәнәгать объектлары файдалануга тапшырылачак, бу исә Ту-214 самолётларын сериялләп чыгаруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Казан вертолёт заводы төп җитештерү цехларын яңартып коруны тәгәлләде, «Ансат» вертолётына Россиядә эшләнгән двигатель куюга

кучүне тәэмин итте һәм яңа Ми-34 вертолётын чыгарырга әзерләнә.

«Казан компрессор машиналары» заводы Зеленодольск мәйданчыгында быел СПГ тармагы өчен компрессор җиһазларын, газ турбиналарын һәм электр двигательләрен сынау буенча дөньякүләм үсеш дәрәҗәсендәге тиңдәшсез комплексны файдалануга тапшырачак.

«Хайер» компаниясе Чаллы шәһәрендә югары технологияле 6 заводны файдалануга тапшырды һәм «Хайер» сәнәгать технопаркын үстерү эшен дәвам итә. Бу исә якынча 30 млрд сумлык инвестиция дигән сүз.

Сәнәгатьне үстерүнең нигезен энергетика комплексы тәшкил итә. Республикада 10 ел эчендә 1,7 гигаватт егәрлекле яңа объектлар файдалануга тапшырылды. Шулай ук «ТГК-16» Түбән Каманың 1 нче җылылык-электр үзәгенең пар турбиналарын яңартып коруны дәвам итә. «ТАНЕКО» нефть коксын ягу өчен куелган энергетик казан-агрегатларны үзгәртеп коруны тәгәлләп килә. «Татэнерго» компаниясе, Түбән Кама җылылык бүлү челтәрләрен алыштырып, зур эш башкарды. Чаллы җылылык-электр үзәген яңартып кору мөһим бурыч булып тора.

ИННОВАЦИЯЛЕ ҮСЕШ ӨЧЕН КАДРЛАР ТУРЫНДА

Урта һөнәри белем бирү өлкәсендә 18 оешма «Профессионалитет» федераль проектында җиңеп чыкты, профильле предприятиеләр – эшче кадрлар заказчыларының турыдан-туры катнашуында ресурс үзәкләре челтәре булдырыла. Аларның саны – 49. Компанияләр уку-укытуны оештыруга производствода эшләүче, гамәли тәҗрибәсе булган укытучыларны җәлеп иттеләр. 2030 елга әле тагын 8 үзәк ачарга планлаштырабыз. Моннан тыш, алдан һөнәри әзерлек бирү буенча ике үзәк булдырылды.

Югары белем бирү өлкәсендә кадрлар әзерләүдә алдынгы инженерлык мәктәпләре төп рольне уйный. Индустриаль партнёрлар – предприятиеләр техник биремнәр ясый, практика узу өчен эш урыннары бирә һәм югары белем алып чыккан яшьләрне эшкә урнаштыруны тәэмин итә. Эшче кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү инфраструктурасын төзүдә эре бизнесның актив катнашуын билгеләп китәргә кирәк. Әйтик, «СИБУР» корпоратив фәнни-техник үзәге һәм Әлмәт шәһәрендә «Нефть югары мәктәбе»нең халыкара дәрәҗәдәге университет үзәге шул рәвешчә эшчәнлек алып бара.

Без технологик эшкуарлыкка да зур өмет баглыйбыз. «Технологик эшкуарлык университет платформасы» проекты һәм «Студентлар стартабы» конкурсы нәтиҗәләр бирде инде: җиңү яулаган татарстанлыларның һәрберсе 1 млн сумлык 1 079 грант алды. Алар киләчәктә инновацияле яңа икътисад өчен кадрлар булачак. Быел компаниянең «Россиядә эш» порталында 4 800 урынга максатчан уку турында шартнамәләр төзү өчен 2 255 тәкъдим урнаштырылды. Барлык эш бирүчеләрне максатчан укудан файдалануны алдан планлаштырырга чакырам. Моннан тыш, республика Хөкүмәтенә предприятиеләрнең белем бирүнең барлык баскычларында кадрлар әзерләүгә квалификацияле дәүләт биремен формалаштыруда актив катнашуларын тәэмин итүне, алдынгы предприятиеләр базаларында студентлар һәм яшь белгечләр өчен стажировка һәм практика программаларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны, компанияләрдә уку үзәкләрен һәм яңадан һөнәри әзерлек бирү программаларын булдыруга кызыксындыру тудыруны йөклим.

Самолёт, вертолёт, автомобильләр төзү, радиоэлектроника, яңа материаллар һәм химия, авыл хуҗалыгы, медицина кебек өстенлекле юнәлешләрдә компетенцияләр үзәкләре төзү максатында, Хөкүмәткә Фәннәр академиясе, югары уку йортлары һәм предприятиеләр белән бергә республиканың технологияләрдә лидерлык илкүләм проектларында актив катнашуын тәэмин итүне, пилотсыз технологияләр, ясалма фәһем һәм биотехнологияләрне дә кертеп, фәнара яңа тикшеренү юнәлешләрен булдыруны һәм эшләтүне, шулай ук бу фәннәрне белем бирү программаларының барлык баскычларына кертү мәсьәләсен эшләүне йөклим.

ИНВЕСТИЦИЯЛЕ КЛИМАТ ҺӘМ ҮСЕШ НОКТАЛАРЫ ТУРЫНДА

Кадрлар кытлыгы шартларында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру иң мөһим бурычка әверелә. Әлеге юнәлешкә караган федераль һәм республика проектларында һәм ярдәм чараларында максималь рәвештә катнашырга, сәнәгать предприятиеләрендә ясалма фәһем элементларын һәм робот техникасын кертергә кирәк. 2030 елга республикада сәнәгать роботлары санын 4 мәртәбәгә арттырылырга тиеш.

Инвестицияләр күләмен арттыруга этәргеч бирү – тулаем икътисадый тотрыклылыкка ирешүнең һәм үсешнең мөһим факторы. 5 ел эчендә республика икътисадына һәм социаль өлкәгә 4,8 трлн сумлык инвестицияләр кертелде. Югары үсештәге инвестиция инфраструктурасы булдырылды. Болар – нәтиҗәле эшләп килә торган «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналары, «Яшел үзән» яңа МИЗ, биш алгарышлы үсеш территориясе һәм сәнәгать парклары.

Үсешкә этәргеч бирә торган яңа нокталар табып, бизнес өчен инфраструктураны үстерү эшен, шулай ук инвестиция проектларын һәм Инвестиция мохитен яхшырту планы чараларын гамәлгә ашырганда хакимиятнең барлык дәрәҗәләре, предприятиеләр һәм ресурслар белән тәэмин итү оешмаларының үзара килешенгән эшчән-

> 5 ЕЛ ЭЧЕНДӘ РЕСПУБЛИКА ИКЪТИСАДЫНА ҺӘМ СОЦИАЛЬ ӨЛКӘГӘ 4,8 ТРЛН СУМЛЫК ИНВЕСТИЦИЯЛӘР КЕРТЕЛДЕ. Югары үсештәге инвестиция инфраструктурасы булдырылды.

леген оештыруны дәвам итәргә кирәк. Инвестиция-төзелеш циклын мөмкин булганча кыскарту таләп ителә, бу эш шул исәптән «Росатом» дәүләт корпорациясе белән берлектә «Турыдан-туры инвестиция агымы» проектын дәвам итү, барлык муниципалитетлар һәм ресурслар белән тәэмин итү оешмаларының цифрлы чишелешләрдән һәм платформалардан, аерым алганда, Бердәм килештерү кабинетыннан файдалануын тәэмин итү хисабына башкарылырга тиеш.

АЗЫК-ТӨЛЕК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ҺӘМ ЭШКӘРТҮГӘ БАСЫМ ЯСАУ ТУРЫНДА

Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча Татарстан Идел буе федераль округында беренче урында тора, ә Россия буенча алдынгыларның беренче бишлегенә керә. Сөт җитештерүдә без күп еллар дәвамында беренчелекне саклап киләбез, җыеп алынган бәрәңге буенча – 2 нче урында, ә шикәр чөгендере буенча 6 нчы урында торабыз. Республика мөгезле эре терлек баш саны ягыннан алдынгылар сафында.

Татарстанда яңа биотехнопарк төзү эше алып барыла, генетик тикшеренүләр буенча ул иң эре махсуслаштырылган үзәк булачак. Геном селекциясе ысулларын куллану ярдәмендә 2030 елга савылган сөтнең күләмен 10 мең килограммга кадәр җиткерү күздә тотыла.

Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә аеруча зур тырышлык куярга кирәк. 5 елда без сөт һәм ит эшкәртү комбинатларының җитештерү куәтен 50 процентан 84 процентка күтәрүгә ирештек. 2030 елга бурыч – әлеге күрсәткечне 95 процентка җиткерү. Эшкәртү сәнәгатен үстерү чит илләргә сатуга чыгарыла торган авыл хуҗалыгы продукциясенең күләмен арттыру мөмкинлеген бирәчәк. Узган ел йомгакларына караганда, экспортның 70 процентын чимал һәм тирәнтен эшкәртелмәгән продукция тәшкил иткән. Тирәнтен эшкәртелгән продукция экспортына күчү мөһим. Экспорт өчен тагын бер әһәмиятле юнәлеш – хәләл азык-төлек. Аны җитештерүне үстерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Шәхси хуҗалыклар дистәләгән мең гаиләләрнең керем чыганагы, авылларның нигезе булып тора. Быел аларга ярдәм йөзеннән республика бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаның күләмен 700 млн сумга җиткердек. Яңа эш башларга нияте булган кешеләргә үз проектларын тормышка ашыруда ярдәм итү, авыл халкының хезмәт активлыгын арттыру, шулай ук авыл хуҗалыгы кооперацияләрен алга таба да үстерү эшен дәвам иттерү зарур. Кооперативларга булышу чарасы буларак ел саен 200 млн сум акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде.

ЦИФРЛАШТЫРУДА ӨСТЕНЛЕКЛӘР ТУРЫНДА

Без алдынгы ИТ-чишелешләрнең яңа программасын эшләү турында карар кабул иттек.

ЭШКӘРТҮНЕ ҮСТЕРҮ ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕН АРТТЫРУ МӨМКИНЛЕГЕН БИРӘЧӘК. Узган ел йомгакларына караганда, экспортның 70 % чимал һәм тирәнтен эшкәртелмәгән продукция тәшкил итә. Тирәнтен эшкәртелгән продукция экспортына күчү мөһим.

Социаль өлкәне цифрлы нигезгә күчерү юнәлешендәге өстенлекле проектларга аерым игътибар биреләчәк. Моннан тыш, республикада инженерлык челтәрләре цифрлы нигезгә күчерелә башлады. Бу исә авариядән соң торгызу эшләрен тизрәк башкарырга һәм җир кишәрлекләре белән бәйле процедураларны гадиләштерергә мөмкинлек бирәчәк. «ГосПромпт» ясалма фәһем республика платформасы эшли башлады. Быел укытучылар өчен аларның хезмәте белән бәйле көндәлек мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле интеллектуаль ярдәмче эшли башлаячак.

ИТ-өлкәгә инвестицияләр җәлеп итүне дәвам итәргә кирәк. «Иннополис» МИЗда литий-ион аккумулятор батареялары җитештерелә башлады, тиздән җылылык-энергетика системаларын автоматлаштыру һәм вакуумлы технологик җиһазлар заводлары ачылачак. 2030 елга бурычыбыз – 100 млрд сумлык еллык керем алу. ИТ-паркта резидентлар санын меңгә җиткергә кирәк.

Бүген Татарстанда 24 муниципаль ИТ-парк эшли. 2030 елга барлык районнарда цифрлы икътисадның үсеш нокталарын булдыру аша аларның санын 40 ка җиткерергә планлаштырабыз.

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮ ПРОГРАММАЛАРЫ ТУРЫНДА

Дүртенче ел рәттән файдалануга тапшырылган торакның күләме 3 млн кв. метрдан артып китә, 600 меңнән артык гаилә үзенең торак шартларын яхшыртуга ирешә. Әлеге саннарда Президентыбыз Владимир Владимирович Путинның өлеше гаять зур, аның йөкләмәләре нигезендә гаиләләргә, авыл халкына булышуга юнәлтелгән, ИТ-ипотека һәм башка төрле бик күп ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла. Моннан тыш, республиканың социаль ипотека программасы кысаларында табиблар, укытучылар, предприятие хезмәткәрләре һәм бюджетның башка тармакларында эшләүче 12 меңнән артык гаилә фатир ачкычлары алды. Күпфатирлы йортларда өлешле төзелештә катнашучыларга бәйле четерекле мәсьәләләр тулысынча хәл ителде – 3 меңнән артык кешенең милеккә хокукы торгызылды.

Без территорияләрне төзекләндерүгә куелган таләпләрне тулысынча үзгәрттек, төзегән объектларыбыз матур гына түгел, ә иң мөһиме кешеләр өчен уңайлы да булырга тиеш. Карарлар кабул итүгә гражданнарны җәлеп итүгә аерым игътибар бирелә. Бу исә төрле яшьтәге һәм кызыксынулары төрле булган кешеләрнең ихтыяҗларына туры килә торган, чын мәгънәсендә кирәкле җәмәгать урыннары булдырырга мөмкинлек бирә.

5 ел эчендә «Безнең ишегалды» программасы кысаларында бөтен республика буенча 1,5 млн

кеше яши торган 5 174 күпфатирлы йорт ишегалды төзекләндерелде, эшләр 54 млрд сумга төште. Ял итү, аралашу, балалар тәрбияләү өчен заманча һәм куркынычсыз мәйданчыклар булдырылды. Яңартылган ишегаллары яше-картының яраткан урынына әйләнде. 10 ел эчендә дәүләт программасы кысаларында 45 муниципалитетта гомуми бәясе 33 млрд сумлык 450 парк, сквер, бульвар һәм яр буйлары төзекләндерелде.

Бүгенге көндә бездә 48 республика программасы эшләп килә. Аалар Татарстанның барлык шәһәр округларында һәм муниципаль районнарында гамәлгә ашырыла. Быел 3 700 социаль объект – мәктәпләр, балалар бакчалары, поликлиникалар, яшьләр үзәкләре, спорт һәм мәдәният объектлары төзеләчәк һәм төзекләндереләчәк. Бу исемлеккә шулай ук муниципаль районнарда сөт кухнялары, көч структуралары, КФУ биналары төзү һәм аларны капиталь төзекләндерү, боз ареналары төзү дә керә.

Кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән республика программалары алга таба да дәвам итәчәк. ТӨЗЕЛЕШНЕ БАШЛАГАНДА, ДЕМОГРАФИК ФАРАЗЛАРНЫ ҺӘМ АГЛОМЕРАЦИЯНЕ ҮСТЕРҮ ПЛАННАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ГАЯТЬ МӨҺИМ. Барлык төзелгән объектлар да нәтиҗәле эшләргә һәм халык йөри торган урынга әйләнергә тиеш.

Кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән республика программалары алга таба да дәвам итәчәк. Төзелешне башлаганда, һичшиксез, демографик фаразларны һәм агломерацияне үстерү планнарын исәпкә алу гаять мөһим. Барлык төзелгән объектлар да нәтиҗәле эшләргә, халык йөри торган урынга әйләнергә тиеш. Моның өчен район башлыклары җаваплы.

Торак-коммуналь инфраструктура объектларын яңарту республика программасын эшләтеп җибәрү киләсе 5 ел өчен иң җитди һәм зур чыгымнар сорый торган бурычларның берсе булып тора. Әлеге тармак республикада яшәүче һәр кешегә дә кагыла. Быел коммуналь челтәрләрне төзүгә һәм яңартуга 16 млрд сум акча бүлеп биреләчәк. Безнең максат – челтәрләрдә өзеклекләр булдырмас өчен, алдан күреп эшләү, аварияләр санын һәм коммуналь челтәрләрдә югалтуларны бермә-бер киметү.

ЮЛЛАР ҺӘМ ТРАНСПОРТ ТУРЫНДА

Илебез Президенты Владимир Владимирович Путин, Россия Хөкүмәте ярдәме белән республиканың юл челтәренә киң яңа трассалар өстәлде. Болар зур чыгымнар таләпителә торган, илдә тиңдәше булмаган проектлар: Идел елгасы аша салынган күпере булган «Көнчыгыш» М-12 югары тизлекле автомобиль юлы, Кама аша салынган күпердән Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен әйләнеп узу юлы, Алексеевск – Әлмәт автомобиль юлы, Казан шәһәре үзәгеннән тоткарлыксыз тиз чыгу мөмкинлеге бирә торган трассалар – Горький шоссесын реконструкцияләү һәм Вознесение трактын төзү.

Быел тагын 1,5 мең км юл төзеләчәк һәм төзекләндереләчәк, Чаллы шәһәреннән Башкортстан чигенә кадәр М-7 автомобиль юлында реконструкцияләү эшләре алып барыла, шулай ук Сокуры поселогына кермичә әйләнеп уза торган юл төзелә. Илебез Хөкүмәте булышлыгы белән Оренбург трактына дублёр юл төзү турында карар кабул ителде. Шулай ук урамнардагы юллар челтәрен төзекләндерү дә аерым игътибарга алыначак. Әлеге максатларга 35 млрд сум акча бүлеп биреләчәк.

Һава юллары да актив үсештә: Г. Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында 6 млн пассажирга хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирәчәк яңа терминал төзелә. Әлеге эшне киләсе елга тәмамлау зарур. «Бигеш» аэропортында самолётлар өчен очып китү-төшү полосасын реконструкцияләүне тәмамлау бурычы тора.

Бүгенге көндә су транспортында йөк ташу җитәрлек күләмдә түгел – 33 млн тонна. 2030 елга бурыч – әлеге күрсәткечне елына 50 млн тоннага җиткерү, Татарстанны, шул исәптән елга логистикасы аша да, «Төньяк – Көньяк» транспорт коридорына тоташтыру. ТР Транспорт министрлыгына су юллары инфраструктурасына тулы аудит уздыруны, причалларны һәм елгаларга килә торган юлларны тәртипкә китерүне йөклим.

Җәмәгать транспортының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә, шулай ук авыл халкына транспорт хезмәте күрсәтүгә ярдәм чараларын эшләргә кирәк. Моннан тыш, метро станцияләре һәм җәмәгать транспорты тукталышлары янында шәхси транспорт кую урыннарын оештыру мәсьәләсен карап тикшерү зарур.

Шунысы мөһим: юлларны, тимер юл, су һәм һава транспортын үстерү буенча барлык проектлар бердәм транспорт системасына кертелергә тиеш, бу исә гражданнар өчен уңайлыклар булдырырга һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә ярдәм итәчәк, бизнес өчен яңа мөмкинлекләр тудырачак.

МӘГАРИФ ҺӘМ ТӘРБИЯ ТУРЫНДА

Гомуми белем бирү өлкәсендә соңгы 5 елда 48 яңа мәктәп төзелде, мондый күрсәткечнең Татарстан тарихында булганы юк иде әле. 1 192 белем бирү объекты капиталь төзекләндерелде. Финанслау күләме 76 млрд сум тәшкил итте. Әлеге мәктәпләрнең һәрберсендә балаларның һәрьяклы үсеше өчен барлык шартлар да булдырылды, мәгариф өлкәсендәге иң алдынгы технологияләр кертелде.

Без «Физика-математика алгарышы» проектына зур өметләр баглыйбыз. Аны гамәлгә ашыруга республика бюджетыннан ел саен 250 млн сумнан артык акча бүлеп биреләчәк. Әлеге проектның нигезенә салынган барлык карашалымнарны башка табигать фәннәрендә дә, бе-

ренче чиратта, химия фәнендә киңрәк файдалану мәсьәләсен хәл итәргә кирәк.

Барлык муниципаль районнарда киләчәктә дә инфраструктураны үстерергә, шул исәптән балаларга яңа технологияләрне өйрәнү мөмкинлеге бирәчәк мәктәп технопарклары булдырырга, мәктәпләрне заманча җиһазлар белән тәэмин итү һәм алдынгы мәгариф технологияләрен кулланышка кертүне күздә тоткан «Цифрлы нигездә мәгариф мохите» программасын үстерергә ниятлибез. Республика Укытучы йортын ачу да күздә тотыла, анда укытучылар Россиянең һәм дөньяның иң яхшы экспертлары катнашында квалификацияләрен күтәрә алачак. Тулаем алганда, укытучы һөнәренең абруен арттыру юнәлешендә эшне дәвам итәргә кирәк.

Россия Президенты Владимир Владимирович Путин күрсәтмәсе буенча оештырылган «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте кысаларында балалар арасында актив эш алып барыла. Бүгенге көндә ул 300 меңгә якын баланы һәм остазны берләштерә. Яшьләрнең барлык категорияләре белән системалы һәм комплекслы эшне дәвам итәргә, патриотик тәрбия бирүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Бу – илебез иминлеге, традицион рухи хәзинәләрне, буыннар арасында бәйләнешне саклау.

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУГА ҺӘМ АДРЕСЛЫ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУГА ИНВЕСТИЦИЯЛӘР ТУРЫНДА

Республика эзлекле рәвештә һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы сәламәтлек саклау системасын үстерә килә. 2020 елдан Татарстанда тармак инфраструктурасы сизелерлек яңартылды: 300 дән артык яңа медицина объекты төзелде. Бу – хастаханәләр, поликлиникалар, ФАПлар. 586 учреждение капиталь төзекләндерелде. Әлеге максатларга 50 млрд сум акча бүлеп бирелде, 40 меңнән артык заманча җиһазлар сатып алынды. Бу республика халкының сәламәтлеген саклауга кертелгән иң зур инвестицияләр.

Авыруларны кисәтү чараларына да зур игътибар бирелә. Узган 5 елда диспансеризация узучыларның саны 5 тапкырга артты, һәм алар 1,5 млн кеше тәшкил итте. «Сәнәгать диспансеризациясе» кысаларында 300 меңнән артык граждан эш урыннарында үзләренең сәламәтлеген тикшерә алды. Биш «Мобиль поликлиника» күчмә комплексы ярдәмендә үзәктән ерак авылларда яшәүче кешеләргә югары технологияле медицина ярдәме үзәге белгечләре 300 меңнән артык консультация ярдәме күрсәтте.

Йөрәк-кан тамырлары һәм яман шеш авыруларын кисәтү һәм дәвалау өлкәсендә без шулай ук уңай нәтиҗәләр күрәбез – 5 елда кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр санын 15 процентка киметүгә һәм яман шеш авыруларын иртә срокта ачыклау очракларын арттыруга ирештек. Югары технологияле медицина ярдәменә килгәндә – соңгы 5 елда ул 160 мең татарстанлыга күрсәтелде, шулай ук трансплантологияне үстерү юнәлешендә – органнарны күчереп утырту буенча 800 дән артык операция ясалды.

Татарстанда халыкка социаль ярдәм күрсәтү кысаларында шәхси ихтыяҗларны күздә тоткан, һәркем файдалана ала торган һәм чын мәгънәсендә нәтиҗәле чаралар гамәлгә ашырыла. Соңгы елларда без балалы гаиләләргә, олы яштәге гражданнарга, инвалидларга һәм мохтаҗ булган башка затларга ярдәм күрсәтү ысулларын шактый киңәйттек. Олы яштәге кешеләрне һәм инвалидларны озак вакытка тәрбиягә алу системасына аеруча зур игътибар бирелә. Зеленодольск шәһәрендә «Тәрбия йортлар»ы төзү мөһим проект булып тора. Бу юнәлештә даими контроль булырга тиеш.

МӘДӘНИ КЫЙММӘТЛӘР ҺӘМ МИЛЛИ ТӘҢГӘЛЛЕК ТУРЫНДА

Соңгы 5 ел эчендә 82 яңа мәдәният объекты төзелде, 348 е капиталь төзекләндерелде, моңа 60 млрд сум акча бүлеп бирелде. Галиәсгар Камал исемендәге театрның заманча бинасы ачылу мәдәни тормышта мөһим вакыйга булды.

2026 елда Казан ислам дөньясының мәдәни башкаласы дәрәҗәсен йөртәчәк. Бу республиканың бай мәдәни мирасын үстерү өчен яңа мөмкинлекләр ача.

Киләсе елда бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына – 140 ел, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 120 ел була. Аларның иҗаты бүген дә тормышчан. Безнең уртак бурыч – шагыйрьләрнең мирасын киң таныту.

Бөтендөнья татар конгрессы үз эшчәнлеге кысаларында киләсе елны Габдулла Тукай елы дип игълан итү тәкъдиме белән чыкты. Мин әлеге тәкъдимне хуплыйм.

> Бөтендөнья татар конгрессы үз эшчәнлеге кысаларында КИЛӘСЕ ЕЛНЫ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТҮ ТӘКЪДИМЕ БЕЛӘН ЧЫКТЫ. Мин әлеге тәкъдимне хуплыйм.

Гомумән алганда, татар халкының милли тәңгәллеген саклау, шул исәптән цифрлы мохиттә дә, аның милли кодын таныту буенча киләчәктә дә бергәләп тырышлык куярга кирәк. Республика Хөкүмәтенә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә Татар халкының милли тәңгәллеген саклау программасына, аны танытуга тагын да зуррак игътибар биреп, тиешле үзгәрешләр кертүне йөклим.

Без шанлы тарихи мирасыбыз, Россиянең күпмилләтле халкының бердәмлеге, әһәмиятен җуймас гореф-гадәтләребез һәм бай рухи-әхлакый хәзинәләребез белән көчле. Болар барысы да Татарстан Республикасының киләчәктәге үсеш-алгарышының, яңа зур җиңүләребезнең һәм Ватаныбызның имин киләчәгенең ныклы нигезен тәшкил итә.

Тарихта беренче Россия-гарәп саммиты алдыннан Казанга **ГАРӘП ЖУРНАЛИСТЛАРЫ КИЛДЕ:** төбәкнең 19 иленнән 65 хәбәрче һәм блогер.

«Фотоэшләр сериясе: Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» номинациясендә катнашучы Юлия Шамарина фотосы. «Всё будет Харампур!», Ямал-ненец автоном округы.

Казан Кремлендәге Кабул итү урыннарында **«КҮПЧАЛЫМЛЫ РОССИЯ» XVI БӨТЕНРОССИЯ ЖУРНАЛИСТЛАР КОНКУРСЫ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘДЕЛӘР.** Быел әлеге конкурска килгән эшләрнең саны рекордлы булды – илнең 55 төбәгеннән 1 249 гариза кабул ителде. Конкурсның бүләкләү фонды 2,8 миллион сумнан артып китте.

Фото: tatar-inform.ru

«TIME: РОССИЯ – ҺИНДСТАН» ФОРУМЫНДА: инвестицияләр, хезмәттәшлек һәм икътисадны үстерүнең яңа юнәлешләре тикшерелде. Шушы вакыт эчендә Татарстан бюджетының беренче мәртәбә ярты триллион сумнан артып китүе билгеле булды, бу исә төбәк программаларының киң колачлы булуын раслый.

Фотолар: Александр Ефремовтан һәм катнашучыларның шәхси архивыннан алынды

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи. Балаларны, укытучыларны өйрәтә. Арабызда алтын куллы иске әйберләрне яңартучы, сирәк һөнәргә ия фидакарь затлар да бар.
«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә. Бу санда без эш вакытының күп өлешен ҖИР АСТЫНДА үткәрүчеләр турында язабыз. Сезгә, Казан шәһәре халкының һәм бирегә килүче кунакларның тормышын уңайлы итеп, моннан 30 ел элек метро төзи башлаучылар һәм бүген дә әлеге эшне дәвам итүчеләрнең тарихларын тәкъдим итәбез.
Бүген казанлылар үз тормышларын метродан башка күз алдына китерә алмый.
Метро төзелә башлаганчы Казанда тормыш нинди була һәм хәзер ничек? Метро ничек пәйда булган?
Бу эшне кемнәр башлаган?
Әйдәгез шул заманга әйләнеп кайтыйк әле. Бүген сез түбәндәгеләрне белерсез:

28 нче ТАРИХ
Рөстәм Миңнеханов ни өчен метро төзү турында карарны кабул итүчеләр каршында башын ия

29 нчы ТАРИХ
Марат Рәхимов ни рәвешле БАМнан Казанда метро төзүгә күчкән

Башка тарихларны «Татарстан» журналының түбәндәге саннарыннан укыгыз: 2022 елның 10–12 нче, 2023 елның 1, 2, 6 нчы, 2024 елның 1, 4 нче, 2025 елның 6, 8 нче саннары.

УЛ ЧАКТА МИҢА МЕТРО УТОПИЯ БУЛЫП ТОЕЛГАН ИДЕ... ХӘЗЕР АНЫ ТӨЗЕРГӘ УЙЛАУЧЫЛАР КАРШЫНДА БАШЫМНЫ ИЯМ!

28 НЧЕ ТАРИХ

Фото: ТР Рәисе матбугат хезмәтеннән һәм kremlin.ru сайтыннан алынды

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – Казанда метрополитен төзелешенең ничек башлануы, көндәшләрдән өстенлегебез, мактанырлык казанышыбыз һәм иң нәтиҗәле транспорт төре турында.

Узган гасырның 90 нчы еллары азагында мин Татарстанның финанс министры идем. Бу елларның икътисад өчен бик катлаулы чор булуын күпләр хәтерлидер... Нәкъ менә шулчакта Казан мэры Камил Исхаков метро төзү турында хыяллана башлады. Бу планны ничек гамәлгә ашырырга дип озак баш ватты, үзенең идеясе белән Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевне дә мавыктырды, аны да ышандырды.

Беләсезме, мин Минтимер Шәриповичны һәрвакыт чын стратег, барысын да алдан күрә белүче зирәк җитәкче дип санадым һәм саныйм. Һәм ул чакта Шәймиевнең дә метро яклы булуына бик гаҗәпләндем! Миңа исә бу утопия булып тоелды.

Хәзер, инде 30 елга якын вакыт үткәч, курыкмыйча әлеге карарны кабул итүчеләрне хөрмәтләп, каршыларында баш иям! Чыннан да зирәк һәм кыю адым булган ул. Һәм, дөресен генә әйткәндә, әгәр метро булмаса, тыгыз-кысан юлларда искиткеч тизлектә агылучы гаять зур автомобиль ташкыны белән хәзерге вакытта без нишләр идек - хәтта уйларга да куркам.

Казанда метроның булуы – шәһәрнең башка калалардан гаять зур өстенлеге ул. Бүген метро – безнең мактанырлык казанышыбыз да, нәтиҗәле транспорт төре дә.

Шулай итеп, 1997 елда Казан метрополитены төзелә башлады. Зур тантана оештырылды – 27 августта Казан үзәгендәге Свердлов (хәзер – Петербург) урамында гранит-мәрмәр ротонда нигезенә Минтимер Шәймиев Казан метросының булачак пассажирларына аталган капсуланы салып калдырды.

2005 елга кадәр бик актив эш барды, бер үк вакытта берничә тоннель казу комплексы эшләде, барлык станцияләр дә ачык ысул белән төзелде.

Һәм менә инде 2005 елның 27 августында Казан метрополитенының беренче өлеше тантаналы рәвештә ачылды, озынлыгы 7,1 километрлы участокта 5 станция урнашкан иде: «Кремль», «Тукай мәйданы», «Сукно бистәсе», «Әмәт» һәм «Горки».

Әлбәттә, мин ул чакта күп кешенең, иң кыска метро Казанда, дип шаяртканын хәтерлим әле. Тик берәүләр шаярткан арада икенчеләре эшен дәвам итте. Ә мин һәрвакыт безнең метроның Россиядә иң яше булуын искәртәм.

Метро ачылышына Россия Президенты Владимир Путин килде һәм, эш графигының тыгыз булуына карамастан, метро төзүчеләр белән аралашырга да вакыт тапты. Кунаклар «Кремль» станциясеннән «Әмәт» станциясенә кадәр барды.

Метроның беренче участогын шәһәр һәм республика халкы бик сөенеп кабул итте. Хәзер безнең дә метробыз бар, һәм без аның белән бик горурланабыз. Тик үзәктәге кыска станцияләрнең әллә ни еракка алып бара алмавын барыбыз да яхшы аңлый иде.

Шунлыктан 2005 елда ук «Ольга» һәм «Полина» тоннель казу комплекслары ярдәмендә «Горки» – «Җиңү проспекты» тоннеле казыла башлады. Әлеге участокны без 2008 елда ачтык – 18 ай эчендә «Горки» һәм «Җиңү проспекты» станцияләре арасында җир астыннан 1924 метр юл салынды.

Минемчә, нәкъ шулчакта инде хәтта скептиклар да ышанды – Казанда метро инде бар һәм киләчәктә тагын да тармакланачак әле. Күпләр Казанның меңъеллыгыннан соң без метро турында онытырбыз, дип уйлады. Һич тә алай булып чыкмады!

Гаять тырыш хезмәтләре һәм чыдамлыклары, ә иң мөһиме – сыйфатлы юл сала алачакларына нык ышанулары өчен, беренчеләргә, шәһәребездә метро төзергә алынучыларга зур рәхмәт. Һәм тагын шунысы да сөендерә: хәзер илдәге метро төзүче иң яхшы оешмаларның берсе саналган «Казметрострой» нәкъ менә Казанда барлыкка килде һәм ныгыды бит! Хәзер безнең метро төзүчеләребезгә Татарстанда гына түгел, Мәскәүдә дә ихтыяҗ зур, бу аларның осталыгын, талантын һәм тәҗрибәсен тану билгесе. Аларга хезмәтләре өчен зур рәхмәт. Иманым камил, безнең уртак планнарыбыз һәм эшләребез күп әле, чөнки Казан метросы шәһәр белән бергә үсә!

МАРАТ РӘХИМОВ: «КАЗАНЫБЫЗ УҢАЙЛЫ БУЛСЫН ӨЧЕН ТЫРЫШАБЫЗ»

– 1996 елның азагы иде. Мине Казан метрополитенын төзергә чакырдылар, – дип искә ала «Казметрострой» АҖ генераль директоры Марат Рәхимов. – Сорау бирдем: «Гафу итегез, нинди метро төзергә җыенасыз сез? Ничек? Булган технологияләр белән тормышка ашырып булмастай эш бу!»

«Заманча метро төзелеше өчен, барлык шартларны да тудырачакбыз!» – җавап әнә шундый булды. Мин бу сүзләргә ике дә уйламый ышандым. Һәм юлга кузгалдым.

«МИҢА УЛ ЧАКТА – НИБАРЫ 40, ӘЛЕ ЯПЬ-ЯШЬ ИДЕМ...»

...Миңа ул чакта – нибары 40, әле япь-яшь идем, тик шулай да, Казан метросын төзергә алынам икән, берничә шартым бар, дип кисә-теп куйдым. Дөресрәге, үтенеч. Заманча технологияләрдән тыш, мин үз командамны алып килергә теләвемне әйттем. Ә аларга фатирлар, балалар бакчалары, мәктәпләр кирәк. «Барысы да булачак!» – диделәр.

2005 елда без метроны сафка бастыр-дык. Җаваплылыкны тулаем үз өстемә алып, шуны әйтәм: Казан метросы – без эшләгәннәрдән иң кыскасы булса да, хәвефсезлек ягыннан да, контроль буенча да иң заманча төзелеш. Без үз алдыбызга куйган планкага әле башка бер генә метро-политенның да ирешкәне юк.

Һәм менә инде утыз елга якын вакыт ара-лыгында Казанда метро һаман да бар, һәм ул төзелүен дәвам итә. Ә минем белән бергә килгән 200 дән артык кеше бүгенге метро тө-

Фото: Александр Ефремов, «Казметрострой» АҖ алынды

зелешенең умырткасын тәшкил итә. «Казметрострой»да хәзерге вакытта 77 династия эшли: аталары, балалары, оныклары. Бу горурлык түгелмени?

Бушлай торак алган һәм аның өчен ун ел буена хезмәт куйган бер генә кеше дә мине уңайсыз хәлгә куймады, сынатмады. Берәү дә эштән китәм дип кубарылмады. Ә бит ул чакларда эш хакын түләү белән дә авырлыклар булмады түгел, булды, метрога финанслар китерү дә гел җайлы гына бармады. Әмма ул кешеләр бүген дә үз эшен эшли, югыйсә инде – пенсионерлар. Җир астында эшләүчеләрнең пенсиягә чыгу вакыты 50 яшьтән бит. Үземнең дә йөрәгем тыныч, намусым чиста – беркемне дә алдамадым.

«КЕМ ДӘ БУЛСА БЕЗГӘ БЕР ГЕНӘ ТАПКЫР ШУЛАЙ ДИП ӘЙТСӘ ИКӘН!»

Бервакыт Рөстәм Нургалиевич Сочидагы форумда, Татарстан презентациясе вакытында мондый сүзләр әйтте: «Казанда метро төзелеше башланган вакытта мин республиканың финанс министры идем, һәм бу проектка катгый каршы тордым. Сез нәрсә инде, җегетләр, нинди метро? Аны ничек башкарып чыгарга? Беренчедән, бу бит коточкыч кыйммәтле проект, икенчедән, коточкыч катлаулы. Кыйммәтле булганга күрә катлаулы да. Финанс министры буларак, мин еатгый каршы идем. Әмма нык ялгышканмын!»

Һәм менә быел, август аенда, Рөстәм Нургалиевич төзелешкә килде дә болай ди: «Метро төзү буенча шундый компетенциягә ия булу – безнең төбәк өчен зур горурлык һәм дәрәҗә. Сез – төзүчеләрнең чын элитасы!»

Мин аның бу сүзләрен бөтен илгә җиткердем, барлык метро төзүчеләргә дә. Барысы да: «Кем дә булса безгә бер генә тапкыр шулай дип әйтсә икән!», – дип, тел шартлатты.

Булмаган җирем калмагандыр. Экспертизага Красноярскига, Чиләбегә, Самарага бардым... Анда әле безнең Казанга кадәр үк башланган метро төзелешен ташландык хәлендә күреп кайттым.

ПЛАНЛАШТЫРГАН КАДӘРНЕ ТӨЗЕРГӘ ГОМЕР ҖИТСЕН ИДЕ...

Метро төзелеше эшендә бу гасырда төп көч – Марат Шакирҗанович Хөснуллин. Ул РФ Хөкүмәте Рәисенең урынбасары булгач, илдәге метро төзелеше юнәлеше шунда ук берничә баскычны берьюлы атлап күтәрелде, алга китте. Мәскәүдә станцияләр саны бермә-бер артты, ул Түбән Новгород, Чиләбе, Красноярскидагы метро төзелешләрен үз контроленә алды.

Инвестицияләргә кагылышлы шундый исәпләүләр бар. Чыгымнар ягыннан да, төбәкнең, метро килгән урынның нәрсә белән җавап бирүе ягыннан да. Мисал китерәм: без метроны Казанның Авиатөзелеш районына китергәч, андагы фатирларның квадрат метры бәясе шунда ук 35 меңнән 55 мең сумга кадәр артты. Шәһәр белән ил икътисады өчен бу ни дигән сүз? Димәк, бу урынга капитал килде, дигән сүз. Кредитлауның шарты шул, асылда.

Хәзер бездән барысы да арендага техника, җиһазлар, тоннель бөҗралары сорый – шул ук Түбән Новгород та, Красноярск та. Чөнки үзебез җитештерәбез дә. «Казметрострой»ның алдагы унбиш елга җитәрлек эше бар. Планлаштырган кадәрне төзергә гомер генә җитсен иде, дим кайчак. Бүген мин бу участокның гына түгел, ә икенчесенең дә сафка тапшырылу графигын яхшы беләм, чөнки метроның дәвамын проектлау белән дә шөгыльләнәбез. Тирә-як

> Геллер мине гел мондый сүзләр белән каршылый: **«Дөньядагы иң кыска метрога – Казан метросына сәлам бирдек!»** Мин аны гел төзәтеп куям: «Дөньядагы иң яшь метрога!»

төбәкләрдә тагын кем шушылай эшли? Бер генә тармак та иртәгәге көнгә нәрсә буласын анык белми. Шуңа да мин Татарстанга килүемне бәхет дип исәплим.

КУЫП ТОТАБЫЗ ДА УЗЫП КИТӘБЕЗ

– Ә сез Казаннан тәкъдим килмәсә, БАМны ташлап киткән булыр идегезме?

– БАМнан без Саяно-Шушенскоеда ГЭС төзеклэндерү өчен кузгалырга тора идек. Әле ул чакта, БАМ да гамәлгә куючы алышынгач, нинди төзелеш җәелеп китәсен белми идек. Хәзер анда – Северомуйск тоннеле, Кодар, Кузнецов, Байкал тоннельләре. Соңгысын яңарак кына сафка тапшырдылар. Боларны ник сөйлим диярсез. Ә менә нигә: «Казметрострой»да Северомуйск тоннеленең һәр сантиметрын диярлек белгән кешеләр эшли. Без ул тоннельне уздык. Гаять катлаулы юл булды ул. Иң яңа җиһазларга заказ бирелгән иде: японнардан, америкалы-

лардан, канадлылардан, немецлардан, французлардан, финнардан, шведлардан китерттеләр. Ул чорда дөньяда нинди иң яңа технология бар, барысы да тупланды. Безнең һәр бистәдә «немец» кунакханәләре бар иде, анда немецлар яшәде. Шулай ук – «япон кунакханәсе», «Америка кунакханәсе»... Аларда шул илләрнең белгечләре торды. Акрынлап бу БАМ га да үтеп керде, шуннан соң инде – гомумән метро төзелеше тармагына.

КАЗАНГА – БӨТЕНЛӘЙГӘ

– Сез ярты гомерегезне диярлек Казанда эшлисез. Шәһәрне ничек кабул итәсез – эш урыны итепме, әллә инде бөтенләйгә шушында төпләнгән яшәү урыны буларакмы?

– Сез дөрес әйтәсез, Казанга – бөтенләйгә... Мин Казанның туган шәһәремә әверелүен шактыйдан тоеп яшим. Югыйсә, 1996 елда килеп урнашканчы, монда бер тапкыр да булганым юк иде. Әмма безнең тамырлар – Татарстаннан. Өченче буында. Әтиемнең туганнары чыгышы буенча – Шәмәрдәннән. Алар Идел буендагы ачлык елларында күченеп киткән. Анда хәзер дә туган-тумача яши. Аларда кунак булганым да бар. Алар миңа: «Син безнеке!» – диләр.

Быел минем тормышымда әһәмиятле дата – юбилей. Әмма бу юбилей санын атарга да курками, миңа, чыннан да, шулкадәр яшь бармы икән?!

Бу яшендәге әти-әниләремне исемә төшерәм. Әтиемне... Ул мин хәзер килеп җиткән яшьтә инде бик олы кеше булып күренә иде. Мин үзем соң туган бала – әтигә 37 яшь булган. Аның кулында төшкән фото сакланып калган, ул сурәттә әти хәрби киемнән. Сугыштан соң инде ун ел узган булса да, юньлерәк киемсалымнан барыбер шул сугыш формасы булган, күрәсең. Ул сугышны башыннан азагынача сапёр булып узган – 1940 елдан 1946 елга кадәр. Ходайның биргәненә шөкер – исән калган. Өч баласын үзе тәрбияләп үстергән. Без барыбыз да – күпер салучылар, тоннель казучылар, бөтен гаиләбез, диюем. Әнием 1941 елда Семипалатинск юл төзелеше техникумын тәмамлаган. Гурьев каласына (хәзерге Атырау – **Ред. иск.**) эшкә җибәрелгән. Ягъни Казахстанга. Әтинең үлеменнән соң, әни ундүрт ел буена биредә, минем белән яшәде. Төп бурычым – ак ипи алырга онытмау иде. Балык әзерләргә дә ярамады. Ялгышып та. Гурьевта алар балыктан башка берни күрмәгән, аны ашый-ашый тәмам гарык булган. «Мин балыкны инде үз гомеремә җитәрлек ашадым!» – дия иде әни. Ак ипине бик яратты, сугыш вакытында андыйны күрмәгәннәр бит.

ЯШӘВЕН КАЗАНДА ЯШӘРБЕЗ, Ә ЭШЛӘВЕН – БӨТЕН ҖИРДӘ ДӘ

Казанда әти-әнием җирләнгән, монда минем балаларым яши, үзем яшим һәм эшлим. Тагын нәрсә кирәк?

2005 елда, метроның беренче линиясен эшләтеп җибәргәндә, без Казанның меңьеллыгына алдыбызга куйган бурычны үтәдек, дип куандык. Инде шуның белән эш бетәр дип, үзебезне тынычландырдык. Илдә авыр вакытлар иде бит, ә метро ул – бик кыйммәтле проект. Башка инде тормышыбызда Казан метросы булмас, дип фаразладык...

2007 елда «Пирамида»да метро төзелешенең ун еллыгын билгеләп үттек. Мин сәхнәдән шундый сүзләр әйттем: «Дуслар, яшәвен без Казанда яшәрбез, ә эшләвен – бөтен җирдә дә. Кая гына чакырсалар да!» Шулчакта без китмәскә дигән карарга килдек. Казан – яхшы шәһәр, аны тагын да үстерергә кирәк. Девизыбыз шундый: «Казаныбыз уңайлы булсын өчен тырышабыз!» Казан барыбыз өчен дә туган шәһәргә әверелде.

БЕРЕНЧЕ ЛИНИЯГӘ «ЧУМАБЫЗ»

– Бүген Казан метро төзелешендә нинди яңалыклар бар?

– Без хәзер «Фучик» станциясеннән метрополитенның беренче линиясенә «чумабыз». Аны узарга кирәк. Анда нибары алтмыш метр. Без бу линиядә юл ачу эшләре комплексын төгәлләп киләбез.

– Димәк, бер линия икенчесе астыннан уза булып чыга?

– Әйе. Әмма метрополитенның сак зонасы бар әле. Анда рөхсәтсез-нисез бер генә кош та

Төзелеш эшләре программасын әзерләү һәм гамәлгә кертү. Чит ил белгечләре. 2000–2001 еллар.

очып уза һәм килеп куна алмый. Без бу юнәлештә бер айга поездларны туктатып торырга рөхсәт документларын эшлибез. Чыгымнарны үзебез каплыйбыз, проектны эшләгәндә, экономия ясарга мөмкинлек бирә торган эшләр комплексын үтәп чыктык. Без бу алтмыш метрны бер ай эчендә бернинди зыянсыз узарлык технологияне һәм тизлекне кулланачакбыз. Әйе, эш технологик яктан бик катлаулы, димәк, зур җаваплылык та дигән сүз. Әмма без моны башкарып чыгачакбыз!

СТАНДАРТ БУЛМАГАН КАРАРЛАР ҺӘМ ИҖАДИ ЯКЫН КИЛҮ

– Казан метросын төзелешендә стандарт булмаган ситуация вакытында кабул итәргә туры килгән шулай ук иң стандарт булмаган карар нинди булды?

– Казанда метро төзү – ул инде үзе үк тиңсез иҗади, стандарт булмаган карар, дияр идем. Биредәге технологияләр моңарчы бер җирдә дә кулланылмаган иде. Әйтик, узу юлын машина башкарып чыга – токымны бит җир астыннан күтәрергә кирәк. Безгә кадәр токымны тәгәрмәч эзеннән йөри торган кечкенә генә вагоннарда чыгаралар иде. Ә без сигез кублы вагон куябыз да тәгәрмәч эзен киңәйтәбез. Стандарт дип әйтеп буламы бу алымны, я?

Менә тагын бер мисал: метрополитенның ике тоннелен алыйк. Технология буенча, алар арасында һәр җиде йөз метр саен кешеләр өчен аерым бер урыннар, техник тел белән әйтсәк, «сбойка»лар эшләнергә тиеш. Әгәр поезд, Алла сакласын, нинди дә булса авария килеп чыгып тукталып калса, кешеләргә аның буенча икенче тоннельгә чыгу мөмкинлеге калдырырга кирәк. Ә без ничек итәбез? Стандартта каралмаганча, без әлеге «сбойка»ны тоннельләр арасында төзелгән вентиляция камерасы яки сусаркәргеч камера белән берләштерәбез. Бу, беренчедән, процессны шактый тизләтә, икенче яктан, чыгымнар да кими төшә.

Метро төзелеше өчен кирәк булган бар нәрсәне дә без биредә, Казанда, Татарстанда җитештерәбез. Монысы әллә стандарт карармы?! Башкалар һәммәсе дә сатып ала. Ә без күбекле реагентны Химградта эшлибез. Томалау (изоляция) материалларын Алабуга ясап бирә. Махсус тимер беркеткечләрне Яр Чаллы җитештерә. Бетон катнашмалар белән блокларның технологиясен Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты эшли. Без хәтта тоннельне каплый торган боҗралар җитештерү өчен форманы да үзебездәге заводта ясадык. Беренче комплектларны Канададан сатып алдык та калганнарын инде биредә башкарып чыктык.

Безнең белгечләр, кем әйтмешли, метроны шунда ук салып чыкмады, билгеле. Бу озын-озак өйрәнүләр тиешле дәрәҗәдә тикшерүләр аша эшләнде. Кайчандыр стандарт булмаган карарлар хәзер инде – көндәлек эш процессы.

22 МИЛЛИАРД БҮЛЕНДЕ, Ә АКЧА ЮК

– Кайчан да булса бер, бәлки, катлаулы 90 нчы елларда, бу һөнәрне ник сайладым икән, дигән уегыз булдымы?

– Профессия турында сорыйсыз икән – юк. Минем эш кенәгәмдә өч кенә урын теркәлгән: «Ташметрострой», «БАМтоннельстрой» һәм «Казметрострой». Берсеннән дә киткәнем булмады, ә бары тик күчтем генә, һәм һәрчак югарырак үрләр иде ул... Шулай булгач, һөнәр сайлауда ялгыштым дигән уй булганы юк. Ә менә Казанга килеп ялгышмадыммы икән дигән уй бер йөгереп узды. Үзегез беләсез нинди еллар... Бурыч куелган, метроны төзергә кирәк. Казанның меңьеллыгы – инде борын төбендә, вакыт коточкыч тиз бара. Ә финанслау җитми. Әлбәттә, югарыдагы җитәкчеләр акча табар өчен мөмкин булганның барысын да эшләде. Казанның тарихи үзәген саклау буенча федераль программа булдырылды, өлешчә аның составына метро төзелешен дә керттеләр. Казанның меңьеллыгын уздыру программасы бар – анда да метро өчен суммалар каралган. Финанслау еш кына чыгымнарны каплау хисабына барды. Илдә сәяси режимның алышынган чагы. 1991–1992 елларда метрополитеннар дәүләт объектлары булса, соңыннан, Россия формалашкач, алар муниципаль милеккә әверелде. Метро төзелешен дә, аны карап-тәэмин итеп торуны да муниципаль хакимият үз кулына алырга тиеш. Аңлашыла, күпләр моны күтәрә алырлык хәлдә түгел иде.

Без финансларны предприятиеләрнең бурычлары өчен бюджетка зачёт буларак та алдык. Алар – болай да бурычта, нәрсә эшләтәсең инде... Бер карасаң, безгә 22 миллиард бүлеп бирделәр кебек, ә чынлыкта реаль акчалар кулда юк!

Итек басу комбинатыннан итекләр алабыз, мәсәлән, аларны юллыйбыз да цемент китертәбез. Цементны икенче бер җиргә озатабыз, аннан безгә бетон килә... Менә шундый катлаулы схемалар. Моннан тыш, республика буйлап салымнарын түләмәгән гражданнарның бурычларын җыеп алалар да аларны метро төзелешенә сарыф итәр өчен кулланалар. Безнең бухгалтерлар Мәскәүгә бара, атналар буе Минфинда утыра, ниһаять, хәл итеп, зачет алуга ирешә. Миңа ваучерлар, облигацияләр тоттырырга тырышучылар күпме булды...

Бервакыт журналда Беринг бугазы астыннан тоннель төзү проекты турында укыдым. Аляскага. Озынлыгы 84 километр диелгән. Ярдәмчем Николай Иванович Мошка кабинетка килеп керде – аңа журналны күрсәттем. Күзләре янып китте бит моның: карыйм, үзе өстәл артында утыра, ә куллары, әйтерсең, инде чемодан тоткасына үрелеп, юлга кузгалырга әзер. «Кая юл тотабыз? Команда бирүең дә җитә!» – ди бу миңа.

Юк, һөнәрне дөрес сайламаганмын дигән уйның башыма да килгәне булмады. Чөнки апаларым белән абыем сайлаган юлдан киттем. Без барыбыз да Новосибирскиның тимер юл транспорты инженерлары институтын тәмамладык, «Күперләр белән тоннельләр» факультетын. Бары тик төрле елларда гына. Апам Нурия – күперләр салучы, ә абыем белән икебез – тоннель эше осталары.

Институттан соң, мин ике ел дәвамында Хабаровск өлкәсендә БАМның тимер юл гаскәрләрендә хезмәт иттем. Тимер юл күперләре төзедем, шуннан соң Ташкентка юл тоттым, метро төзелешендә эшләдем. Ташкентта миңа берәү әйтте: «Рәхимов, син – милли кадр түгел, димәк, монда перспективаларың юк». Нишләдемме? 1986 елда чемоданымны күтәрдем дә БАМга чыгып киттем. Инде ил таркала башлаган еллар иде ул: Рязань – русларга, Казан – татарларга, дигәндәй. Анда мин иң түбәннән – нульдән башладым, тау мастерыннан. Ике ел эчендә тоннель отрядларының генераль директоры дәрәҗәсенә үстем. Миңа ул чакта 31 яшь иде.

«БЕЗГӘ ТӨРЛЕСЕ КИРӘК. ТӘРБИЯЛӘ, ӨЙРӘТ!»

– Яшь инженерларга, үзегезнең эш тәҗрибәгезгә таянып, нинди төп эш принцибын яки кагыйдәсен сеңдерер идегез?

– Төп принципны миңа үз остазым – дөнья дәрәҗәсендә билгеле тоннельче Владимир Асланбәк улы Бессолов сеңдереп калдырды. Ул БАМда тоннель төзелеше башлыгы иде, аннан соң «Трансстрой» корпорациясенең җитәкчесе булды. Һәрчак кабатлап килде:

«Җаваплылык йөге, проблемалар авырлыгы астында бераз гына биленңне бөгәргә дә ярый, әмма – бераз гына!» Тагын бер кагыйдәне аның кул астында баш инженер булып эшләгәндә үзләштердем. Кешенең анкетасын карыйм да болай дим: «Юк, бу кеше минем таләпләргә туры килми, белеме җитәрлек дәрәҗәдә түгел, фәлән-фәлән яктан ярап бетми...» Ә Владимир Асланбәкович миңа менә нинди җавап кайтара иде: «Безгә төрлесе кирәк. Тәрбиялә! Өйрәт!» Мин аның бу сүзләрен каныма сеңдердем: безгә төрлесе кирәк!

«ЕГЕТЛӘР, ТЕЛӘГӘН ҖИРЕГЕЗГӘ КИТӘ АЛАСЫЗ, ӘММА БЕРГӘ-БЕРГӘ БАРЫБЕР ЯХШЫРАК!»

– Авыр чакларда, эш хакын вакытында түләмәгәндә, төзелеш өчен акчалар булмаганда, кешеләрне рухландырыр өчен нинди сүзләр таптыгыз?

– Мин үзем белән эшләгән кешеләрне җаваплылыкка өйрәттем. Алар белән бергә тулай торакта яшәдем. Беренче фатирымны алгач, анда җиде кеше бергә тордык. Чөнки башкаларның әле фатирлары юк иде. Әгәр яхшырак фатир алсам, булганын чиратта торучыларга тапшырдым.

Менә шулай итеп рухландырдым һәм ышандырдым. «Егетләр, теләгән җирегезгә китә аласыз, әмма кайдадыр яхшырак булмаячак. Нәкъ менә монда бергә-бергә барыбер яхшырак! Бар да әйбәт булыр, мин сезгә моны вәгъдә итәм».

БАМда да эшнең тукталып торган чаклары булгалады. Мин андый вакытта, җир астына төшеп, мәсьәләнең ничек торганын тыныч кына аңлатып бирә идем. Артык кызып киткәннәр дә була, аларга: «Әгәр сиңа монда ошамый икән, ошый торган урынга бар. Юк акча, мин сиңа эш хакын хәзер берничек тә түли алмыйм. Әмма мин ул акчаны табам һәм кулыңа тоттырам, син кешеләрне генә котыртма, болгатма, чыгып кит, яме!» Шул сүзләрдән соң гадәттә тынычланалар иде.

Шулай берсендә кабинетыма балалар бакчасы мөдире килеп керде (бакчаны безнең отряд тәэмин итә). Болай ди: «Иртәгә мин балаларны кабул итә алмыйм. Аларны ашатыр ризык юк». «Иртәгә мин команда бирәчәкмен, сезгә таңнан дуңгыз ите китерерләр», – дим. «Балаларга дуңгыз итен ашатырга ярамый, ул артык майлы», – дип, авыр сулый мөдир. «Алай булгач, утырыгыз да маен аерыгыз! Ул арада балыкчылар бригадасына балык тотып китерергә кушармын!» – дим. «Балаларга балык ярамый, балыкта кылчык бар», – дип, тагын да авыррак сулый бу. «Димәк, утырып, балыкның да кылчыкларын чистартып, итен аерып алырга туры килә инде, җаныйларым», – дим җавапка. Ник мин аның белән шулай авыз суымны корытып утырдыммы? Югыйсә минем турыдан-туры вазифама карамый да кебек, чыгар да җибәр... Әмма, юк, карый, чөнки иртәгә баласын бакчага илтә алмыйча, берәр әни эшенә килми кала икән, димәк, безнең дә эш тукталып калачак, дигән сүз. Бөтен нәрсә үзара бәйләнгән.

Без үзебездә теплица төзедек. 8 мартта хатын-кызларга үзебез үстергән лаләләрне бүләк иттек. Урамда – чатнама суык, буран, ә безнең туташлар белән ханымнар, газетага төрелгән лалә чәчәкләрен тун асларына яшереп, яхшы кәеф белән өйләренә таралыша... Февраль аенда ук кыярларыбыз өлгерә, сатуга чыгарабыз... Спартакиадалар уздырабыз: йөзү, чаңгы,

мини-футбол, волейбол... Ике көн ял арасында йөгереп тә, йөзеп тә тәмам кинәнә аласың, ә аннары өйгә шундый эчке ләззәт, тантана тойгысы белән кайтасың, әле грамота белән бүләкләр дә күтәреп... Тагын нәрсә кирәк?! Барыбыз да – бергә, команда белән, иң зур мотивация әнә шул!

«ИСӘНМЕСЕЗ, МИН – РӘХИМОВ, МИНЕ ӨЙГӘ КАЙТЫРЫП КУЯРГА КИРӘК, МАШИНА ТАБЫГЫЗ!»

– Җитәкче булып тумыйлар, ә җитлегәләр, өлгерәләр, дип әйтәләр. Сез бу юлны ничек уздыгыз? Сезнең өчен кем үрнәк булды?

– Әтием гомер буе җитәкче булды – юл тресты белән идарә итте. Бөтен балачагым аның УАЗигында узды, эшендә ашый да, эчә дә, йоклый да идем. Планёркаларда да утырам. Беренче классны тәмамлагач, баш инженер улы белән икебезне 250 километр ераклыктагы пионер лагерена җибәрделәр. Иртәгә смена тәмамлана, әти безне килеп алырга тиеш. Ә безгә бер көн алдан әйтәләр: «Лагерь бүген ябыла, әйберләрегезне җыегыз, сезне кая илтергә?»

«ДЭУ-546га илтегез», – дим боларга. Беренче класста мин моны каян белгәнмендер?! Әтинең эш урыны – ДЭУ-547, әмма анда барырга бик ерак, ә якында гына – ДЭУ-546. Безне шунда илттеләр, ә анда планёрка бара. Мин бит планёркаларны күргән кеше, барып кердем дә: «Исәнмесез, мин – Рәхимов, мине өйгә кайтарып куярга кирәк, машина табыгыз!» – дидем.

Таптылар бит, төн уртасында 250 километр дип тормадылар, кайтардылар. Өй янында төшереп калдырдылар. Бу хәлне хәзер дә көлешеп искә алабыз.

АКЧА ШУНДА УК КҮП БУЛМЫЙ УЛ

– Яшь белгечләр белән эшләгәндә иң кыены нәрсә?

– Эшкә җәлеп итү. Монда эшли башлаганыма тиздән утыз ел була, ә кеше юк та юк. Инде өйрәттек тә, укыттык та... Менә, мәсәлән, Дәрвишләр бистәсендәге көллиятне генә алыйк. Аны тәмамлаучылар безнең заводта эшләргә әзер булып чыга – лаборантлар, осталар сыйфатында... Ел дәвамында без чыгарылыш төркемен җәлеп итәбез дә аларны эшкә кертеп җибәрәбез. Бездә практика узалар, ашатабыз, эчертәбез, акчасын да өстәп түлибез... Инде чыгарылыштан соң, эшкә урнаштыру вакыты килеп җитә, безгә килергә әзер бер (!) яшь белгеч бар булып чыга. Ә бит төркемдә 50 ләп кеше укып чыга. Шуларның 17 се: «Таксист булып урнашам», – диде. Яртысы сату буенча менеджер булып китәчәген белдерде. Кемдер «доставка»да эшләргә җыена. Кайсынадыр әле тагын бер урында шунда ук кулына 60 мең вәгъдә иткәннәр...

Парадокс! Аңлатырга тырышабыз: акча шунда ук, килеп урнашканнан соң ук күп булмый ул. Башта һөнәрне үзләштерергә кирәк, эшкә өйрәнергә. Без дә эшли башлаган гына дәвердә әллә нинди зур акчалар алмадык.

ТӨЗҮЧЕЛӘРНЕҢ БУЛАЧАК ЭЛИТАСЫ!

– Шулай да, «Казметрострой»га яшьләр барыбер бара бит, килгән яшьләр сезне нәрсә белән куандыра?

– Мин күбесен инде танымыйм да. Димәк, алар эшчеләр составында урнашып өлгергән, дигән сүз. Бу аеруча геодезия хезмәтендә аермачык күренә. Инженерларның участок хезмәте, сменаларның линия башлыклары, тау осталары бигрәк тә куандыра. Бер ай элек мин Санкт-Петербург тау университетын тәмамлаган бер егетнең гаризасын бик шатланып кабул иттем. Ул әле студент вакытында ук метрополитенда эшләп алырга өлгергән. Күпмегә калырсың икән син бездә, егет, дип уйлап куйдым. Кала алса, эшкә кереп китсә, бәлкәй генә бер бүлмәле фатирны тәкъдим итәчәкмен – резервта бар безнең берәү. Чыгымнары артык күп булмасын, кызыксынуы тагын да артсын, кулга кергән акчасы яшәүгә генә китеп бармасын, бераз аның тәмен тойсын өчен, диюем.

Республика Рәисе белән соңгы очрашуларның берсендә аңа яшь метро төзүчеләрне күрсәттек. Утызлап кеше – егетләр дә, кызлар да бар. «Рөстәм Нургалиевич, менә алар, исегездә калдырыгыз, төзүчеләрнең булачак элитасы шушы!» – дим. «Алар өчен нәрсә сорыйсың?» – ди Рәис шунда ук. «Социаль ипотека булдырыгыз, гаилә корып, тормыш алып барасылары бар», – дим.

Ул шунда ук хуплады. Менә хәзер шул мәсьәлә белән шөгыльләнәбез.

ШӘҺӘРНЕҢ ЯҢА ЙӨЗЕН БУЛДЫРГАН КОМАНДА

– Сезнең карашка, «Казметрострой» командасының республика тарихына керткән өлеше ни дәрәҗәдә?

– Бу команда шәһәрнең яңа йөзен булдырды! Дөресен генә әйткәндә, без моңа иң баш-

та үзебез дә ышанмаган идек хәтта. 1997 елның 11 мартында мин Казанга килдем. Ә инде 14 апрельдә Казанда үземнең БАМнан килгән беренче командамны каршы алдым. Җәйгә безгә эшчеләр белән тулай торакта торырга туры килде. Тоннельне уза ала торган комплекс сатып алдык. Берничә мәртәбә Торонтога заводка очтык, анда ул комплексны эшләп бирделәр. Контракт төзедек.

Саратовның «Гидроспецстрой» оешмасы булышты. Түбән Кама белән «Татнефть», Минтимер Шәрипович тәкъдиме белән, берәр миллион доллар төзелешкә бүлеп бирергә тиеш булдылар...

«Сөембикә» дигән беренче машина инде Казанга килеп җитте, монтажлана башлады. Ничек алып кайтуны сөйли башласаң – аерым мәкалә язардай тарих. Аны монтажлый торган кранны ничек кайтарганыбызны да үзебез генә беләбез! Махсус поезд, ул габаритлары белән бөтенләй башка, әмма аны оештырдылар. Тимер юлдан, махсус шартлар һәм таләпләрне үтәп, күзәтү астында барды: алдан 15 вагон каплап алынган, арттан – 15 вагон. Бу операция белән Казан тимер юл вокзалы бүлекчәсенең башлыгы шәхсән үзе җитәкчелек итте.

Ә нинди монтажчылар! Алар шул алагаем олы кран белән шырпы тартмасыннан тагын да бәләкәйрәк тартманы тартып чыгарырга сәләтле иде. Миллиметрга кадәр исәпләнгән төгәл хәрәкәтләр! Менә шундый команда булдырды Казанның яңа йөзен!

1997 елның 27 августында, беренче субайны салганда, Минтимер Шәрипович әйтә: «Акчаның беркайчан да булмавы бигрәк шәп, бер карасаң, болай без Казанны бозмадык. Тарихи үзәген ничек булган, шулай саклап кала алдык!»

ЯШИСЕ КИЛӘ ТОРГАН ШӘҺӘР

– Ә сез Казанны тагын 20 елдан соң ничек күрәсез?

– 20 елдан соң Казан илебезнең өченче башкаласы дәрәҗәсен горур йөртә торган заманча гигант шәһәр булачак. Сез карагыз, юллар, мәктәпләр ничек төзелә бездә! Быел гына 1200 балага исәпләнгән биш мәктәп ачылды. Аларның бит барысы да федераль акчаларга төзелми. Хәтта республика акчаларына да түгел. Әмма безнең республикабыз лидеры һәрчак Татарстан өчен тиешле булган алтын урталыкны табарга тырыша, таба да. Татарстан 38 федераль программада катнаша! Кайсыларында – 50 гә 50 нисбәтендә. Кайсыларында – башка пропорцияләрдә. Уңайлы мохит, эш җитештерүчәнлеген арттыру, авыл тормышын, инфраструктураны яхшырту, Иделне сәламәтләндерү... Барысында да Татарстан үз өлеше белән катнаша, шул ук вакытта эшләрнең бер күләме федераль акчалар хисабына башкарылып чыга. Зөядә логистика үзәге төзелгән, ул республика белән бөтен илдәге юлларны берләштереп тора һәм биш диңгезгә чыга. Тирә-якны кайгыртулары, төзекләндереп, карап торулары шунда ук күзгә ташлана. Озакламый Иделдә искиткеч зур яр буе пәйда булачак!

Бездә дүрт тоннель казый торган комплекс бар – дүрт «хатын-кыз». Нәкъ менә алар эшчеләрне җир асты буйлап алып бара һәм саклап килә. Католиклар дөньясында җир астында эшләүчеләрне саклаучы булып Изге Барбара санала. Бер генә тоннель казый торган комплекс та заводтан үзенә туры килә торган хатын-кыз исемен алмыйча чыкмый – бу традиция. Безнең машиналарның исемнәре – Татарстан өчен кадерле булган милли исемнәр: Сөембикә, Алтынчәч, Айсылу һәм Ләйсән.

Яхшы шартларга тиз ияләшәсең, ә менә кайда да булса барып кайтсаң, шунда ук чагыштырырга мөмкинлек туа. Хәтта юллардан гына да күреп була: безнеке ничек, ә Татарстаннан чыккач, нинди караусыз, чокыр-чакырлар...

МИН – ӨЕМДӘ

37 ел дәвамында җитәкче булып эшлим һәм 37 ел буена юлда йөрим. Җир шарын машинада инде 37 мәртәбә әйләнеп чыктым, ахрысы. Йоклап китсәм дә, уянып торсам да, машина йөртүчемнән: «Без кайда?» – дип сорамыйм. Күреп торам – юллардан, басу-кырлардан, таралып утырган авыл-бистәләрдән, сорылыктан, моңсулыктан... Ә аннары без Татарстанга килеп керәбез. Кайсы гына якка күз ташлама – тәртип һәм ямь. Күз карашын иркәләүдән үк, йөрәкне җылытуыннан ук тоеп аласың: мин – өемдә.

«ГОСУДАРЕВ АМБАР» ОНЫ: ТАТАРСТАННЫҢ АЛТЫН КЫРЛАРЫННАН – СЕЗНЕҢ ӨСТӘЛГӘ

Чүпрәле районындагы Борындык бистәсе янәшәсендәге алтынсу басулар арасында чын икмәк шәһәре – «Государев амбар» ҖЧҖ җәйрәп ята. Биредә ашлык, он һәм хезмәт исе аңкый. Сиксән еллык тарихы булган предприятие икмәккә һәм традицияләргә хөрмәт саклап яши.

ХӘРБИ БАРАКЛАРДАН – ШВЕЙЦАРИЯ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНӘ

«Государев амбар» предприятиесе тарихы 1942 елда, немец хәрби әсирләре бу җирләрдә Юдинодан Ульяновскига кадәр тимер юл төзегәндә башлана. Юл белән бергә кечкенә генә ашлык кабул итү пункты – Борындык элеваторы да салына. Ул чакта барысы да бик гади: такта складлар, кул үлчәве, ашлыкны атларда китерәләр. Электр булмый, әмма икмәк һәрвакыт кирәк, дигән инану була.

2017 елда элеваторга «Государев амбар» исеме бирелә.

– «Дәүләт амбары» исемен очраклы гына сайламадык, – дип сөйли предприятие директоры Васыйл Вазыйх улы Сәлахов. – Бер яктан караганда, байлык саклау символы булган амбар, икенче яктан – дәүләт: анда икмәк һәрвакыт алтын резерв, безнең уртак байлыгыбыз саналган.

ҖИРГӘ ТУГРЫ ДИРЕКТОР

Васыйл Сәлахов предприятиене 2013 елдан бирле җитәкли. Аның әйтүенчә, элеватор тарихында директор вазыйфасында ике-өч елдан артык эшләүче юк диярлек.

– Ә менә мин бер урында озак эшләгән ике директорның берсе, – дип елмая ул. – Бәлки, игенчеләр гаиләсеннән булгангадыр. Җирне ярату һәм хөрмәтләү каныма сеңгән.

Белеме буенча агроном, Каратун ашлык кабул итү предприятиесе директорыннан гаять зур комплекс җитәкчесенә кадәр хезмәт юлы үткән, ашлыкның сыйфатыннан алып онны төргәкләүгә кадәр – һәр этапны үзе контрольдә тота. Предприятие аның җитәкчелегендә тулысынча диярлек үзгәргән: складлар, юллар, киптергечләр, төргәкләү линияләре – барысы да яңартылган.

21 ГЕКТАРЛЫ ИКМӘК ШӘҺӘРЕ

Бүген «Государев амбар» – 21 гектар мәйдан билгән югары автоматлаштырылган заманча комплекс ул. Аның составына 22 ашлык склады, 171 мең

Фото: «Государев амбар» ҖЧҖ нән алынды. РЕКЛАМА

тонна сыйдырышлы элеватор, тегермән, катнаш азык җитештерүе, механика цехлары, газ хуҗалыгы, тулай торак, ашханә керә. Биредә һәрнәрсә Швейцария сәгате төгәллегендә эшли, һәм бу очраклы түгел: предприятиегә җиһазлар дөньяның әйдәп баручы компанияләреннән, шул исәптән BUHLER AG тан кайтартылган.

Бүген предприятиедә көн саен югары сортлы 280-290 тонна он җитештерелә. «Государев амбар» оны Татарстаннан читтә дә яхшы мәгълүм: аны Санкт-Петербургтан Ерак Көнчыгышка кадәр – бөтен Россия буйлап җибәрәләр. Моннан өч ел элек биредә онны икешәр килолы итеп төргәкли башлыйлар, һәм ихтыяҗ гаять зур булып чыга – татарстанлылар «үзләренең» вакыт белән сыналган онын аеруча үз итә.

– Безнең он чиста, өстәмәләрсез, – дип ышандыра Сәлахов. – Без ашлык кабул итүдән алып әзер продукцияне төяп җибәрүгә кадәр – һәр этапны катгый контрольдә тотабыз. Лаборатория бертуктаусыз эшли: чималны, он тарттыру һәм әзер продукция сыйфатын тикшерә. Яхшы икмәк яхшы ашлыктан башлана бит. Он җитештергәндә күп параметрлар исәпкә алына: икмәкнең сыйфатына турыдан-туры тәэсир итә торган он төшү саны, аклыгы, җилемсә дәрәҗәсенең 23 проценттан түбәнрәк, ә дымлылыкның 14 проценттан югарырак булмавы. Онның аклыгы бодайның сортына, һава торышына һәм үстерү шартларына бәйле. Нигездә без бары тик Татарстан ашлыгы белән генә эшлибез, аны төрле холдинглардан алабыз. Фермерлар исә башка күрше төбәкләрдән үз ашлыгын һаман активрак китерә бара. Предприятиедә аны кабул итәләр, киптерәләр һәм җентекләп чистарталар – һәр партия катгый сыйфат стандартларына тәңгәл килергә тиеш.

Кул хезмәте әкренләп заманча технологияләр белән алыштырыла. Периметр буенча контроль һәм махсус программалардан файдаланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлтелгән системалар кертелгән. Бүген онның чыгышы 75 процентны тәшкил итә – бу югары күрсәткеч: бер тонна ашлыктан предприятие 750 килограмм әзер он ала.

ОН ГЫНА ТҮГЕЛ, КАТНАШ АЗЫК ТА

Оннан тыш, предприятие кошлар, дуңгызлар, мөгезле эре терлек өчен 80 төрдән артыграк катнаш азык һәм премикс та җитештерә. Хайваннарның һәр төре өчен биредә махсус азык эшләнә, барысы да диярлек гранулалланган. Гранула составы һәм үлчәме хайванның яшен, тәүлек дәвамында туклану нормасын һәм кош яки терлекнең төрен исәпкә алып сайлана. Һәр рецептура катгый үтәлә, бу продукция сыйфатының тотрыклылыгын гарантияли.

Болар барысы да 2005 елда җитештерүчәнлеге елына 120 тонналы заманча катнаш азык заводы төзегәннән һәм анда BUHLER AG җиһазлары куелганнан соң тормышка аша.

– Бүген безнең 40 рецептурабыз бар, – дип сөйли директор. – Без Татарстанның иң зур хуҗалыклары – Питрәч бройлер фабрикалары, YARATELLE, «Авангард» дуңгызчылык комплексы, башка предприятиеләр белән хезмәттәшлек итәбез.

ҮТКӘНГӘ ХӨРМӘТ ЙӨЗЕННӘН ТУГАН ЗАМАНЧАЛЫК

2013 елда Васыйл Сәлахов килгәч, күпнәрсәне өр-яңадан башларга туры килә. Юллар яңартыла, җир өстендәге 22 складка капиталь ремонт ясала – ишекләре дә алыштырыла, түбәләре дә тулысынча яңадан ябыла. Моннан тыш, ашлык кабул итү нокталары арттырыла – хәзер алар ундүртләп. Һәр пункт конкрет культурага, ашлыкның сорты, дымлылыгы һәм классына исәпләнгән. Бодай өчен 5-6 кабул итү пункты тәгаенләнгән: 3, 4, 5 нче класслы, дымлы һәм коры ашлык. Барлык партияләр аерым кабул ителә һәм исәпләнә. Әгәр элек үлчәүчеләр бөтен мәгълүматны кулдан теркәсә, бүген инде процесс тулысынча автоматлаштырылган. Машиналар махсус карточка буенча керә, система исә бөтен мәгълүматны үзе терки һәм контрольдә тота. Элеккеләре урынына куелган яңа Америка киптергечләре, энергия һәм вакытны янга калдырып, сәгатенә 100 тонна ашлык эшкәртергә сәләтле.

Бүген биредә 265 кеше хезмәт куя, һәм аларның һәркайсының икмәккә бәйле үз тарихы, үз язмышы бар. Ветераннарның берсе, инде 1948 елда ук элеваторда баш инженер булып эшләгән Иван Михайлович Маскиев хатирәләрен яңарта: «Башлаганда – атлар һәм үлчәү генә, бернинди машина юк иде. Хәзер исә – автомат, экраннар, техника», – ди.

– Без күп өйрәнәбез. Мәскәү һәм Петербургтагы, Гарәп Әмирлекләрендәге предприятиеләрдә булабыз, – дип санап китә Васыйл Вазыйх улы. – Нәрсәгә ихтыяҗ зур булуны ачыклыйбыз. Шул рәвешле, онны 1-2 килолап төргәкләү идеясенә килдек – Италиядән җиһазлар сатып алдык. Хәзер ай саен 500-600 тонна төргәкле он сатабыз, аны кибетләргә үзебез таратабыз – моның өчен фура тотабыз.

Предприятиенең үзенең кечкенә икмәк пешерү цехы да бар: монда хезмәткәрләр өчен икмәк пешерәләр, онны, яңа рецептураларны сынийлар.

СЫЙФАТЛЫ ОН ҖИРДӘН БАШЛАНА

– Өйдә гаиләм үзебезнең оннан гына пешерә, – ди директор. – «Государев амбар» онынннан пешерелгән икмәкне бер тапкыр авыз иткән кеше, башка онныкын инде ашамый.

Үзе җитәкчелек иткән дәвердә Васыйл Сәлахов предприятиене республикада иң алдынгы һәм абруйлыларның берсенә әйләндергән. Аның хезмәте, һөнәрмәндлеге һәм эшкә тугрылыгы лаеклы бәяләнгән: 2023 елда ул, Татарстан агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен, «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән. Аңа шулай ук Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исемнәре бирелгән – гомерен Ватанына хезмәткә багышлаган кешегә зур ихтирам билгесе бу.

– Сыйфатлы он җирдән башлана, – дип исәпли ул. – Без туфракны кайгырта торган сыналган хуҗалыклар белән генә эшлибез. Башакны күрәсең дә, икмәк буласын аңлыйсың. Калганы – кул һәм йөрәк эше.

«Государев амбар» шулай, үткәнне хөрмәтләп, җиргә таянып, Россиядә гомер-гомергә иң кыйммәтле продукт саналган икмәкне ярытып яши.

ЭКОРАЙОН: ТАТАРСТАН МӘРКӘЗЕНЕҢ ЯҢА ҖӘЛЕП ИТҮ НОКТАСЫ

Казан үзәге биеккә ашкан һәм үскән арада, шәһәрлеләрне торган саен күбрәк саф һавага һәм яшеллеккә бай булган урыннар җәлеп итә. Киров районы, тын гына шәһәр чите, бүген чын мәгънәсендә Казанның перспективалы районнарының берсенә әверелеп бара. Бу – шәһәрдән чыгып китмичә генә, табигатьтә яшәү мөмкинлеге.

ДАЧА ҺӘМ ЗАВОДЛАРДАН – «ШӘҺӘРГӘ 15 МИНУТ ЭЧЕНДӘ»

Биредә, нарат урманнары уратып алган җирлектә, кайчандыр дачалар белән сәламәтләндерү лагерьлары урнашкан булса, хәзер исә шәһәр мохитенең бөтенләй яңа төре формалашып килә. Территорияне яңарту буенча кабул ителгән һәм расланган программа буенча, «Экорайон» дигән исем алган районның 700 гектардан артыграк мәйданы «шәһәргә 15 минут эчендә» принцибына нигезләнеп корылачак. Димәк, көнкүреш өчен кирәкле бөтен нәрсә дә янәшәдә генә, дигән сүз: балалар бакчасы да, мәктәп тә, парклар да, кибетләр дә, спорт учреждениеләре дә.

Территориянең яңарышы 2025 елның августында башланды. Нәкъ менә шушы вакытта республикада 3,47 млрд сумга исәпләнгән инфраструктура буенча федераль кредит хупланды, димәк, бу акчалар ТКХ га, аны модернизацияләүгә китәчәк. Алар шулай ук канализациянең магистраль челтәрләрен төзү өчен дә исәпләнгән. Параллель рәвештә Горький шоссесы төзекләндерелде, димәк, хәзер үзәккә барып җитү шәһәрдәге кайбер йокы районнары белән чагыштырганда тизрәк тә.

ҮЗӘКТӘН ЧИТТӘГЕ ПРЕМИУМ

Соңгы елларның тенденциясе күзгә күренеп тора: премиум дәрәҗәсендәге торак проектлар «алтын мильләр» белән генә чикләнми. Бүгенге көндә статус урам индексы белән түгел, ә торакны торгызучылар тудырган мохит һәм тәрәзәдән күренгән манзара белән бәяләнә. Шулай ук саф һава сулау мөмкинлеге дә – беренчел урында.

Киров районы потенциалына ышаныч күрсәткән девелоперларның берсе – GloraX федераль компания. Нәкъ менә биредә, нарат урманы йөрәгендә һәм Идел янәшәсендә, компания GloraX Premium Экосити торак проектын торгыза да. Бу проект кабатланмас табигый мохит белән югары дәрәҗәдәге инфраструктураны берләштерә.

ТАБИГАТЬ ИЛҺАМЛАНДЫРГАН АРХИТЕКТУРА

GloraX Premium Экосити архитектурасы «җиңеллек һәм яктылык» идеясе нигезендә торгызыла. Биек булмаган корпуслары камера атмосферасы тудыра, ә түшәмнән идәнгә кадәр булган панорамалы тәрәзәләр, терраса, балконнар табигать белән интерьерны бербөтенгә берләштерә. Мультифункциональ пыялалар җәй көне эсседән яхшы саклый, кышларын җылыны чыгармый – бу экология ягына тагын бер плюс.

Әмма GloraX белгечләре «экологик проект» мәсьәләсендә, традицион күзаллаулардан китеп, тагын да алгарак карый. Биредә экология архитектура фәлсәфәсенең иң әһәмиятле өлешенә әверелә: табигый материаллар куллану ягыннан гына түгел, ә кеше белән ландшафтны үзара яраштыру җәһәтеннән дә. Утрау һәм плейхаб күздә тотылган ясалма күл, су буйлап урнашкан ял итү маршрутлары, мини-гольф кыры, теннис корты һ.б. монда яшәүчеләрне һичшиксез табигый дә, актив та булган яшәү рәвешенә күнектерәчәк. Казан өчен мохитне шулай уйлап куллана белү – әлегә сирәк һәм бик кирәкле күренеш. GloraX Premium Экосити очрагында уңайлыклар тудыру бөтенләй яңа дәрәҗәгә чыга, бу аны Мәскәү һәм Санкт-Петербург проектлары белән бер югарылыкка куя.

GloraX Premium Экосити да яшәүчеләр урман сукмакларында рәхәтләнеп йөри, саф һавада спорт белән шөгыльләнә ала, шул ук вакытта Казан Кремеленә дә... 15 минутта барып җитә. Уңайлыклар белән табигый яшәеш арасында сайлау кирәкми, яңа тормыш моделе аны табигый рәвештә безгә тәкъдим итә.

ЯШИСЕ КИЛӘ ТОРГАН РАЙОН

Инфраструктураны колачлы рәвештә яңарту, яңа юллар, мәктәпләр, төзекләндерелгән мәйданнар – болар барысы да Киров районын уңайлы һәм ямьле генә итеп калмый, ә Казанның үсешендәге стратегик әһәмиятле юнәлеш буларак та билгеле.

Инвесторлар өчен бу – перспективалы территориягә акчалар кертү урыны, димәк, тормыш уңайлыклары белән бергә торак бәясе дә үсәчәк, дигән сүз. Биредә яшәргә теләүчеләр өчен – шулай ук шәһәрдә яшәү белән беррәттән, саф һава һәм табигать шартларын берләштерү мөмкинлеге.

GloraX Premium Экосити яңа фәлсәфә символына әверелде: биредә табигать архитектура һәм төзекләндерү, яңарыш – барысы бербөтенне тәшкил итә.

Фотолар: «Мицар» СЗ» ҖЧҖ, наш.дом.рф/сервисы/каталог-новостроек/объект/66389

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр /

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Нәсимә Гайфетдинованың **ничә** оныгы бар

Юлия Пермякова тернәкләндерү үзәген **ничек** оештырган

Әлфия Закирова сугыш чорында **ничек** исән калган

«Кечкенә мәктәпнең» уңыш формуласы **нинди**

КЫТАЙ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КАЗАНДАГЫ ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛЫ СЯН БО 26 СЕНТЯБРЬДӘ КХР ТӨЗЕЛҮНЕҢ 76 ЕЛЛЫГЫ һәм Кытай белән Россия арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруның 76 еллыгы уңаеннан кабул итү тантанасы үткәрде.

«76 ел эчендә Россия белән Кытай арасындагы мөнәсәбәтләр эре державалар арасындагы дуслык үрнәге булды», – дип билгеләп үтте Генераль консул, Илләр якынаю курсын дәвам итә: Кытай россиялеләр өчен визасыз режим ачты, бу илләр арасындагы авиаэлемтәләрне киңәйтүгә исәп тотарга мөмкинлек бирә.

КАЗАНДА КАЗАХСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕН – 1990 елда Казахстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителгән көнне билгеләп үттеләр. «Казахстан тугры дуслар һәм партнёрлар тапты, – диде тантаналы кабул итүдә Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков. – Идел буе федераль округы регионнары белән тыгыз элемтәдә тору безнең икътисадый хезмәттәшлекнең ышанычлы күперләренең берсе булды». Кабул итү тантанасы казах һәм рус телләрендә «25 октябрь – Республика көне» дип язылган бәйрәм тортын бүлү белән тәмамланды.

Фото: Александр Ефремов, Татар-информ



9–10 октябрьдә Казанда узган **«КИЛӘЧӘК ОРИЕНТИРЛАРЫ» VIII ТУРИСТЛАР ФОРУМЫНДА 600 ДӘН АРТЫК КЕШЕ КАТНАШТЫ.** Чара Россиянең 37 төбәгеннән 448 туриндустрия вәкилен берләштерде. Барлыгы җиде эксперт сессиясе узды, алар кысаларында эчке туризмны, чит илләрдән керү туризмын үстерү стратегияләре, бизнесны цифрлы үзгәртеп кору һәм яңа маркетинг ысуллары, туристларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм кадрлар әзерләү, шулай ук туроператорлар һәм турагентлар эшчәнлегенең хокукый аспектлары турында фикер алыштылар.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ӘНИЛӘР

Әниләр төрле була.
Яшь һәм мәңге яшь.
Матур һәм **һәрчак матур**.
Мәрхәмәтле һәм искиткеч мәрхәмәтле.
Газиз **һәм газизләрдән газиз**.

Алар безне нинди генә булсак та ярата. Кайчакта без яратуга лаек булмаганда да. Алар безне гел көтә. Алар безне – инде үсеп беткәч тә! – барыбер кайгырта: авырмыйсыңмы дип тикшерә, дорфалыкларыбызны кичерә, өскә-башка җылы киеп йөрергә мәҗбүр итә. Әниләр, нишләтәсең. Бүген сүз алар турында.

Фото: махсус проектта катнашучылар архивыннан

«Ана даны» ордены иясе
НӘСИМӘ ГАЙФЕТДИНОВА
ТУРЫНДА

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар
өчен тернәкләндерү үзәге оештырган
ЮЛИЯ ПЕРМЯКОВА ТУРЫНДА

80 яшьлек юбилеен бәйрәм иткәндә.

Фото: Гайфетдиновлар архивыннан

ӘНИЛӘРЕБЕЗНЕҢ ӘНИСЕ

Әбиләребез исән чакта аларның кайчан да булса кинәт кенә безне ташлап китәчәге хакында уйламыйсың да. Ә инде аннары ниндидер тирән югалту хисе уяна һәм, бу кеше янында күп еллар яшәп тә, аның төрле вакыйгаларга бай озын гомере турында берни дә ваемламый калганыңа үкенә башлыйсың. Югыйсә 92 еллык гомернең сюжеты теләсә кайсы китапныкыннан да мавыктыргычрак бит...

Мария Ермакова

Аның бакыйлыкка күчкәненә инде алты ел. Һәм бу елларда аның 9 баласы белән 17 онык-оныкчыгының кадерле «баш әниләрен» искә алмаган бер генә көне дә юктыр.

Нәсимә Әмирхан кызы Гайфетдинова 92 еллык гомерендә күп кыенлык кичерде: сугыш та, ачлык та, янгын да, яңа туган кызының үлемен дә, улының үз-үзенә кул салуын да. Ул безнең зур гаиләнең яклаучысы һәм саклаучысы иде. Бик зур хуҗалык алып барды. Табигатьне һәм үзенең кече ватанын өзелеп яратты. Бәйләргә бик оста иде, һәр буш минутын шушы шөгыльгә багышлады.

БАЛАЧАК ХЫЯЛЛАРЫН СУГЫШ УРЛАГАН

Нәсимә Әмирхан кызы 1926 елның 24 июнендә Украинаның Матвеевка авылында туган. Әти-әнисе анда акча эшләргә дип туган авыллары Салкын Чишмәдән (Малмыж районы, Киров өлкәсе – **Ред. иск.**) чыгып киткән, анда аның абыйсы һәм сеңлесе туган. Күп еллар узгач, инде абыйсын да, сеңлесен дә югалткач, ул үзенең алар өчен дә яшәвен кат-кат әйтә торган була.

Нәсимәгә биш яшь тулгач, гаилә Салкын Чишмәгә әйләнеп кайта. Әмма, ни күрсеннәр, аларның туган йортлары буш түгел икән – аны авылдашлары яшерен рәвештә гыйбадәт кыла торган мәчет итеп файдалана башлаган булып чыга. Ул елларда совет хакимияте чиркәү һәм мәчетләрне юкка чыгарган, складлар һәм ашлык саклый торган урыннарга әйләндергән.

Нәсимә этисенең авылдашлары ярдәме белән янәшәдә тагын бер йорт салганнарын хәтерли – кызның балачагы да, яшьлеге дә шунда үтә.

Ул, мәсьәлә һәм тигезләмәләрне чикләвек ваткандай җиңел чишеп, мәктәптә үзенең математик зиһене белән барысын да таң калдыра. Укытучы булырга хыяллана, әмма 1940 нчы еллар балаларының барлык хыяллары да тормышка ашмый шул – сугыш комачаулый.

ГОМЕРЛЕК ТАМГА БУЛЫП КАЛГАН

Сугыш аңа унбиш яшь тулгач башлана. 1941 елның июнендә үк этисе һәм абыйсы фронтка китә. Нәсимә этисен бүтән күрми инде, ә абыйсы, исән-сау әйләнеп кайтып, авыл советы рәисе була.

Әнисе Нәсимә һәм кечкенә сеңлесе белән генә кала. Гаилә турында кайгырту

1986 ел. Җәмәгате һәм балалары арасында – 60 яшьлек юбилеен бәйрәм иткән көннәре.

1952 ел. Сулдан уңга: Нәсимә, олы кызы Фидания, каенсеңлесе.

унбиш яшьлек чандыр гына кыз җилкәсенә төшә.

Ул үзенә тиешле хезмәт көннәрен дә тутыра, икмәккә акча табу өчен урман да кисә. Ничек тә булса тамак туйдырыр өчен, аларга колхоз басуыннан өшегән бәрәңге дә җыярга туры килә. Ул елларда барысы да шулай яшәгәнлектән, Нәсимә зарланмый.

1942 һәм 1943 еллар – иң уңдырышсыз чор, халык ачлыктан бик интегә. Нәсимә исенә төшереп сөйләгәнчә, колхозчылар үз хуҗалыкларыннан натураль салым түли, хезмәт көннәре өчен нибары берничә уч ашлык ала... Ничек тә исән калу хакына, он белән тукранбаш кушып әвәләгән катнашма ашап тукланырга туры килә. Ачтан үлмәс өчен, бөтен яшүсмерләр дә олылар белән бергә җәй уртасыннан урман кисәргә китә.

1962 елның 27 декабрендә Нәсимә Әмирхан кызы Гайфетдинова – **II дәрәҗә Ана медале,** 1964 елда **I дәрәҗә Ана медале** белән бүләкләнә.

1966 елның 24 декабрендә Нәсимә Әмирхан кызына – **III дәрәҗә,** 1970 елда – **II дәрәҗә** һәм 1973 елда **I дәрәҗә «Ана даны» ордены** тапшырыла.

Ә андагы михнәт! Урман кисүчеләрнең күбесе фронтта, барлык кирәкле техника һәм атлар да сугышка армия ихтыяҗларына җибәрелгән. Шуңа күрә җәен-кышын чабата кигән хатын-кызлар, яшүсмерләр һәм картлар агач ега, ботак турый, метровкалар кисә – алардан аннары корал түтәләре ясыйлар. Болар барысы да балта һәм пычкы ярдәмендә генә башкарыла. Нократ буйлап урман агызалар, бүрәнәләрне, киптерер өчен кул белән күтәреп, биек ярга менгезеп өяләр.

– Әнинең картайганчы башында бер төере бетмәде, – дип искә ала Нәсимәнең кече кызы Фәймә Кәлимуллина. – Урман кискәндә ботак кадалды дип, искә алып сөйли иде әни.

АВЫЛНЫҢ ИҢ ОСТА ГАРМУНЧЫСЫ

Сугыштан соң Нәсимә үзенең гомерлек мәхәббәтен – авылның иң оста гармунчысы Нуретдинне очрата. Алар 1947 елда өйләнешәләр, ә берничә айдан Нуретдинны армиягә – Орёл шәһәре янындагы коры җир гаскәрләренә хезмәткә алалар. Ул авылга кабат 1952 елда гына әйләнеп кайта, өйдә аны хатыны һәм инде өч яшьлек кызы көтеп тора.

Армиядән соң Нуретдин Киров өлкәсендәге Мелетские Горки авылында «Передовая» колхозында тимерче булып эшли, гаиләсен Салкын Чишмәдән шунда күчерә. Аннары алар Никольскоега күченеп, йорт сала. Гаиләдә бер-бер артлы тагын ун бала туа, әмма 1967 елда туган кызлары исән калмый, Нәсимә бу югалтуны гомере буе бик авыр кичерә.

Башта ярлы гына түгел, бик хәерче яшиләр. Бигрәк тә – йорт салганда. Нәсимәнең кунакка киярлек күлмәге дә булмый. Бервакыт аларны туганнары туйга чакыра, һәм ул, мәҗлестә башкалардан ким булмас өчен, күршесеннән кияргә күлмәк сорап тора. Киеме бик килешле була, тик кече кызы кинәт бөтен кеше алдында: «Әни, син нигә күрше апаның күлмәген кидең?» – дип сорап куя. Нәсимә шунда ничек оялуын үлгәнче онытмый.

КОТОЧКЫЧ ЯНГЫН ХАРАП ИТӘ

Нуретдин тимерче алачыгында эшләгәндә, Нәсимә берсеннән-берсе кечерәк балаларын тәрбияли һәм хуҗалыкны алып бара: яшелчә бакчасы, абзар тулы мал-туар – барысын да ул карый. Сыер саву, мал-туар ашату, бакча утаулар арасында ул әле балаларына шәл, башлык һәм оекбашлар бәйләргә, гөлҗимеш һәм гөмбә җыярга, иренә очын-очка ялгарга һәм гаиләсен туендырырга ярдәм итәр өчен каен себеркесе хәстәрләргә дә өлгерә. Бәлә көтмәгәндә килә. 1985 елның августында гаилә печәннән кайтып кичке ашка утыргач: «Тизрәк чыгыгыз! Янабыз!» –

«Ана даны» орденын һәм Ана медален булдыру идеясе ил халкы сизелерлек кимегән вакытта – сугыш вакытында ук туа һәм күп балалы аналарны хөрмәтләү билгесе булып тора. Совет чорында орден белән тугыз һәм аннан да күбрәк бала тапкан һәм тәрбияләгән 431 мең хатын-кыз, ә Ана медале белән 13 миллион хатын-кыз бүләкләнә.

дип кычкырып, өйгә уртанчы уллары Нургаян йөгереп керә.

Коточкыч янгын бөтен хуҗалыкны юк итә. Гаиләгә Никольскоедан Малмыжга күченергә туры килә. Нәсимәгә ул вакытта 60 яшь була. Күченү аның өчен зур хәсрәткә әйләнә. Никольскоедагы газиз йортының юклыгы белән ул һич тә килешә алмый. Ел саен «үз бакчасына» бәрәңге утырта, Сабан туена һәм башка бәйрәмнәргә кайта.

НИКОЛЬСКОЕ АВЫЛЫ ШАГЫЙРӘСЕ

Бервакыт Нәсимә 8 мартта гаиләсе белән тагын Никольскоега бәйрәм концертына кайта һәм барысын да гаҗәпкә калдыра.

– Шул бәйрәм көнне Мәдәният йорты сәхнәсенә менеп, авыл турында үзе язган шигырен сөйләде ул, – дип искә ала кече кызы Фәймә. – Мин моңа бик гаҗәпләндем. Безнең гаилә бик тыныч иде, әти күп сөйләшмәде. Әни дә моңарчы кинәт җыр җырлап яки шигырь сөйләп шаккатырмады. Ә бит аңарда шагыйрьлек сәләте дә булган икән!

ҖӘЙ САЕН БЕРГӘ

Нәсимә Әмирхан кызының балаларын язмыш Россиянең төрле почмакларына тарата. Өлкәннәре – Фидания белән Нурислам – Свердловск өлкәсендә төпләнә, Фирдәүсә – Казанда фармацевт, Ринат Ханты-Мансийскида машина йөртүче булып эшли, дүрт кызы исә Малмыжда кала: Финзия – табиб, Фәйрүзә – бухгалтер, Фәридә – кондитер, Фәймә – дәүләт сатып алулары буенча белгеч.

Әмма һәр елны җәй көне 9 бала, 17 онык һәм оныкчыктан торган зур гаилә «баш әниләренең» туган көненә җыела торган була. Нәсимә әби киенергә ярата, матур күлмәкләрдән, балкып, зур гаиләсен каршылый, «Ана даны» орденын тагарга да онытмый.

– Әниебез инде безнең арада булмаса да, – диләр Нәсимәнең нәсел варислары, – хәзер дә Киров өлкәсендәге Малмыж шәһәренә, әниләребезнең әнисенең туган көнен билгеләп үтү өчен, Россиянең төрле почмакларыннан барыбыз да кайтабыз.

2006 ел. Оныклар янәшәсендә.

2011 ел. Бөек Җиңү көнен бәйрәм итү тантансында.

Фото: Юлия Пермякова архивыннан

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ИГЕЗӘКЛӘРНЕҢ ӘНИСЕ

Юлия Пермякова Казандагы Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен тернәкләндерү үзәген оештыруга бөтен көчен бирә. Бу үзәк «Яшә» дип атала. Борчулары һәм өметләре охшаш башка Казан әниләрен дә бу эшкә җәлеп итә ул. Шул рәвешле эмоция-ихтыяр өлкәсендә тайпылышлар (аутистик спектрга караган тайпылыш, аутизм, Даун синдромы) күзәтелгән балаларны тәрбияләүче әти-әниләр өчен әлеге автоном коммерциячел булмаган оешма бик әһәмиятле урынга әйләнә.

Бүгенге көндә «Яшә» – 53 үзенчәлекле бала өчен җылы йорт. Иң бәләкәйләргә ул балалар бакчасын алмаштырган. Биредә баласын калдырып, әти-әниләр тыныч күңел белән эшкә бара ала, чөнки сабыйларының ышанычлы кулларда икәненә ышана алар. Өлкәнрәк балаларга бу – озынайтылган көн группасы, мәктәптән соң, алар монда шөгыльләнүләрен дәвам итә.

ТӨП МАКСАТ – КИЛӘЧӘК

Үзәктә укыту-тәрбиянең төп максаты – балаларга иң әһәмиятле социаль-көнкүреш күнекмәләрен бирү. Алар монда үзләрен үзләре тәэмин итәргә өйрәнә: ашау вакытында, бәдрәфтә һәм юыну бүлмәсендә, уку процессында. Кечкенә генә уңыш та педагогларның үзләре өчен дә, әти-әниләр өчен дә бик олы җиңүгә әверелә: урамда йөреп керер өчен мөстәкыйль киенү, пеналны йә портфельне тутыру, җыю, ашарга җылытып алу, кашык тотып ашый белү.

Үзәкне оештыручыларның тагын берсе – педагог Рената Шәрәфетдинова әйтүенчә, бары тик коллективта һәм үзләрен аңлый торган педагоглар, яшьтәшләр арасында гына үзенчәлекле балалар ачылып китә һәм хәтта сәләтләрен дә күрсәтә ала. Иҗади рух белән ярышу атмосферасы барлыкка килә чөнки. Ә менә дүрт стена арасында өйдә утыртып яшәтергә ярамый, ул очракта мондый балалар сүнә, аларның тормышы «диван белән аш өстәле» арасында гына кала. Хәтта урамга йөрергә чыгулар да инде баланы рухландырмый, кызыксындырмый башлый.

БАШТА ҺӘРКЕМНЕКЕЧӘ БУЛДЫ...

Ире белән Юлия игезәк кызлар тәрбияли – 11 яшьлек Элина белән Аринаны. Тормышлары башта һәркемнекечә дә була – меңләгән башка әти-әниләрнеке кебек үк. Әмма көннәрдән бер көнне кызларга диагноз куела, дөресрәге, «хөкем карары» чыгарыла: «акыл ягыннан зәгыйфьлек».

Туганнан соң беренче айларда Юлиягә бер дә җиңел булмый, аңлашыла да, игезәк балалар гел күбрәк игътибарны таләп итә бит. Ул алар белән еш кына ялгызы кала – ашата, йоклата, саф һавага алып чыга. Ә тора-бара балаларда ниндидер үзгәлек барлыгын сизә, бигрәк тә Аринаның балачак проблемалары авыр уза. Мускулларының зәгыйфьлеге – гипотонус ачыклана. Бу, үз чиратында, хәрәкәтләнү аппаратына гына тәэсир итеп калмый, эчке органнарның эшчәнлегенә дә авырлык китерә. Арина начар ашый, начар йоклый, гел эче авыртып интегә. Төннәрен Юлия белән ире, чиратлап, аны саклап-карап чыга башлый.

– Әмма төшенкелеккә бирелергә вакыт калмый иде, – дип елмая әни кеше.

Бер яшь тулганда, инде проблема аермачык була: кызлар башка балалар кебек гөрелдәми, үзләренә мөрәҗәгать иткәнгә реакция белдерми, бик озак башларын тотмый һәм утырып торырга өйрәнә алмый. Атлап китәргә дә алгысымый. Шуннан соң, проблемалар бер-бер артлы артып кына тора. Игътибар туплый алмау, гадәтлә-

рендәге сәерлекләр, кинәт кенә кайнап, ташып чыккан агрессия, еш чирләүләр...

Кызларда баш миенең органик зарарлануы табыла, нәкъ менә шул акыл ягыннан зәгыйфьлеккә сәбәп булгандыр, дип фаразлана. Юлия бу борчу-мәшәкатьләргә баштанаяк кереп чума: башка шәһәрләргә даими бару, хастаханәләр буйлап йөрү, белгечтән белгечкә бәргәләнү... Хәтта имләүчеләргә дә барып карыйлар.

ТОРМЫШНЫҢ АСТЫ-ӨСКӘ КИЛДЕ

Тормышның асты-өскә килгәндәй тоела аларга. Юлия – ике югары белеме һәм дипломы булган белгеч. Аналитик акылга ия ханымны эшендә дә югары бәялиләр, ул «Татэнерго»ның башта стратегик үсеш, ә аннары эчке контроль бүлегендә эшли. Бизнес-процессларның схемаларын төзү белән шөгыльләнә, эшен бик ярата. Әмма китәргә туры килә.

– Мондый хәл килеп чыкса, әниләргә аеруча авыр, – ди Юлия. – Үзенчәлекле балаларга, билгеле, шулай ук бик кыен. Билгеле, дәүләт аларны дәвалар һәм карап торыр, тәрбияләр, укытыр өчен шактый күп акчалар бүлеп бирә, пособие белән ярдәм итә. Ә менә эти-әниләрнең үзләре турында, бигрәк тә әниләр турында кем уйлый? Кызларыма диагноз куелганнан соң, мин шәхси тормышның нәрсә икәнен бөтенләй онытттым. Нәрсә ул ял, отпуск, үзеңне кайгырту, ирең белән йөреп керергә чыгу, театрга, кинога бару...

Әмма беренче бунттан соң («Нишләп миңа моны бирдең?» «Ник мине болай итеп сыныйсың?»), гадәттә аек акыл белән эш итү этабы килә. Юлия язмыш сынавын кабул итә дә бирешмәскә була: көн дә көрәшергә.

Ул үзен тулаем балаларга багышлый. Үзенекеләргә генә түгел, гомумән инвалидлык бирелгән балаларга. Юлиянең зур тырышлыклары нәтиҗәсендә Элина бүген мәктәптә махсус сыйныфка укырга йөри, ә Арина коррекция мәктәбендә белем ала. Юлиянең бу вакыт аралыгында булышырга әзер торган бик күп яңа танышлары пәйда була, алар аны ташламый. Болар, нигездә, шундый ук «кояш балалары»ның эти-әниләре.

ҮЗЕҢНЕКЕЛӘР ҺӘМ КЕШЕНЕКЕЛӘР

«Яшә» үзәгендә нәкъ менә Юлия кебек язмыш сынавы алдында калган әниләр эшли һәм могҗизалар кыла. Мәсәлән, тәрбияче Айгөл Сабирова, аның өчен улы Ризван – тулы бер галәм ул.

Яки Ләйсән Саттарова, аның йөрәге 13 яшьлек сөйкемле яшүсмерне – Максимны берсүзсез кабул иткән, ул аның үстерергә алган. Башта сау-сәламәт бала алырга өметләнгәннәр.

– Әмма минем күзләрем Максимныкы белән очрашкач, йөрәгем әллә нишләп китте, – ди Ләйсән Илдусовна. – Ул, әйтерсең, башка балалар арасында да тирә-якны яктыртып тора торган маяк. Кыяфәтендә тумыштан килгән әдәплелек, зыялылык бар, үзе матур... Мин эредем дә төштем. Беренче очрашудан ук искиткеч якын итү тойгысы барлыкка килде. Ә аралашып киткәч, мин аның эчке дөньясының шундый бай булуына шаккаттым. Без аны ике дә уйламыйча уллыкка алдык. Һәм, беләсезме, шушы көнгә кадәр бер генә мәртәбә дә үкенгәнебез юк!

АНА МӘХӘББӘТЕ ТАРИХЫ

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен тернәкләндерү үзәген булдыру эшендә Юлия белән бергә учредитель булган әниләр бу адымга ни өчен баруларын бик гади аңлата. Махсус мәктәпләр бар, билгеле, коррекция ысуллары, методикалары, авыру балалар өчен интернат-мәктәпләр дә эшли.

Әмма барлык балалар да андый мәктәпләргә йөрергә сәләтле түгел. Кайбер ата-аналарга дефектологлар белән махсус табибларга баласын йөртергә кирәк, юлга гына да ярты көн китә андый чакта. Бу бер белгечтә 40 минутлык сеанс узар өчен!

«Яшә» үзәгендә уникаль мохит тудырылган, биредә һәр белгеч балага социальләшергә ярдәм итә. Бу акча китерә, табышка йөз тота торган бизнес-проект түгел, билгеле. «Яшә» – олы бер ярату тарихы, хәтта ки тарихларының җимеше. Ул башкаларга охшамаган, әмма ата-аналары өчен шулай ук бик газиз балаларга яхшы һәм югары дәрәҗәдәге яшәү мөмкинлеге тудыру омтылышыннан барлыкка килә.

Барысының да көчен һәм мөмкинлекләрен берләштереп, комплекслы ярдәм белән тәэмин итә ала торган махсус пространство булдыру идеясе берничә әнидә берьюлы туа. Алар бу мохитне бергәләп тудыру җиңелрәк булачагына төшенә, ә инде балаларына үз потенциалын ачарга ярдәм итү мөмкинлеге аларны ныклап берләштерә. Монда балалар, чынлап та, яңа нәрсәләргә өйрәнә, үзләрен зур бер дусларча мөнәсәбәтләргә нигезләнгән җәмгыятьнең кадерле өлеше итеп тоя. Үзәк күнекмәләр, дәресләр урыны гына түгел, ә чын мәгънәсендә бер-береңнең ярдәменә таянып яши торган чын өй ул.

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БАЛАЛАРНЫҢ ДА БӘХЕТКӘ ХАКЫ БАР

«Яшә» үзәген булдыру юнәлешендә гамәлгә куючылар шунда ук бер фикергә килми әле. Баштарак көчләрен берләштерү ягыннан алар җиңелрәк, гадирәк ысуллар кулланып карый. Ә узган елны «Яшә»нең булачак образын уйлап бетерәләр – Казандагы бер эшлекле үзәк базасында урнашкан мәктәпне. Әмма барлык әти-әниләр дә тынычрак, кеше күзенә бигүк ташланып тормый торганрак урынга омтыла – балаларны саф һавага да алып чыгасы була бит, ә анда кеше күзе кадалып, сынап, күзәтеп кенә тора... Шундый урынны Оренбург трактында табалар. Бу – яшеллеккә күмелеп утырган җыйнак кына ике катлы йорт. «Яшә»не оештыручылар йортны арендага алыр өчен акча туплый. Ике-өч айдан соң, алар бу йортны үз балалары һәм башка сабыйлар өчен мәрхәмәт һәм кайгыртучанлык утравына әйләндерә.

Юлия үзәккә көч каян килгәнен аңлата: һәр әти-әни баласы өчен уңайлы шартлар һәм әйбәт тәрбия булдырырга тели, аны олы тормышка әзерләп, кешеләр арасына әзерлекле итеп чыгарырга ымсына. Ул кызы Элинаның да киләчәктә, гади генә булса да, берәр эш табуын, кешеләр арасына чыгуын тели.

Әлегә кызлар бу үзәкне яңа дуслар табып, ярдәмләшеп яши торган җылы, якты бер урын итеп кенә кабул итә.

Үзәкне оештырган ата-аналар, әлбәттә, тернәкләндерүнең бик озакка, бөтен гомергә сузылган катлаулы, озак процесс икәнлеген яхшы аңлый. Биредә комплекслы якын килү дә, һәр баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу да гаять мөһим. Шуңа да үзәктә хезмәткәрләр командасын чын профессионаллардан тупларга тырышалар. Аларга бит балалар белән генә түгел, ә ата-аналар, тулы бер гаилә әгъзалары белән эшләргә туры киләчәк, бары шулай гына ныклап алга китешне тәэмин итеп була.

«Яшә» – үзенчәлекле балалар өчен иң яхшы киләчәк булдыру хыялына нигезләнгән урын. Бу – ана мәхәббәтенең баласы хакына барлык киртәләрне җиңеп чыга алуына һәм аның бәхете өчен таулар күчерергә әзер булуына чын дәлил.

«Яшә» үзәгендә күптән түгел генә кечкенә бакча барлыкка килгән – педагоглар да, балалар да, мавыгып, микрояшеллек үстерә.

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ 80 ҖИҢҮ!

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, «Кырык беренче ел балалары» рубрикасын дәвам итәбез. Бу юлы Бөек Ватан сугышы елларында өлкәннәр белән бергә тормыш арбасын җигелеп тарткан гади бер авыл баласының язмышын бәян итәбез.

«КАЗАХСТАННАН СЫЕР ҖИГЕП КАЙТКАНБЫЗ...»

Руфия Фазылова

Чистай районы Уракчы авылында яшәүче Әлфия Закирова әтисез үскән бала. Ул аны гомерендә бер тапкыр күрмәгән дә, чөнки әтисе фронтка киткәндә сабый әле тумаган була. Шуңа да карамастан, Әлфия апа газиз кешесе турында бик күп истәлекләр белә. Алай гына да түгел, әтисенең фронттан килгән хатларын әле дә кадерләп саклый, ә сурәтен зурайтып ясаткан.

– Әтием бик батыр булган. Әмма әниебез Әминә Фәхретдиновага да һәйкәл куярлык: сыер җигеп, җиде баласын Казахстаннан кадәр Уракчыга алып кайткан, – диде Әлфия апа.

Бу гаилә тарихы, чыннан да, чын батырлык һәм чын мәхәббәт турында.

«БАЛАЛАРНЫ АДАШТЫРЫП КАЛДЫРМА...»

Әминә белән Гыймран 1925 елда кавыша. Бер-бер артлы алты бала алып кайталар. 1940 елда тормышлар авыраеп китә. Гаилә башлыгы заманасына күрә гаять җаваплы карарга килә: Казахстанга китәргә кирәк. Әнә авылдашларының берничәсе күченеп китте һәм бик шатланып хатлар язалар: анда тормыш яхшырак икән. Әминә каршы килми,

Фото: Лилиана Вәлитова

алты баланы җыеп, туган якларыннан чыгып китәләр. Яшь гаилә Казахстанның Кустанай өлкәсенә барып төпләнә. Гыймран – фермага, Әминә май заводына эшкә урнаша. Хезмәт хакы әйбәт, йортлы да булалар. Тиз арада хуҗалыкларын, тормыш-көнкүрешләрен тәртипкә китерәләр. Тик бәхетле тормыш бер елдан артык бармый... Илдә сугыш башлана. Дөрес, гаилә башлыгына беренче айларда повестка бирмиләр әле. Шулай да ир белән хатын аңлый: Гыймран гына читтә калмаячак. Куркып көткән ул көн җитә: 1942 ел башында Әминә газиз ирен фронтка озата. Кочагында – алты бала, җиденчесе әле тумаган.

– Әни эти турында сөйләгәндә гел елый иде, – ди Әлфия апа. – Бер-берсен бик яраткан алар. Әни үги ана белән үскән бала, сабыр, бик эшчән була. Әтинең гаиләсен дә үзенеке итеп кабул итә. Әтинең эти-әнисе дә әнине бик ярата. Шуның өчен ул, ике дә уйламыйча, җиде баласын алып, туган ягына – каенана, каената өенә әйләнеп кайта.

Кайту тарихы болайрак. Әминәгә чит җирләрдә җиде баласы белән ялгыз яшәү авырлаша. Әле ярый кул арасына керерлек балалары бар. Олы кызы Наилә, берничә чакрым ераклыктагы авылга барып, үгезләр карый. Малайлар да булыша. Тик сугышның әле азагы күренми, тамак ягы да каты-коты... Әминәнең бердәнбер юанычы – Гыймраныннан килгән хатлар. Аларда сагыну әчесе, кайгырту, юату, мәхәббәт – барысы да бар. Тагын әле туган яктан килгән, каенатасы Мифтахетдин язган хатларны укып шатлана, елый да... «Килен, чит җирләрдә балаларны адаштырып калдыра күрмә. Кайтыгыз, бергә ничек тә ачка үлмәбез», – дип яза ул хатларында.

1943 елның салкын кышын исән-имин чыкканнан соң, Әминә ныклы карарга килә: туган якка кайтырга кирәк! Шулай итеп, май аенда, җиде баласын ияртеп, яшь хатын туган ягына юл тота.

– Әнине бөтен авыл озатып калган, – дип, күз яшьләрен сөртте Әлфия апа. – Кызганганнардыр инде. Әйтергә дә куркыныч: юлда бер ай чамасы кайтырга кирәк. Тамак та бар бит. Күрше рус әбисе безгә яшь сыерын җитәкләп кертеп бирә. Фамилиясе Бондаренко булган, дип истә калган. «Сезгә бу сыер кирәгрәк, юлда сөтен эчәрсез, арба тартып кайтырлык та чамасы бар, борчылмагыз. Мин сезнең өчен догада булам», – дигән. Әни, «Манька» кушаматлы сыерны җигеп, әйберләрне төяп, шулай итеп казах авылыннан чыгып киткән. Абый-апалар җәяү кайткан, арбага 1940 елгы абыем Мөҗипне, аның янына мине генә утырткан.

Әминә белән Гыймранның җиде баласы.

Әминә әбинең 95 яшьлек юбилее.

Әлфия апаның әтисе
Гыймран Фәхретдинов.



«ИКЕ КУЛЫМ КАНАТ БУЛСА...»

«Сагынычлы хат башы, язылгыз каршы. Сез ки семьямнан аерым яшәүче, армия сафында йөрүче, ирең нән, гаять дәрәҗәдә сагынулы, нечкә күңелемнән кайнап чыккан ялкынлы һәм кайнар сәламнәремне тапшырам. Сезгә һәр барчагызга якты көн, шатлыклы тормышлар теләп калам. Һәм дә кызларым Наиләмә, Рәхиләмә, Халимәмә, Факиямә, Әлфиямә сагынулы кайнар сәлам. Улларым Гомәргә, Мөҗипкә мин артык дәрәҗәдә сагынулы сәламнәремне язам. Мин кайтканчы бик зур булуларын теләп калам. Барча авылдашларыма сәлам. Сәламемне тәмам итәм.

Иркәм-бәгърем, сезнең яннан 20 гыйнварда, иртә сәгать 9 да, бернәрсә белмәгән сабый бала кебек аерылып чыгып киттем. Менә шул көнгә бер ел тулды. Шул ел эчендә күпме нәрсәләр күрдем. Явыз немецлар белән сугыштым. Үзем 1942 елның 12 апрелендә яраландым. Докторларның яхшы каравы аркасында җәрәхәтем төзәлде. Тиз көннәрдә явыз немецны җиңеп чыгып, сезнең белән күрешүемне телимен.

Сез ул тарафларда нишләп ятасыз? Сезгә бик күңелсездер, авырдыр, азыгыгыз беткәндер. Язга кадәр ничек чыгарсыз икән? Аннары мәшәкать булса да, илгә кайтыр идегез. Әгәр дә икмәк табылса, нинди нәрсә сорасалар, минем киемнәргә алыштырыгыз.

Мин язуымны тәмам итеп, үзегездән хат көтеп калам. Хат килмәсә, үлеп беттеләрме икән дип куркып торам.

Әтиләрдән хат аласызмы? Сезгә карточка җибәрәм, бәлки алырсыз. Мине сагынганда, балаларыма күрсәтерсез. Мине күргәч, исләренә төшерергә сәбәп булыр. Мин бик сагындым. Сезне күрергә насыйп булырмы?

Җыр белмәсәм дә, сезгә бераз җыр язам:

Алма бакчасына кереп,
Алма өләшер идем.
Ике кулым канат булса
Күреп сөйләшер идем.

Исән-сау хатым барып җиткәч, мине исегезгә төшерерсез. Миңа сагынулы сәламнәрегезне язарсыз. Шуның белән сүзем тәмам. Сезнең белән күрешергә насыйп итсен».

Сәлам белән хәләлең Гыймран.
1943 ел, 24 гыйнвар.

ЮЛ ГАЗАБЫ – ГҮР ГАЗАБЫ...

Юлда ни генә күрми ана кеше. Җил-яңгырлар булганда, туктап, агач ышыгына сыеналар. Үлән, җиләк ашап тамак ялгыйлар. Кипкән сохарилар бик озакка җитми. Каршыга очраган кайберәүләр, бу гаиләне кызганып, сумкасыннан соңгы телем икмәген дә чыгарып бирә.

– Юлда әниләргә хәлле генә кешеләр очраган, – дип дәвам итте Әлфия апа. – Безнең ач икәнлекне күргәннәр. «Арбадагы бу кечкенә улың белән кызыңны безгә калдыр, ичмаса тамаклары туяр», – дигәннәр. Әмма әни каты торган: «Иремә биргән вәгъдәм бар. Бер баламны да бирмим, үлсәк, барыбыз бергә үләрбез», – дигән. Гөнаһсыз балалар хакынадыр инде, шулай исән-имин кайтып җиткәнбез.

– Сыер да зур ярдәм иткән булып чыга, – дим.

– Ничек кенә әле! – ди Әлфия апа, күңеле нечкәреп. – Бер ай буе тамагыбызны да туйдырган, арбасына ятып йоклаганбыз да. Бер ай эчендә бер йортка да кермәгәнбез, курыкмыйча, ялан кырда кунганбыз. Берсендә төнлә сыер качкан. Дөресрәге, бауны кемдер кисеп киткән. Йоклаганда олы кыз – Наилә апа сыерның бавын аягына бәйләп ята торган булган. Шуннан барысы бергә сыерны эзләргә керешкән. Безнең бәхеткәдер инде, Манька бер көтүлеккә кушылган була: «Манька, Манька», – дип дәшкәч, үзе килгән.

Казах далаларын узып, Россия җиренә аяк басканнан соң, Әминә сыерны берәүләргә сатып җибәрә, чөнки туган ягына поезд белән кайтып җитәргә ниятли. Ләкин монда да җайлы гына килеп чыкмый.

– Поездда яраланган солдатлар күп була, – ди Әлфия апа. – Әни шуларның берсенә әйтеп, авылга, Мифтахетдин бабайга телеграмма суктыра. «Безне Норлат тимер юл станциясеннән каршы алыгыз», – дип яздыра. Ләкин безне каршы алучы булмый. Аптырагач, әни ике апамны – Наилә белән Рәхиләне – авылга җәяү җибәрә. «Бабаңа телеграмма барып җитмәгәндер, кайтып әйтегез», – дип үтенә. Хәзер уйлап утырам: юл бик ерак, урманнар аша чыгарга кирәк. Ничек йөрәге җитеп, апамнарны ялгыз җибәрде икән? Хәер, башка чара юк, вак балалар, кием-салымнар да бар, җәяү генә кайтып җитә торган юл түгел. Аллаһы Тәгалә апамнарны саклаган, алар бабай йортына исән-имин кайтып җиткәннәр. Аннан инде бөтен гаилә дә Уракчыга кайтып егылган...

БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК

Туган ягына кайткач, Әминә чынлап та җиңел сулап куя. Каенанасы, каенатасы бик ярдәм итә, бер йортта яшиләр. Балаларның да үз нигезләрендә кәефләре күтәрелеп китә. Монда кая карасаң да, туганнар, дуслар. Гаилә могҗиза көтеп яши башлый: тиздән сугыш тәмамланыр да әтиләре кайтып керер. Ләкин 1944 елның ноябрендә бөтен хыял-өметләр

чәлпәрәмә килә... Фәхретдиновлар йортына кара мөһер сугылган кәгазь калдырып китәләр.

– Әни барыбер гомер буе этине көтте, – ди Әлфия апа. – Картайган көнендә генә өметен җуйды бугай. Әнигә ияреп, без дә этине исән дип уйлый идек. Утын киссәк тә, бакча сөрсәк тә, эти кайтып керер дә безне үтереп мактар төсле иде... Әни, хәленнән килгәнчә, безне кешедән ким-хур итмәде. 1945 елны Мифтахетдин бабай үлеп китте, әни авыру каенанасы, җиде баласы белән ишелгән йортта торып калды. Шулчакта да ул төшенкелеккә бирелмәде. Теләсә нинди эшкә алынды, без дә, кул арасына кереп, аңа ярдәм иттек. Акча юнәтә-юнәтә, йорт җиткереп чыктык. Рәхмәт, туганнар, авылдашлар да бик булышты.

Әминә апа 96 яшендә бакыйлыкка күчә. Кадерле әни, дәү әни булып гомер кичерә ул. Соңгы көннәренә кадәр үзен үзе йөртә. Җиде баласының бүген икесе генә исән икән – Факия апа 90 яшендә һәм Әлфия апа 83 яшен тутырган. Кыз туганнарның икесе дә гомер буе Уракчыда яшәгән. Эшләре, ашлары да уртак булган. Без дә Факия апа белән барып таныштык: улы, килене янәшәсендә бик матур тормыш кичерә икән. Әлфия апа исә тагын да бәхетлерәк – җәмәгате Гаваз абый белән тигез картайганнар. Гаилә коруларына 62 ел булган.

– Гаваз белән бер ул, ике кыз үстердек, – диде Әлфия апа. – Балалар да үзебез кебек матур гаилә корды, һәркайсы өчен ихластан сөенәбез. Бердәнбер улыбыз Рәискә аеруча рәхмәт, безнең яннан китмәде. Киленебез Гөлнара белән бик матур яшиләр. Картлыкта балалар белән яшәү тагын да кадерлерәк икән – янында һәрчак кеше бар. Бөтен өлкәннәргә дә безнең кебек рәхәт картлык бирсен.

Туганнар җыелган вакыт.

...Закировларның йорты нурлы. Бәлки, өйдә көн саен биш вакыт намаз уку хикмәтедер, ә бәлки, бер-берсенә карата хөрмәт булгангадыр. Биредә хатын-кызлар чибәр һәм уңган, ә ир-атлар сабыр һәм акыллы. Гөлнара апаның булдыклылыгына ис китте: берьюлы ике төрле бәлеш белән сыйлады ул безне.

Ә иң сөендергәне – Казахстан далаларыннан җәяү кайткан гаиләнең матур тарихы дәвам итә. Ничә еллар үтсә дә, алар Әминә эбиләренең батырлыгын онытмый, ә буыннан-буынга күчереп сөйли. Гаилә альбомнары, язылган рефератлар – барысы да шуның ачык мисалы. Гыйммран бабаларының фронттан килгән хатлары да иң кадерле ядкәр булып саклана гаиләдә.

ИКЪТИСАДНЫ ҮСТЕРҮ НИГЕЗЕ БУЛАРАК ОСТАЗЛЫК

Россия Президенты Владимир Путин Хөкүмәт алдына икътисадны үстерү буенча зур бурычлар куя. Әмма мондый үсешнең нигезе – бүген хезмәт базарында кытлык булган квалификацияле кадрлар. Проблеманы хәл итүдә остазлыкны торгызу ярдәмгә килә.

РЕНАТА КӘНӘФИЕВА, «Берләштерелгән двигательләр төзү корпорациясе» АҖнең әйдәп баручы эксперты, КИТТУ-КАИны 2024 елда тәмамлый:

– Студент чакта һәркем үзен эзләү һәм тормыш ориентирларын барлау этабын уза. Еш кына бу юл шик, ышанычсызлык һәм киләчәкнең билгесезлеге өчен шомлану тойгысы белән үрелеп бара. Мондый вакытларда дөрес юлны сайларга һәм мөмкинлекләрне студент үзе күрмәгән урында күрергә ярдәм итүче кеше – остазның булуы аеруча мөһим. Ә кайчакта остаз иң гади әйберләрне аңлата, тик ул аларны алга бару өчен нәкъ шул сүзләрне ишетергә кирәк чакта әйтә. Шәкертенә юнәлеш биреп кенә калмый, ярдәм дә итә, аңлы рәвештә алга барырга булыша. Минемчә, үз артыннан ияртерлек кеше булу мөмкинлеген чын бәхет дип санарга кирәк, бигрәк тә яшьлектә.

ЗАКОН ЧЫГАРУ АСПЕКТЫ

Кайбер илләрдә остазлык мәсьәләләре дәүләт дәрәҗәсендә көйләнә. Мәсәлән, Россиядә 2030 елга кадәрге чорга остазлыкны үстерү концепциясе расланган. Бу документта остазлар эшенең максатлары, бурычлары һәм өстенлекле юнәлешләре билгеләнгән, һәм болар барысы да җәмгыятьнең икътисадый, социаль үсешенең максат һәм бурычларына тәңгәл килә. Концепциядә, мәсәлән, остазлык практикаларын гомумиләштерүгә һәм остазлыкны гамәлгә ашыру буенча бердәм алымнар формалаштыруга караган бурычлар беркетелгән.

Россиядә шулай ук хезмәткәрләрне эш шартларына яраклаштыру формаларының берсе буларак остазлыкны популярлаштыру буенча да актив сәясәт алып барыла. Дәүләтнең кызыксынуы берничә юнәлештә – хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда, яшьләргә һәм мәгариф өлкәсенә кагылышлы сәясәттә чагыла.

Фото: Гөлнара Мостафинаның шәхси архивыннан. РЕКЛАМА

ТИМУР САБИРҖАНОВ, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесенең яшьләр ярдәмчесе вазыйфасына конкурсның башкарма директоры, КИТТУ-КАИның 1 курс магистры:

– Остазлык үсешемнең мөһим өлешенә әверелде. Тәҗрибәле кеше, акыл өйрәтмичә, янәшә барганда, ышаныч һәм эшләү теләге туа. Остаз синең көчле якларыңны күрергә һәм энергияңне кирәкле тарафка юнәлтергә ярдәм итә. Остазым Гөлнара Гаптелнур кызы Мостафина ярдәмендә мин хаталарның җиңелү түгел, ә узарга тиешле юлымның бер өлеше икәнен аңладым. Бу алга баруны дәвам итәргә һәм башкалар өчен терәк булырга рухландыра.

Үз чиратында, Татарстанда да остазлыкны үстерүдә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек адымнар ясала. Әмма эшчәнлекнең бу тармагын нәтиҗәле үстерү юлында киртәләр дә бар. Киртәләрнең берсе – хезмәт турындагы законнарда остазлык мөнәсәбәтләренең хокукый яктан көйләнмәгән булуы. Мөгаен, остазлыкны норматив регламентлау буенча дәүләт гражданнар хезмәтендә тупланган хокукый тәҗрибәдән файдаланырга мөмкин булыр иде, әлбәттә, хезмәт мөнәсәбәтләре үзенчәлекләрен исәпкә алып үзгәрткәннән соң.

ЮГАРЫ МӘКТӘП ТӘҖРИБӘСЕ

Югары мәктәптә бакалаврлар, белгечләр һәм магистрлар әзерләгәндә, без гаять тиз үзгәрүчән дөньяда кеше капиталын арттыру һәм үстерү тенденциясенә юнәлешне күрәбез, бу исә постиндустриаль чорда дәүләтнең алга китешен һәм гөрләп үсүен тәэмин итә. Чыгарылыш укучыларының шәхси-һөнәри сыйфатларын үстерү, югары уку йортында белем бирү процессын инновацияле итеп оештыру күбесенчә укытуны камилләштерүгә һәм, студентларны шәхси якын килеп укытуга басым ясап, яңа педагогик технологияләр кертүгә бәйле.

Һәм монда нәкъ менә остазның роле арта.

Югары мәктәптә укытучы, үз тәҗрибәсе белән уртаклашып, яшь кешегә белем һәм күнекмәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерергә, башкалар тәҗрибәсен өйрәнүнең мөһимлеген аңлатырга, үсешнең шәхси-һөнәри траекториясен төзү өчен кирәкле күнекмәләрне сайларга һәм алардан файдаланырга булыша.

АЛИНӘ ХӨСӘЕНОВА, «Казан» Халыкара аэропорты» АҖ баш хисапчысы урынбасары, КИТТУ-КАИның 2 курс магистры:

– Бервакыт мин мондый гыйбарә ишеткән идем: «Остазлык – шәкертнең йөрәгендә һәм аңында эз калдыра торган игелек үрнәге ул». Минем өчен остаз – беренче чиратта уку, һөнәргә өйрәтү, гомумән, теләсә нинди юлда ярдәм итәчәк кеше. Белем, тәҗрибә тапшыру һәм шәкертен кирәкле юнәлешкә борып җибәрү – бәһасез бүләк. Һәрберебезгә тормышның теләсә кайсы чорында, бигрәк тә студент елларында, остаз кирәк, дип уйлыйм. Бу сине нәрсәдер өйрәнергә мәҗбүр итә торган кеше түгел, ә кулыңнан тотып, алга барырга илһамландыра торган кеше!

Остазның шәхси һәм һөнәри сыйфатлары, шәкертенә уңышка ирешүдә ярдәм итү омтылышы – болар барысы да укытучыны билгеле бер мәгънәдә үрнәк итә, ягъни кемнеңдер абруе, дәрәҗәсенең йогынтысы көче, тәрбияви методы эшли, ул студентка шәхси потенциалын ачарга булыша. Тәҗрибәсе азрак булган кешегә чын күңелдән ярдәм итәргә теләве, һөнәрне, укытыла торган дисциплинаны, фәнне, инновацияләрне үзләштерүне яратуы, җаваплылыгы, укучының шәхесе һәм аның уңышлары белән кызыксынуы мондый укытучының үзенчәлекле сыйфатлары булып тора.

КИТТУ-КАИның икътисад теориясе һәм ресурслар белән идарә итү кафедрасы мөдире Гөлнара Мостафина «Хәзерге заман педагог-остазы компетенцияләре» курсын эшләгән. Курс университеттагы академик уку төркемнәренең барлык остазлары өчен гамәлгә ашырыла һәм алар эшли торган барлык өлкәләрне колачлый.

«Минем өчен студент – кафедра, университетның белем бирү программаларына кергән укучы гына түгел, – ди Гөлнара Гаптелнур кызы. – Иң элек ул – күпкырлы уникаль шәхес, ә минем бурычым – аның сәләтен, талантын күреп алу һәм ачу, һәм, бергәләп, ул үзе дә, җәмгыять тә, тулаем ил дә уңышка ирешерлек үсеш траекториясен төзү».

Гөлнара Мостафина билгеләп үткәнчә, университетта эшләү дәверендә ул КИТТУ-КАИның күп студентлары өчен остаз була, хәзер дә элекке укучыларының шактые белән аралаша. Өземтәләребездә аның кайбер укучыларының сүзләрен китерәбез.

ЗИЛӘ ХАФИЗОВА, КИТТУ-КАИның икътисад теориясе һәм ресурслар белән идарә итү кафедрасы ассистенты, КИТТУ-КАИны 2025 елда тәмамлый:

– Остазлык яшьләр тормышында зур роль уйный, ул безгә һөнәри күнекмәләрне үстерергә генә түгел, шәхси сыйфатларны формалаштырырга да ярдәм итә. Остазлар, тәҗрибәләре һәм белемнәре белән уртаклашып, безнең өчен илһам һәм ярдәм чыганагына әйләнә. Аларның киңәшләре хаталарны булдырмаска һәм максатка таба ышанычлы атларга булыша. Остазым Гөлнара Гаптелнур кызы Мостафинага ихласлыгы, намуслылыгы һәм зирәклеге өчен рәхмәтлемен. Хәзер без бер коллективта эшлибез. Ул мине уңышка һәм камиллеккә рухландыра!

SMART KIDS БАЛАЛАР БАКЧАСЫ: ҖЫЛЫЛЫК ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ГАРМОНИЯСЕ

Бүгенге көндә балалар өчен Smart Kids ул – Казан Лицей – инженерлык үзәге дип аталган олы белем бирү пространствосының бер өлеше. Алар тәүге адымнарын әле 10 ел элек башлый. Шушы вакыт эчендә Smart Kidsta иң яхшы белем белән тәрбия бирәләр: балаларда кызыксынучанлыкны, үз көченә ышануны үстерсәләр, педагогларда иҗади энергияне, һөнәри зирәклекне хуплыйлар һәм күтәреп алалар. Балалар бакчасы диварларында җылылык, белемгә йөз тоту һәм ачышларга омтылу хөкем сөрә.

УЕН АША УКЫТУ, ӨЙРӘНҮЛӘР АША ҮСТЕРҮ

Инженерлык лицее системасындагы балалар бакчасы – олы бер белем бирү чылбырының тәүге буыны. Бу элемтә бөтен нәрсәгә булган мөнәсәбәтне дә күрсәтеп тора – мохитне тудырудан башлап, белем бирү ысуллары – методикаларына кадәр. Бакчаның мөдире Елена Баранова һәм методисты Наталья Стрелкова лицей өчен бердәм белем бирү концепциясен булдыруда катнаша. Smart Kidsta аны заманча инструментлар сайлау һәм куллану, балаларны инженерлык дисциплиналарына өйрәтүдә яңача карарлар кабул итеп, уңышлы практикалар кертү аша тормышка ашыралар. Шул рәвешле балалар бакчасында STEM-AR моделе пәйда булган. Ул табигый фәннәр белән технологияләр, инженерлык иҗатын, математиканы, сәнгать белемен һәм укуны берләштерә. Бу модель балаларда тикшеренүләргә хирыслык уятуга юнәлтелгән: кечкенәләр дөньяны уен һәм төрле гамәлләр аша танып белә, урта сыйныф укучылары – эксперимент һәм күзәтү аша, өлкән сыйныфлар – тикшеренү эшләре һәм беренче фәнни проектлар аша.

Smart Kids, башлангыч лингвистика мәктәбе һәм лицей үзе – барысы да бер юнәлештә эшли һәм хәрәкәт итә. Программаларның эзлеклелеге, алымнар белән җиһазларның да дәвамчанлык принцибына корылган булуы балаларга алдагы баскычка инде формалашкан мотивация белән, ышанычлы рәвештә күчәргә мөмкинлек бирә. Аңлашыла ки, мондый җирлектә һәм белем алу процессында бала үз алдына куелган һәр бурычны үтәр өчен көче җитәчәген белеп тора.

Фото: Лицей – инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

КУБИКТАН – ОЛЫ ДӨНЬЯГА

Оксана Николаева 26 ел дәвамында үз һөнәре буенча эшли. Ул барлык яшьтәге балалар белән дә шөгыльләнгән: әзерлек төркеменнән алып, кечкенәләргә кадәр. Ә бу елны үз практикасында беренче мәртәбә ике яшьлекләрне тәрбиягә алган. Аның күзәтүе астында балалар кубиклардан манаралар торгыза, конструктор детальләрен беркетә, формасы һәм төсенә карап, предметларны тиешле тәртиптә тезеп чыга. Гади генә күнекмәләрдән күзәтүчәнлек һәм эспериментларга әзерлек формалаша.

– Ике яшьтә балалар инде дөньяны танып, әйберләр арасындагы бәйләнешләрне күрә башлый. Шөгыльләнгән вакытта бер бала блоклы конструкторның зур һәм кечкенә детальләрен бер-берсенә тоташтырды да: «Бу – эт», – диде. Чынлап та, ул эткә охшаган бит. Мин аңа этнең кайда яшәгәнен уйлап табарга киңәш бирдем, кая юл тотканын. Шулай итеп, без уенны дәвам итәбез, тулы бер сюжет төзибез. Уйлау сәләтен үстерәбез, тел күнекмәләрен эшкә җигәбез. Бу яшьтә балалар күп нәрсәгә кемгәдер охшап кабатлау аша өйрәнә. Шуңа да актив мохит бик мөһим, биредә алар гади әйберләрдән катлаулы нәрсәләргә төшенә, – ди Оксана Геннадьевна. Һәр дәрес өчен төп белем бирү программасына өстәмә була алырлык форматлар сайлый ул.

– Балалар үзгәреп тора, без дә алар артыннан өлгерергә тиеш. Элегрәк баланың соравына җавапны белмәсәң: «Мин бу теманы өйрәнеп, сиңа соңрак җавап бирермен», – дияргә ярый иде. Хәзер бу инде туры килми. Балага җавапны, үзара сөйләшеп, фикерен әйтергә мөмкинлек тудырып, шунда ук бирергә кирәк. Педагогика күпкә катлауланды, әмма ул торган саен иҗадирак һәм кызыклырак була бара. Smart Kidsта үз эшеңә күмелеп эшләргә уңай шартлар тудырылган, – ди ул безгә.

ИРТӘБЕЗ КОЧАКЛАШУЛАРДАН БАШЛАНА

Интеллектуаль үсеш үз чираты белән барырга тиеш, ә педагогларның тырышлыклары – үз нәтиҗәләрен китерергә. Балага белем алу һәм үсеш процессында үзен хәвефсез хис итү, кемнеңдер аңа булышуын тою, ягъни эмоциональ яктан органик үсеш кичерү гаять әһәмиятле. **Гөлсәрия Сафиуллина** – кечкенәләр төркеме тәрбиячесе, 10 ел эшләү дәверендә ул инде үз эш ысулларын уйлап тапкан. Ул балаларны шаккатыру, күңелләрен ачу белән шөгыльләнми, бары тик аларга юнәлеш кенә бирә. Янәшәдә торып. Шул ук вакытта, төркемдәге һәр баланы ишетә, күрә, ача белә – менә монысы чын мәгънәсендә зур сәнгать.

– Балалар төрле темпта үсеш кичерә. Аларның холыклары бик төрле, омтылышлары. Кайсынадыр мөстәкыйльлек кирәк, икенчесенә – аны кабул итүләре, ярдәм, терәк. Һәрберсе белән аралашу тәртибен булдыру өчен вакыт таләп ителә.

Бу төркемдәге балалар белән – өченче елыбыз. Һәр иртәбез кочаклашудан башлана. Алар ялларда нәрсә белән шөгыльләнгәнен сөйләргә ашыга. Мин аларның ничек үскәнен күзәтеп торам, эшебезнең нәтиҗәсен күрәм, бу мине бик рухландыра, – ди Гөлсәрия Рәисовна.

СҮЗЛӘР ТЕРЕЛГӘНДӘ

Smart Kidsta индивидуаль, «өйдәгечә» якын килү белән заманча белем бирү инструментлары үзара керешеп китә. Балаларның үсешенә карап, программага югары технология элементлары өстәлеп тора: конструкторлаштыру, проектлар эшләү, программалаштыру. Алар барлык юнәлешләрне дә колачлый – әйләнә-тирә дөньядан башлап, телләрне өйрәнүгә кадәр.

– Мин педагогика белән татар телен бик яратам. Балаларга телнең барлык матурлыгын күрсәтергә телим. Кечкенәләр төркемендә рәсемнәр һәм җырлар ярдәмендә сүзләр өйрәнүдән акрынлап урта һәм өлкән төркемнәрдә инде сәхнәләштергән тамашалар куюга кадәр үсеп

җитәбез. Роботлар программалаштырган чакта татар теле дәресләрендә өйрәнгән сүзләрне һәртөрле гади командалар башкарыр өчен кулланабыз, – дип сөйли татар теле укытучысы **Лилия Газизҗанова**.

Лилия Рифкатовна Smart Kids укучылары өчен тулы бер тел галәме булдырган. Монда аңа Мияу исемле песи белән Акбай атлы эт ярдәмгә килә. Алар белән һәр дәрес күңелле тамашага – тулы бер спектакльгә әверелә. Бу галәмдә башка персонажлар да яши: Куян, Аю, Төлке, татар экиятләреннән каһарманнар.

– Без «Мататалаб» җыелмасы ярдәмендә робот җыю техникасы дәресләренә татар теле дәресләрен дә кушып җибәрдек. Робот өчен мин колакчыннары булган башлык тектем, бу балаларга яхшы таныш Куян инде. Балалар аны махсус басуда кишер эзләргә программалаштыра, алгоритмнарны татар телендә билгели: юнәлешләрен, ничә адым ясарга кирәклеген, ничә кишер табарга тиеш булуын, – дип сөйли безгә Лилия Газизҗанова. – Шул рәвешле, балаларда югары технологияләр белән милли тел янәшә яши, алар бер-берсеннән аерылып тормый дигән тоемлау барлыкка килә.

КАТЛАУЛЫ КОНСТРУКТОРЛАР

Smart Kidsның әзерлек төркеме – мәктәпкә күчәр алдыннан соңгы этап ул. Биредә балалар инде мөстәкыйль уйлый, фикерен белдерә ала, зур булмаган проектларны эшләргә өйрәнгән була. Үзләштергән күнекмәләрне тагын да үстерер өчен, **Мәсгудә Теребилина** һәр дәрескә тикшеренү алымнары кертергә тырыша. Шулай ук мөстәкыйль эшли белүгә, иҗадилыкка зур басым ясый.

– Әгәр гербарий җыябыз икән, без бу яфракларны нинди дә булса яңа күнекмәне үстерү юнәлешендә файдаланабыз, әйтик, шул яфраклардан арыслан сурәтен эшлибез. Детальләрдән нидер җыю балаларга бик ошый. Дәресләрдә без «Фанкластик» кулланабыз – ул шактый катлаулы конструктор. Модельне җыеп бетерер өчен дәрес вакыты гына җитмәскә мөмкин, әмма балалар һәрвакыт бик мавыгып шөгыльләнә. Минем бурыч – башта яңа әйбердә

үзем күнекмәләр булдырып, шуның нечкәлекләрен балаларга да аңлатып бирү. Әти-әниләр балаларының кайтып ни белән ничек шөгыльләнүе турында мавыгып сөйләвен әйтеп күрсәтә дә, мин эшемне яхшы башкарганмын икән, дип чын күңелдән сөенәм, – ди Мәсгудә Рәфыйковна.

БАЛАЛАР БАКЧАСЫ НИЧЕК ӨЙГӘ ӘВЕРЕЛГӘН

Smart Kidsның якты, җылы, әйтерсең, өйдәгечә атмосферасына кумелгәч, кайчандыр биредә күңелсез, салкын диварлар, искереп беткән җиһазлар булганлыгына ышанып та булмый. Ремонт та мөгаллимнәрнең һәм ата-аналарның үз тырышлыгы белән башкарылган. Балалар бакчасының яңа тормышы ул Инженерлык лицее составына кергәч башланган.

– Венера Кәшфиевнаның* беренче килүен һич онытасым юк. Мин аңа безнең бинабыз буйлап экскурсия уздырдым. Венера Кәшфиевна барысын да игътибар белән карап чыкты. Азактан болай диде: «Әйе, монда бик каты тырышырга кирәк, әлбәттә». Шулай итеп үзгәрешләр башланды, – дип сөйли **Гөлия Карташова**. Ул Smart Kidsның хуҗалык эшләре буенча директор

урынбасары. Гөлия Гатаулловна биредә 2004 елдан бирле эшли. Ул балалар бакчасының оештыру һәм инфраструктура ягыннан яңарышын беренчеләрдән булып хуплый, күтәреп ала. Хәзерге көндә үзе балалар бакчасының көнкүрешен тәэмин итүгә тулаем җавап бирә: хуҗалык эшләре белән идарә итә, сатып алуларны оештыра, янгын куркынычсызлыгын контрольдә тота, кече персоналның эшчәнлеген көйли.

– Бу бер дә җиңел эш түгел, җаваплылык гаять зур, әмма миңа эшем бик ошый. Коллективыбыз бер дигән, алар бар эштә дә зур ярдәм күрсәтә. Бездә бердәмлек мушкетерларча дип әйтер идем: бер кеше – бөтен кеше өчен, бөтен кеше – бер кеше өчен. Һәркем хезмәттәшен тигез күреп эш итә: берәрсе авырып китсә, әйтик, мин кече тәрбиячегә булышып җибәрә алам. Савыт-саба юудан да тайчанмыйм, краннарны борырга кирәк булса да... Без барыбыз да уртак, олы бер эшне башкарабыз, – ди Гөлия Гатаулловна. – Балалар, ата-аналарның канәгать калуын күрүдән дә зуррак куаныч юк, димәк, эш тиешле җае белән бара. Ә бу бик яхшы илһамландыра!

ҖЫЛЫЛЫК – ЫШАНЫЧЛЫ КУЛЛАРДА

Smart Kidsта барысы да, чынлап та, сәгать шикелле эшли. Һәркем үз бурычын, урынын белә һәм эшен чын күңелдән башкара. **Гүзәлия Гәрәева** – юу буенча оператор. Ул әйберләрне юу техникасы белән идарә итә: тиешле температураны сайлый – алтмыш яки туксанны, вакытны исәпкә ала, барабан ярдәмендә көнгә унлап комплектны юып, сыгып, киптереп чыгара. Аның уңган куллары белән юылган, балалар йокы бүлмәсендә җәелгән урын-җир өйдәгечә рәхәтлек бирә.

– Мин бу балалар бакчасында инде егерме елга якын эшлим, хәзер миңа монда бик уңайлы һәм рәхәт. Коллектив та әйбәт, мохит тә, балалар белән эти-әниләр дә. Лицей безне бик яхшы шартларда тота, кайгырта, төрле сәфәрләр оештыра. Мондый мөнәсәбәт – алтын бәһасе, – ди Гүзәлия Ганиҗановна. – Балаларны күзәтеп тору да зур сөенеч: үскәннәрен, мөстәкыйльлеккә өйрәнгәннәрен күрәсең, ә тирә-якларында – чисталык, пөхтәлек. Димәк, эшең юкка гына түгел, дигән сүз. Көн дә нәрсәнедер тагын да яхшырак эшлисе килә – алар өчен дә, уртак бакчабыз өчен дә. Зур гаилә итеп хис итәм мин үзебезне.

КЕЧКЕНӘ АЧЫШЛАРДАН – ЗУР КИЛӘЧӘККӘ

Smart Kidsтагы белем бирү практикасы аерым бер, махсус компонентлардан оешкан: мәктәпкә кадәр белем бирүнең алдынгы технологияләре, хезмәткәрләрнең чын мәгънәсендә һөнәрмәндлеге, фәнни эш белән җитәкчелек итүчеләрнең яңа методик ысуллары. Шулай ук, педагогларның зур тәҗрибәсе дә үз ролен уйный. Аларның барысы да диярлек бу бакчага үз балаларын йөрткән. Smart Kidsның барлык башка чыгарылышлары шикелле үк, үз балалары да мондагы тәрбиячеләрне, пешекчеләр, мөгаллимнәр һәм башка барлык төр хезмәткәрләрне рәхмәт хисләре белән генә искә ала. Аларның үзләрен ничек укытуларын, ашатуларын, бәйрәмнәр оештыруларын, кайгыртуларын.

Нәкъ менә шушы бакчадан балалар мәктәпкә кызыксынучан, яңа ачышларга әзер укучылар булып аяк атлый. Һәм төгәл белә: янәшәдә гел аларга ышана, көч бирә, ярдәм күрсәтә торган өлкәннәр булачак. Уен, фән, үз эшеңә мәхәббәт хөкем сөргән гармонияле балалар бакчасы мохитеннән атлап чыккан балалар бу атмосфераны, әлбәттә, гомерлеккә күңелендә саклый, үзләре белән олы тормышка ала. Шуңа да монда белем алу шатлыклы тойгылар белән өретелгән. Ә мәктәп үзе бәхетле балачакның тәмамлану ноктасы түгел, ә аның яңа борылышы, күңелле дәвамы булып тора.

* Венера Кәшфиевна Хәйретдинова – Казан Лицей – инженерлык үзәге директоры.

КАЗАН ЛИЦЕЙ – ИНЖЕНЕРЛЫК ҮЗӘГЕНӘ 10 ЯШЬ ЮБИЛЕЙ БЕЛӘН!

ЫШАНЫЧ + ҮСЕШ: «КЕЧКЕНӘ МӘКТӘПНЕҢ» УҢЫШ ФОРМУЛАСЫ

ILS (Intellectual Linguistic School), яисә «Кечкенә мәктәп» – Казандагы Лицей – инженерлык үзәгенең башлангач баскычы. «Лингво + техно» принцибы биредә беренче сыйныфтан ук тормышка ашырыла.

Балалар тулы көн моделе буенча укыйлар: көннең беренче яртысында төп фәннәр укытыла, төшке аштан соң өстәмә инженерлык дәресләренә йөриләр, тьюторлар белән бергә, тел мохитенә чумып, проектлар эшлиләр. Мондый алым башлангыч мәктәпне тәмамлаучыларга ышанычлы рәвештә лицейда белем алуга күчәргә һәм IT, робот техникасы һәм киләчәкнең башка дисциплиналарын үзләштерергә мөмкинлек бирә.

ILS моделенең бөтенлеге коллективның үз эше белән кызыксынуы, компетентлыгы һәм профессиональлеге нәтиҗәсендә саклана. Венера Хәйретдинова Лицей – инженерлык үзәгенең бөтен структурасына җитәкчелек итә. Әлеге структурага Smart Kids балалар бакчасы да, «Кечкенә мәктәп» тә керә. Биредә фәнни җитәкчеләр белән бергә, бүген ихтыяҗ зур булган инженерлык белеме үстерелә. «Кечкенә мәктәп» җитәкчесе Эльмира Митрофанова команданың көйле эшен тәэмин итә, мәктәп, әти-әниләр, балалар, инженерлык лицее арасында бәйләнешне тотып тора. Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Екатерина Гаврилова тел экосистемасын төзергә һәм тьюторлык эшчәнлеген көйләргә ярдәм итә. Олимпиада хәрәкәте кураторы Татьяна Майорова, балаларның кызыксынучанлыгын күреп, аны даими әзерләнүләргә, олимпиада, конкурсларда җиңүләргә әйләндереп, индивидуаль эш юнәлешен үстерә. Укытучы һәм тьюторның ныклы хезмәттәшлегендә ышаныч һәм белемгә нигезләнгән мәктәп оештырыла. Педагог талантлы булганда, аңа иҗат ирекe бирелгәндә, ярдәм күрсәтелгәндә, ул һичшиксез балалар күңеленә сукмак сала. Безнең әңгәмә – моңа иң яхшы дәлил.

Фото: Лицей – инженерлык үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

ILS (Intellectual Linguistic School) – интеллектуаль лингвистика мәктәбе (ингл.).
** Smart Kids – акыллы балалар (ингл.).

ИЛҺАМЛАНДЫРУ ОСТАЛЫГЫ

Рәйсә Хафизова кечкенәдән укытучы булырга хыяллана. Бүген ул 44 еллык эш стажына ия педагог. Хәзергә кадәр аның күңелендә күренекле тарихчы Василий Ключевскийның: «Яхшы укытучы булу өчен, үзең укыткан фәнне дә, үзең укыткан балаларны да яратырга кирәк», – дигән сүзләре саклана.

– Бүген безнең бурыч – укучыларга яңа белем бирү генә түгел, балаларны үзара аралашырга, бер-берсе белән эш итәргә, тиз үзгәрә торган социаль шартларга яраклашырга өйрәтү. Укытучы үзе дә үзгәрешләргә игътибарлы булырга, яңа компетенцияләрне һәм педагогика технологияләрен үзләштерергә тиеш, – ди Рәйсә Рафаиловна. – ILSда без балаларны урта һәм зур сыйныфларда актив проект эшчәнлегенә әзерлибез. Төп ысулларның берсе – команда белән эшләү. Моңа башлангыч мәктәптән үк өйрәтәм: төркемнәрдә, парларда эшлим, баланы үз эшен, сыйныфташы эшен бәяләргә өйрәтәм.

Ключевский сүзләрен тормышка ашыру тырышлык таләп итә. Рәйсә Хафизованың үз тәҗрибәсе бар. Ул үзен үзе көйләү күнекмәләрен үстерә. Бу киеренке хәл туганда тыныч булып калырга, һөнәреңнән ялыкмаска һәм яхшы кәеф сакларга булыша. Укытучының эшендә күп нәрсә шуңа бәйле: укучы укытучы уңышка әзер булганда гына җиңүләргә ирешә ала.

Z БУЫНЫН АҢЛАП ЭШЛӘҮ

Бүгенге башлангыч мәктәп укучылары – цифрлы мохиттә үскән буын. Бу аларның үзенчәлеге, шуңа күрә мәгълүматны тизрәк кабул итсәләр дә, алар өчен мәсьәләләрне чишү катлаулырак. Шуңа күрә материалны бирүнең яңа формаларын эзләргә, игътибарны саклап калу өчен уен һәм интерактив алымнарны кулланырга туры килә, ди башлангыч сыйныфлар укытучысы, «Педагогик дебют – 2024» Бөтенроссия конкурсы лауреаты, Казан шәһәре мэры гранты һәм «Безнең яңа укытучы» федераль проекты гранты иясе **Юлия Денисова.**

– Шул ук вакытта бүгенге балалар кызыксынучан, ачык һәм яңалыкны тиз үзләштерә. Аларны мавыктыру өчен мин еш кына онлайн-платформалар кулланам, мәсәлән, LearningApps* яки Wordwall**, анда теләсә нинди темага интерактив уеннар табарга мөмкин, – дип сөйли Юлия Владимировна. Цифрлы технологияләр кулланып, ул тере аралашуга зур игътибар бирә: укучылар белән бергә иҗади проектлар, күргәзмәләр әзерли, бәйрәмнәргә сыйныфны бизәтә. Бу балаларны үзара якынайта һәм мәктәптә укуны кызыклы итә.

– Аларның киләчәгенә чыннан да йогынты ясавым мине рухландыра. Укучыларымның минем янымда үсүләрен, үзгәрүләрен күз саен күреп торам. Иҗат итү һәм хезмәттәшләрем белән аралашу үземә дә үсәргә ярдәм итә. Без идеяләребез белән уртаклашабыз, бергәләп яңа юллар-ысуллар эзлибез, бер-беребезне илһамландырабыз. Мондый мохиттә эшләү тормышымны җанлы һәм кызыклы итә, – ди педагог.

ЫШАНЫЧ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ

ILSта аерым бер җыйнаклык сизелә. Монда зур мәктәпләрдәге кебек ыгы-зыгы юк: класслар кечкенә, педагоглар үз укучыларын фамилияләп кенә түгел, кызыксынулары, гадәтләре, кәефләре буенча

* *LearningApps – өйрәтә торган кушымталар (ингл.).*
** *Wordwall – сүзләр дивары (ингл.).*

да беләләр. Мондый мохит педагогларга илһамланып эшләргә, ә балаларга укуга кызыксыну һәм ышаныч тоярга булыша.

– Бирегә килгәнче ун ел гомумбелем бирү мәктәбендә эшләдем. Анда бер параллельдә 15 ләп класс булырга мөмкин иде. Арыдым, эштән киттем һәм мәктәпкә кире кайтырга уйламадым да. Ләкин бераздан мине лицейга чакырдылар, һәм миңа мондагы гаиләдәге

кебек мөнәсәбәтләр ошады. Инде менә дүрт ел мин монда эшлим, китәргә дигән уем юк, – ди башлангыч сыйныф укытучысы **Диана Малахова.** Үзара ярдәм, тынычлык, ышаныч мохите булдырып, укытучы үзенең тәрбияләнүчеләренә карата да бик игътибарлы мөнәсәбәттә.

– Узган елны минем 1 «В» сыйныфым шигырь сөйләргә өйрәнде. Балаларны такта янына бишәрләп чыгуларын сорадым, бөтен кеше каршында чыгыш ясау куркыныч булмасын өчен. Кемдер барыбер оялды, кайберләре сүзләрен онытканга елап та җибәрде. Аннары, балалар урамга ял итәргә чыгып киткәч, каушап калганнар минем яныма аерым килеп сөйләделәр, – ди Диана Равилевна. – Шул рәвешле әкренләп сыйныф каршына чыгып сөйләүдән курыкмаска, оялмаска өйрәндек. Тьютор белән уртак эшебезне балалар укуда да, проект эшләрендә дә уңышка ирешерлек итеп оештырдык. Алар шулай, бик рәхәтләнеп, чит телләрдә башкарыла торган лингвистика театры күренешләрендә катнашалар.

ҺӘРКЕМ БИШЛЕ АЛСЫН!

ILS өчен «бөтенсоюз старостасы» Михаил Калининның: «Укытучы – кеше күңеле инженеры» дигән сүзләре аерым мәгънәгә ия. Лицейның башлангыч мәктәбе укытучылары чыннан да инженерлар кебек эшли: дәресләрне һәм үз эшчәнлекләрен киләчәктә төгәл фәннәрне өйрәнгәндә балаларның ныклы нигезләре булырлык итеп проектлыйлар.

– Балаларга уку җайлы һәм җиңел булсын өчен, укытучының да үсүе мөһим. Хәзер бу яктан иҗади якын килүгә аерым игътибар бирелә. Быел миндә – дүртенчеләр, чыгарылыш сыйныф. Алар уеннар, иҗади эшләр, төрле квестлар кергән дәресләрне шатланып көтеп ала. Болар барысы да миңа математика,

әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә авыр темаларны аңлатырга ярдәм итә. Һәр көнне алар үз белемнәрен тәҗрибәдә кулланалар, аларны моның өчен башка укытучылар да мактый, – дип сөйләде башлангыч сыйныфлар укытучысы **Дилә Җиһаншина.** Укучыларның уку белән кызыксынулары, ата-аналарның белән җылы элемтәләр

укытучыга да канатлар куя. Әти-әниләрнең рәхмәт сүзләре педагог хезмәтенең юкка гына булмавын раслый. Һәм үз белемеңне арттыру белән шөгыльләнергә, категорияңне күтәрергә, конкурсларда катнашырга көч бирә. Диләнең хыялы – кайчан да булса үзенең кечкенә генә мәктәбен ачу, анда балалар бары тик бишлегә генә укыячак. Хыялга юл бүгенгедән башлана.

ҮЗАРА АҢЛАШЫП ЭШЛӘҮ...

Лицей системасында укытучы белән тьюторның уртак эше аралашу ярдәмендә дәвам итә һәм киңәя торган пространство тудыра. Көннең икенче яртысында тьютор балаларга өй эшләрен эшләргә ярдәм итә, алар белән инглиз яки немец телендә сөйләшә. Һәр тьютор мәктәпкә үз тәҗрибәсен алып килә, һәм биредә акыллы гамәлләр, игелекле эшләр һәм мәңгелек кыйммәтләр яхшы шытымнар бирә.

– ILS моделен уникаль итүчеләр – укучыларыбыз. Чәчрәп торган, талантлы, сәләтле, игелекле һәм ярдәмчел балаларыбыз. Мин аларның ихласлыгына һәм самимилегенә сокланам. Шул мизгелләрдә үземнең дөрес урында эшләвемне аңлыйм. «Кечкенә мәктәп»тә чыннан да һәр укучыны беләләр, аларга сәләтләрен ачарга булышалар, – ди **Айгөл Хәбибуллина.** Ул шәкертләрен инглиз телендә аралашырга өйрәтә. Тьютор эше гел игътибар үзәгендә булуны таләп итә. Нәтиҗәгә ирешер өчен, үз кыйблаңны саклап калырга кирәк. Айгөл Фиргатовна уңышлы эшчәнлегенең серләре белән дә бүлеште:

– Миңа күңел көрлеге, эшләрне дөрес бүлә белү, кирәк вакытта хезмәттәшләремнән ярдәм сорау, вак-төякләрдән дә шатлык табу сәләте һәм, әлбәттә, якыннарымның эшемне аңлавы булыша. Мин гаиләмә, яраткан шөгыльләремә һәм ялга вакыт калдыру өчен, мәктәптәге эшләремне вакытында яисә алданрак эшләп куярга тырышам. Ял итеп алганнан соң, яңа көч, дәрт, идеяләр белән рухланып эшемә киләм.

КОЧАКЛАШЫП ӨЙРӘНҮ...

– Мине эшемнең нәтиҗәләре илһамландыра. Мәсәлән, балалар лингвистика театрында спектакль кую өчен текстны вакытында өйрәнгәндә, мәктәп экият фестивалендә шәп чыгыш ясаганда, я булмаса инглиз телендә алып барыла торган «World around us»* дәресләрендә сорауларыма актив җавап биргәндә, – дип сөйли тьютор **Гөлнара Гыйләҗетдинова.** – Уңышымның, күркәм нәтиҗәләрнең нигезе – укучыларның кызыксынучанлыгы, аларның яхшы кәефе. Мин укытуның төрле формаларын кулланам, уеннарга зур игътибар бирәм. Интерактив такта балаларга таныш цифрлы мохиткә чумарга булыша, өйрәнгәннәрне ныгыту өчен дә файдалы. Тагын бер принцибым – ышанычка корылган аралашу. Мин сыйныфта уңайлы мохитне көйлим, һәр баланы тыңлыйм, хуплыйм һәм, һичшиксез, ниндидер уңышлары өчен мактыйм. Балаларның ышаныч белән кочагыма сыенулары бик сөендерә!

* «World around us» – «Безнең тирә-юньдәге дөнья», ингл. теленнән

БАЛАЧАК БАЛАЧАК БУЛЫП КАЛЫРГА ТИЕШ

– Тьютор эшендә иң мөһиме – укучының үсешен, аңардагы үзгәрешне күрү мөмкинлеге. Бу бигрәк тә лингвистика театры дәресләрендә сизелә. Баштагы оялчанлык, тарсыну юкка чыга, ел ахырына бала ачыла, хисләрен иркен белдерә, инглиз телендә ышанычлы сөйләшә башлый, – ди тьютор **Элиза Галиванова.** «Кечкенә мәктәп» аңа кечкенә инглиз пансионын хәтерләтә, анда, барыннан да элек, искиткеч педагоглар һәм хезмәткәрләр тудырырга тиешле ышаныч һәм уңайлылык мөһим. Укучылар һәм педагоглар бер-берсен яхшы белә, рәхәтләнеп аралаша һәм уңышларга бергәләп сөенә. Бала, теләсә кайсы олы кеше янына килеп, ярдәм сорарга курыкмый.

– Мин һәр бала белән аерым эшләүгә өстенлек бирәм. Һәр бала үзен тыңлаганны, хөрмәт иткәнне, фикеренә колак салганны ярата, – дип билгеләп үтә Элиза Илдаровна. – Һәм минемчә, балачак балачак булып калырга тиеш, шуңа күрә дәресләрдән соң уйнарга, күңел ачарга вакыт калсын, дип тырышабыз. Нәкъ менә шундый алым ныклы контакт булдырырга, укуга кызыксыну уятырга ярдәм итә.

РУХЛАНДЫРУДАН – ОЛИМПИАДАГА

– Тьютор бала укыган вакытта гел аның янында, аны ничек рухландырырга кирәклеген белә, мәктәптән һәм гомумән дәресләрдән нәрсә алырга теләгәнен аңлый. Ул белем алу юнәлешен сайлауга уңай йогынты ясый ала торган дус һәм иптәш, – ди инглиз теле укытучысы һәм тьютор **Ирина Куприянова.** – Балалар мәктәпкә кызыксынып йөргәндә, ата-аналар яхшы нәтиҗәләр күргәндә, ә тьютор үз бурычларын үтәүдән ләззәт алганда гына уку нәтиҗәле була. Әлбәттә, тьютор эше төгәллекне, җыйнаклыкны таләп итә, аңа үҗәтлек, сабырлык та кирәк. Бу сыйфатлар көндәлек эшнең бер өлешенә әйләнгәч, нәтиҗәләр озак көттерми: балалар, олимпиадаларда һәм конкурсларда җиңеп, сәхнәдә ышанычлы чыгыш ясый башлый, халыкара имтиханнарны уңышлы тапшыра.

Лингвистика театрын Ирина Львовна төп белем бирү ысулларының берсе дип саный. Чит телләрне өйрәнүнең заманча методикалары белән тулыландырылган театр педагогикасы чын-чынлап сыгылмалы һәм җанлы белем бирү моделен булдырырга ярдәм итә. Ул башлангыч сыйныф укучыларының яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала һәм иң мөһимен – чит телдә иркен һәм ышанычлы аралашуны үстерә.

ОФЫКЛАР ТАТАРЧА АЧЫЛА

ILSта телләрне өйрәнү – чын сәяхәт: тирәнгә – нәсел тамырларына һәм киңлеккә – халыкара мәйданга. Татар теле, мәсәлән, – 3 миллионга якын татар яшәгән Россия төбәкләренә, дистәләгән мең татар гомер иткән чит илләргә һәм тагын 200 миллионга якын кеше сөйләшә торган төрки төркемдәге 14 башка телгә ачкыч. Бу хакта укучыларга татар теле дәресләрендә **Гөлназ Гыйләҗетдинова сөйли.**

– Мәктәп профиленә ияреп, темалар даирәсе һәм лексикасы елдан-ел киңәя. Дүртенче сыйныфта балалар ата-аналарының һөнәрләре турында чыгышлар әзерлиләр, моның өчен техник өлкәгә караган сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең татарчага тәрҗемәсе таләп ителә. Югары сыйныфларда татар телендә без һөнәри юнәлеш турында, шулай ук татар теленең дә халыкара тел булуы турында сөйләшәбез. Балаларга бу алган тел белемнәрен мәктәптән соң да саклап калу өчен стимул, – ди Гөлназ Габдулловна. Ата-аналар еш кына баланың телне өйрәнүе, дәресләрнең җылы үткәрелүе, укытучының игътибарлы булуы өчен аңа рәхмәтләрен җиткерәләр. Моңа театр тәҗрибәсе дә ярдәм итә: Гөлназ Габдулловна – инженерлык лицееның татар труппасында катнаша. Сәхнә сәнгате сүзне, интонацияне, эмоцияне нечкә итеп тоярга ярдәм итә. Димәк, һәр бала белән уртак тел табарга да. Дәрес белән спектакль асылда бик якын: анда да, монда да тамашачының яки укучының сюжет белән мавыгуы, иң кирәклесен ишетүе мөһим.

ЧИСТАЙДАН КЫТАЙГА КАДӘР – СӘЛӘТ ЧИКЛӘР БЕЛМИ

Бүген чит телне өйрәнү дәреслектән күчереп язу, ятлау түгел. Технологияләр гасырында балалар материалны программалар һәм гаджетлар ярдәмендә яхшырак үзләштерә, анда барысы да инглиз телендә, ди **Дарья Ластовец.** Ул мәктәптә инглиз һәм кытай телләрен укыта.

– Дәресемне 90 процентка чит телдә алып барам: өйрәнүнең иң яхшы ысулы – мохит булдыру. Дәресләремнең бөтенесен дә интерактив уен формасында эшлим. Кытайга соңгы сәфәремдә мин укучыларга яңа белемнәр алып кайту бурычын куйдым, шуңа күрә рәхәтләнеп фотографияләр һәм югары технологияләр өлкәсендәге кызыклы казанышлар белән уртаклаштым, чит телләрне белү һөнәр сайлауны формалаштыруда һәм үз мөмкинлекләреңне тормышка ашыруда ярдәм итә, – дип сөйли Дарья. Аның өчен педагог булып эшләү – балачак хыялын тормышка ашыру.

– Минем әби-бабам, фронттан кайткач, Чистайда мәктәп салган. Әбием химия һәм биология укыткан, бабай тарихтан кергән, директор булган. Алар турында истәлекләрне тыңлаганда, иске мәктәп көндәлекләрен актарганда, мин дә шундый ук көчле, зирәк булырга, барысын да дөрес эшлим, дигән ышаныч белән яшәргә хыялландым, – ди Дарья. – Инженерлык лицеенда мин коллектив һәм директор ярдәмен таптым. Биредә һәр баланың хыялын тормышка ашырырлык белем бирү өчен, мөмкин булганның барысы да эшләнә. Әлеге файдалы эштә катнашуым минем өчен бик кадерле.

ЭНЕРГИЯ ТЕЛЕНДӘ

Спортның да телгә катнашы бар. Ул – энергия, көч, җиңүгә омтылыш теле. «Кечкенә мәктәптә» физкультура дәресен укытучы **Сирин Гасыймов** бу энергияне ничек уятырга һәм аны ни рәвешле дөрес юнәлешкә борырга кирәклеген белә.

– Безнең барыбызга да хәрәкәтләнү җитми, ә күп вакытын парта артында, дәрес әзерләп үткәргән балаларга – бигрәк тә. Мин үзем җәяү күп йөрергә тырышам һәм укучыларыма киңәш шуны итәм. Бу - гади һәм бик яхшы сәламәтлек коралы. Дәресләремне күп хәрәкәтләнергә кирәк булган өчен дә ярата́м. Моннан тыш, балалар спортның төрле төрләре белән таныша, аларның кагыйдәләренә өйрәнә, бу үз-үзенә һәм башкаларга карата дисциплина һәм хөрмәт тәрбияләргә ярдәм итә. Төрле юнәлешләрне сынап карыйлар, нәтиҗәдә күңелгә ятышлы спорт төрен табарга, аны җитди һәм файдалы мавыгуга әверелдерергә мөмкин. Бүген бу бик җиңел: безнең илдә спортка зур игътибар бирелә, һәм мин әлеге хәрәкәтнең бер өлеше булуыма шатмын, – ди Сирин Римгилевич.

Педагогиканы ул тәрбияләнүчеләренең ничек үсүен һәм ныгуын күрү мөмкинлеге өчен ярата. Сирин Римгилевич үрнәк булырга тырыша: күнегүләр ясау белән даими шөгыльләнә, футбол уйный, көн саен ун чакрымнан да артык юл үтә. Укытуда ул күңелне яшәртә торган энергия таба.

БИЮ – ОЧРАШУ МИЗГЕЛЕ

«Кечкенә мәктәп»не үзенчәлекле атмосфера гына түгел, һәр укучының потенциалын эзләү һәм ачу өчен тудырылган киң мөмкинлекләр дә аерып тора. Хореография студиясендә дәресләр, мәсәлән, активлык белән иҗатны берләштерә. Биредә балалар музыканы тоярга, иркен хәрәкәтләнергә, гәүдә һәм ритм гармониясен аңларга өйрәнәләр. Бию һәрьяклап үсәргә, үзеңә игътибарлырак булырга һәм үз көчеңә ышанырга ярдәм итә.

– Мин балаларның ихтыяҗларын исәпкә алырга тырышам. Аларга кызыклы формалар, уен элементлары, техникада ниндидер яңалык кирәк. Хәзер бу заманча биюләр һәм акробатика. Мин аларның кызыксынулары белән педагогик бурычларны берләштерергә тырышам, – ди ILS хореография студиясе укытучысы **Эмма Динмөхәммәтова.** – Балалар, сәхнәгә чыгып, бөтен осталыкларын җигеп биегәндә үземнең дә тәннәрем чымырдый. Алар белән шулкадәр горурланам! Хореография – төп предмет түгел, өстәмә шөгыль, ләкин алар чын-чынлап тырыша. Аларның һәрберсенең үз ритмы һәм үз юлы бар, мин аларга бу ритмны ишетергә ярдәм итәргә омтылам. Хыялым – үз бию студиямне оештыру. Бу хыялга бару өчен гел үсәргә, хата-ялгышлардан курыкмаска кирәк. Мин шәкертләремә дә шуны сендерергә телим!

КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАУ СӘНГАТЕ

Мәктәптә, инженерлык фикерләве гармониядән һәм гүзәллек тойгысыннан башка мөмкин түгел, диләр. Рәсем укытучысы **Владислав Баранов** үз шәкертләрендә нәкъ менә шушы сыйфатларны үстерә. Аның өчен сәнгать – булачак һөнәргә иҗади якын килүнең нигезе.

– Без дәрестә узганнарның барысы да – яссы һәм күләмле перспектива. Әлеге күләмне тапшыру яки төс белән эшләү – технология юнәлешендәге

мәктәп рухына бик яхшы туры килә. Бу югары сыйныфларда модельләштерү, конструкцияләү һәм башка техник дисциплиналар нигезенә салына торган классика, – ди Владислав Геннадьевич. Аның өчен укыту – барыннан да элек, фикерләүне башлап җибәрә торган диалог:

– Һәр кеше үзен ишетүләрен тели, башкаларга нәрсәдер әйтергә омтыла. Рәсем сәнгате фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Безнең фикерләр нинди? Без матурлыкны, гармонияне, кешене ничек күрәбез? Дәресләребезнең асылы менә нәрсәдә бит.

Владислав Баранов – профессиональ каллиграф. Октябрьдә Казанның «Бизон» галереясында аның «Юллар арасында» дип аталган чираттагы шәхси күргәзмәсе ачылды. Укытса да, ул остаханәдә эшләвен дәвам итә һәм иҗади планнар кора. Россия шәһәрләре буйлап йөртерлек күчмә күргәзмә өчен җитәрлек эшләр иҗат итү хыялы белән яши.

– Дюрер әйткәнчә, рәссам өчен иң яхшы ял – музыка белән шөгыльләнү. Минем өчен мәктәптә укыту шундый ук иҗади ялга әверелә, – ди Владислав Баранов. – Ял итеп остаханәгә кайткач, эшкә яңача карыйсың һәм нәрсәне төзәтергә кирәклеген күрәсең. Самими балалар дөньяга үз карашлары белән уртаклашалар. Һәм бу аралашуда без бер-беребездән нәрсәгәдер өйрәнәбез.

ШӘХЕСКӘ МӘДХИЯ ҖЫРЛАУЧЫ ХОР

Әгәр тасвири сәнгать күләмле фикерләү нигезләрен сала икән, хорда җырлау музыканы кабул итү белән тел белүне үстерү арасындагы күпер ролен үти.

– Лингвистика мәктәбендә хор – күпфункцияле белем бирү мәйданчыгы. Төрле телләрдәге репертуар белән эшләү нәтиҗәсендә балалар бер үк вакытта вокал күнекмәләрен дә үзләштерәләр, фонематик ишетү сәләтен дә үстерәләр, әйтелешне камилләштерәләр һәм сүзлек запасын баеталар, – ди сәнгать белеме кандидаты, музыка укытучысы **Алексей Баранов.** Аның өчен педагогикадагы уңыш хор яңгырашы сыйфатында гына түгел, ә һәркемнең шәхси казанышларында да күренә:

– Элегрәк оялчан булган укучының үз партиясен ышаныч белән башлавын, ә балаларның бер-берсенә ярдәм итүен, әлегә югалыбрак калучан иптәшләренә сиздерми генә булышуларын күрү аеруча рәхәт. Бу коллективның чын көчен

күрсәтә. Мондый мизгелләрдә мин укучыларымда аңлы иҗат очкыннары күрәм.

Балалар тавышының ирекле, табигый яңгыравын, аларның уртак иҗат өчен чын күңелдән шатлануын Алексей Геннадьевич үз эшенең төп нәтиҗәсе дип саный. Аның өчен иң зур бүләк – балаларның ачыш һәм казанышлары. Бала: «Мин матур җырлый һәм сәнгатьле сөйли алам», – дип әйтә икән, бу – бәхет. Т

«ТИСБИ» ИДАРӘ УНИВЕРСИТЕТЫ – ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ПАРТНЁРЛЫК АША ТӨБӘКНЕ ҮСТЕРҮ НОКТАСЫ

Заманча университет – белем бирү учреждениесе генә түгел, ә төбәк социаль-икътисадый үсешенең стратегик ресурсы да ул. «ТИСБИ» идарә университеты кеше капиталын формалаштыру, эшкуарлык активлыгын стимуллаштыру буенча стратегик бурычларны хәл итә, бу әлеге югары уку йортының Татарстан Республикасы икътисадын нығытуда турыдан-туры катнашуын раслый.

Төбәк икътисады нәтиҗәле экосистема – квалификацияле кадрлар, инновацион карарлар, эшкуарлыкка ярдәм булганда һәм мәгариф, бизнес белән хакимият арасында тыгыз элемтә урнашканда гына тотрыклы, көндәшлеккә сәләтле була. «ТИСБИ» идарә университеты нәкъ менә шушы бәйләнешне тәэмин итә дә инде.

Фото: ТИСБИ архивыннан алынды. РЕКЛАМА



Югары уку йортында студентларны укытып кына калмыйлар, ә кече бизнесны цифрлы трансформацияләүдән алып территорияләрне тотрыклы үстерү стратегияләрен эшләүгә кадәр булган реаль икътисадый бурычларны хәл итәргә сәләтле кадрлар әзерлиләр. Безнең фәнни тикшеренүләр, студент проектлары һәм эксперт инициативалары хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга, цифрлы икътисадны үстерүгә, социаль эшкуарлыкка ярдәм итүгә һәм барлык дәрәҗәләрдә идарә итү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән.

Моннан тыш, ТИСБИ төбәк программаларын (милли проектлардан алып шәһәр мохитен үстерү стратегияләренә кадәр) гамәлгә ашыруда актив катнаша. Бу университетка икътисад ихтыяҗларына җавап бирергә генә түгел, ә бирергә дә хәзерге вакытта әһәмиятле булган карарларны тәкъдим итеп, ул ихтыяҗларга алдан күреп җавап бирергә дә мөмкинлек тудыра.

Университетны төбәк икътисадына җәлеп итүнең төп ысулы – эш бирүчеләр белән системалы хезмәттәшлек итү. Бүген ТИСБИ зур корпорацияләрдән һәм дәүләт структураларыннан алып Татарстанның инновацион стартапларына һәм социаль предприятиеләренә кадәр – 150 дән артык компания һәм оешма белән эшли.

Бу партнёрлык үзара бәйле өч юнәлештә гамәлгә ашырыла.

1. БЕЛГЕЧЛӘРНЕ МАКСАТЧАН РӘВЕШТӘ ӘЗЕРЛӘҮ

Университетта студентлар эш тәкъдим итүчеләр хисабына белем ала торган махсус мәгариф программалары гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, «Җәмәгать туклануы предприятиесе белән идарә итү» профиле укытуның иң зур рестораннар челтәре «ТҮБӘТӘЙ ИК» ҖЧҖ хисабына тәэмин итә, ә Cinnabon халыкара компаниясе **«Цифрлы трансформация шартларында персонал белән идарә итү»** профиле студентларына белем бирү өчен түли. Белем бирү программалары конкрет тармак һәм корпоратив көйләнеш ихтыяҗларына яраклаша. Студентлар индивидуаль юнәлешләр буенча, еш кына эш бирүче җибәргән остазлар катнашында белем ала. Бу аларга карата ихтыяҗны арттырып кына калмый, бәлки яңа хезмәткәрне эшкә өйрәткәндә бизнеска йөкләнешне дә киметә.

2. ГАМӘЛИЛЕККӘ ЙӨЗ ТОТЫП УКЫТУ

«ТИСБИ» идарә университеты хезмәт базары таләпләренә туры килгән һәм аны тәмамлаучыларны көндәшлеккә сәләтле итә торган заманча һөнәрләрнең киң спектрын тәкъдим итә.

Белем бирү процессы **эш бирүчеләр белән турыдан-туры элемтәгә һәм практик укытуга** юнәлдерелгән, шулай булгач, студентлар югары курсларда ук һөнәрләре буенча эшкә урнаша, чыгарылыш эшләренең күп өлеше эш бирүчеләр заказы буенча башкарыла.

Практикалар, стажировкалар, уртак кейслар һәм проектлар уку процессына инде беренче курслардан ук интеграцияләнгән. «Саклык банкы», «Альфа-банк», «ICL», «Барс групп» кебек зур компанияләр университетның партнёрлары булып тора, алар базасында студентлар практика һәм стажировкалар уза, алга таба эшкә дә урнаша. Цифрлы технологияләр йогынтысында дөнья бик тиз үзгәрә, һәм бүген югары

белем алу гына түгел, ә моны инновацияләр чынбарлыкка әверелә торган мохиттә эшләү дә бик мөһим. «ТИСБИ» идарә университеты тарафыннан Россиянең цифрлы белем бирү лидеры – «Иннополис университеты» коммерциячел булмаган автономияле югары белем бирү оешмасы белән берлектә эшләнгән яңа «Мәгълүмат системалары инженериясе» бакалавриат программасының максаты – Россиядә дөнья дәрәҗәсендәге белем бирүгә ирешү.

Партнёрлыкның төп факторы – «Иннополис университеты»ның «ТИСБИ» идарә университетына югары технологияле белем бирүне сыйфатлы гамәлгә ашырырга сәләтле партнёр буларак ышанычы. Иннополис – Россиядә һәм БДБ илләрендә цифрлы белем бирүнең танылган лидеры – партнёрларны җентекләп сайлый, һәм ТИСБИның шундый университетлар сафына кертелүе безнең югары уку йортының академик һәм идарә итү компетенциясенең югары дәрәҗәдә булуын дәлилли.

Программа әзерлекнең 09.03.01 «Информатика һәм исәпләү техникасы» юнәлеше буенча гамәлгә ашырыла, һәм укуның беренче айларыннан ук IT-индустриягә туры юл гарантияләнә. Студентлар заманча технологияләр, шул исәптән ясалма фәһем, программа инженериясе, DevOps, системалы аналитика һәм уеннар эшләү дөньясына чума. Укыту рус һәм инглиз телләрендә алып барыла. Әлеге белем бирү проектын эшләүдә дөньяның иң яхшы 100 университетында IT-белгечләр әзерләүдә бай тәҗрибә туплаган гамәли экспертлар катнашкан. Бу – практикага, проект эшенә һәм базарның реаль бурычларына әзерлеккә басым ясап, халыкара дәрәҗәдә белем бирү.

Уку йөкләнешенең 40 проценттан артыгын гамәли эш алып тора, студентлар әйдәп баручы IT-компанияләрдә стажировкаларга, үз проектлары өчен бизнес-инкубаторга, дөньяның иң алдынгы университетлары белән үзара алмашу программаларына керә ала. Бу программа буенча белем алучының киң портфолиосы IT-ин-

дустриядә яхшы түләнә торган позицияләр алырга мөмкинлек бирә.

3. ЭШКӘ УРНАШТЫРУ ҺӘМ ЯҢА ЭШ УРЫННАРЫ БУЛДЫРУ

ТИСБИны тәмамлаучыларның 85 проценттан артыгы укып бетергәннән соң өч ай дәвамында эшкә урнаша – күпләр практика узган яки максатчан юнәлеш буенча белем алган оешмаларда карьерасын башлый. Моннан тыш, университет ярдәме белән ел саен дистәләгән студент стартаплары эшен башлый, алар яңа үсеш нокталарына әйләнә: хезмәт урыннары булдыра, инвестицияләр җәлеп итә һәм төбәктә инновацион мохит тудыра. Бүгенге көндә университетның 17 студенты үз стартапларын гамәлгә ашыруга грант откан.

Ел саен дәүләт югары уку йортлары белән беррәттән бюджет нигезендә укытуга дәүләт заказы гамәлгә ашырыла. 2025/2026 уку елына гына да ТИСБИ бакалавриат һәм магистратураның төп программалары буенча укыту өчен **230 дан артык бюджет урыны алган.**

Бюджет урыннары **бизнес-процессларның сыйфаты белән идарә итү** өлкәсендә белгечләр әзерләү буенча яңа бакалавр программасына, шулай ук «Яшьләр белән эшне оештыру» программасына бүлеп бирелгән, программа икътисадның барлык өлкәләренә яшь кадрларны җәлеп итүнең өстенлекле бурычын исәпкә алып төзелгән.

Традицион белем бирү программалары белән беррәттән магистратураның «Психотерапия нигезләре белән социаль-психологик консультация» юнәлеше, шулай ук **Росстатның Статистика фәнни-тикшеренү институты белән «Икътисадта статистика һәм мәгълүмат белән идарә итү» уртак магистр программасы** игътибарга лаек, ул мәгълүмат икътисады һәм статистик модельләштерү өлкәсендә белем алу өчен уникаль мөмкинлек бирә.

Нэлла Матвеевна Прусс – «ТИСБИ» идарә университетын оештыручысы һәм президенты, педагогика фәннәре кандидаты, профессор, Россия гуманитар фәннәр академиясе академигы, РФнең атказанган югары мәктәп хезмәткәре:

– «ТИСБИ» идарә университеты – белем бирү мәйданы гына түгел, ә социаль-икътисадый интегратор ул. Без бизнеска талантлар табарга, ә студентларга үз потенциалларын туган төбәкне үстерүдә файдалануга ярдәм итәбез. Хәзерге заман шартларында нәкъ менә шундый университетлар тотрыклы үсеш терәгенә әйләнә. Без яңа партнёрлыкларга ачык, чөнки бергәләп кенә – мәгариф, бизнес һәм хакимият – төбәкнең көчле, инновацион һәм социаль җаваплы икътисадын төзергә мөмкин икәнлегенә ышанабыз. ТИСБИ – гади югары уку йорты гына түгел. Бу – булачак лидерлар туа һәм төбәкне үстерү юллары табыла торган үсеш ноктасы.

«ГОМЕР БУЕ КУРЫКМЫЙЧА ФИКЕРЕМНЕ ӘЙТТЕМ!»

Руфия Фазылова

Гадәттә, без кунакларны редакциягә чакырабыз. Бу юлы исә үзебез бардык, ни дисәң дә, 90 яшькә хөрмәт белән карарга кирәк. Бүген Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы, журналист Мәдинә Маликова белән әңгәмә корабыз. Август аенда Мәдинә апаның туган көне булды. «Инде яшь кызлар кебек булмасам да, үз аягымда йөрим әле!» – ди ул. Яңалыклар, дөнья хәлләре белән танышып бара. Әле күптән түгел генә зурлап юбилеен билгеләп узды.

– Мәдинә апа, сез – үз бәягезне яхшы белүче шактый кыю ханым. Тагын безгә күренмәгән нинди сыйфатларыгыз бар?

– Дуамаллык бар, дип әйтер идем. Алны-артны бик уйлап җиткермичә, сүзне әйтеп ташлау гадәте бар миндә. Мин хаклы, дип, чын күңелдән ышанып, шунда ук әйтеп салам. Яшь чагында да бар иде андый сыйфатым, кызганыч, дияргә кирәктер, яши-яши дә бетмәде ул.

Кечкенәдән үзсүзлерәк булганмын. Һәм күп сөйләгәнмен, авызым бер дә ябылып тормаган. Телем бик иртә ачылган. Тукай шигырьләре белән ачылган, чөнки әнкәй заманасына күрә укымышлы кеше булган. Тукай иҗатын бик яраткан, нәтиҗәдә, безгә дә шуны сеңдергән. Тукай шигырьләре бит үзеннән-үзе истә кала.

Холыкка килгәндә, сизгерлек тә бар миндә. Кешене бер караштa ук абайлый алам. Журналистикада, әдәбиятта бу миңа ярдәм итте.

– Сарман районының Мортыштамак авылында туып-үскән кечкенә Мәдинә нәрсә турында хыялланды икән? Һәм аның хыяллары тормышка аштымы?

– Мин бит – сугыш чоры баласы, илдә афәт башланганда, биш-алты яшьлек кызчык идем. Иң зур хыял тамакны туйдыру булгандыр инде ул чакта.

Әйе, сугыштан соң аерым хыяллар белән яшәп алынды. Китап укырга ярата идем, кайсы герой күңелгә якын, шуңа охшарга тырышасың. Табиб та буласы килде. Ләкин әлеге һөнәрнең миңа туры килмәгәнлеген аңладым, чөнки бөтен әйберне йөрәккә якын кабул итәм. Шуңа да педагогика юнәлешен сайладым. Дөрес, Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач та, мөгаллим булып китмәдем, «Чаян» журналында эшли башладым. Тукай шигырьләре үзенекен итте – әдәбиятка мөкиббән идем.

– Әдәбиятта, бигрәк тә татар әдәбиятында хатын-кызга үз урынын табу җиңел түгел кебек. Ир-атлар тарафыннан нииндидер кимсетеп карау бар сыман... Сез дә моның белән очраштыгызмы?

– Юк, мин аны сизмәдем кебек. Гомер буе курыкмыйча фикеремне әйттем. Шул исәптән – ир-атларга да.

– Остазым дип кемне әйтә аласыз?

Фотолар гаилә архивыннан алынды

– Остазым дип күпләрне әйтә алам. Олпат язучы, шагыйрьләрдән күп нәрсәгә өйрәндем. Мисал өчен, Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев белән бер бүлмәдә утырып эшләдек. Аларның һәр сүзен сеңдереп барып, зурлап кабул итә идем. Алар янәшәсендә үземнең бәләкәй кеше икәнлегемне аңлый идем. Минем өчен ул искиткеч яхшы мәктәп булды. Тагын Атилла Расих бар иде, аннан да күп нәрсәләргә өйрәндем. Ул һөнәре буенча ветеринар, ә минем беренче әсәремдә үк ветеринар табиб турында сүз бара.

Язучыларның минем хакта: «Журналист бит ул», – дип әйткәннәрен ишеткәнем бар. Бәлки, ул сүзләрдә өлешчә хаклык та бардыр, чөнки язганым һәрвакыт көнүзәк темаларга булды.

– Әйе, Мәдинә апа, сез журналистикага да якын кеше, күп еллар «Чаян», «Сөембикә» журналларында эшләдегез. Үзегезгә күбрәк язучы дипме, әллә инде журналист дип әйтүләре ошыймы?

– Әгәр халык мине шулай дип кабул итсә, язучы исемен хуплар идем. Әмма журналист дисәләр дә ризамын, чөнки ике исем дә миңа туры килә. Укучы сине ничек кабул итә, хикмәт шунда бит. Күп китапларымны үз акчама чыгардым, чөнки алар үз-үзен аклый иде: сатылып бетеп бардылар. Ә бу инде укучыга син кирәк дигән сүз.

– Мәдинә апа, татар әдәбиятында роман язган хатын-кызлар күп түгел. Ә сез курыкмыйча, беренчеләрдән булып, батырчылык иткәнсез. Моңа кем, нәрсә этәрде?

– Аның мин башта роман икәнен белмәдем дә, бу турыда әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәр әйтте. Баксаң, миңа кадәр хатын-кызлар арасында роман язган кеше булмаган икән. Моның сәбәбен соңрак ачыкладым: хатын-кызның роман язып утырырга мөмкинлеге, вакыты булмаган. Ул чакта йөклелектән саклану чаралары юк, Аллаһы Тәгалә күпме бала бирә, шуны таба да таба... Ә өйдәге эшләр күпме! Хатын-кызның роман язарга түгел, кайчагында утырып ашарга да чамасы булмаган.

– Тукай премиясе тирәсендә ел саен ыгы-зыгы булып ала. Сез дә 2017 елда бу мәртәбәле исемне алдыгыз. Премия гадел биреләме икән?

– Дөресен генә әйткәндә, ул турыда хәзер уйлаганым да юк. 2017 елда шушы мәртәбәле исемне алдым һәм бик бәхетле булдым. Миңа аны ТР Язучылар берлеге беркайчан да бирмәс тә иде, чөнки анда премиягә чират зур... Мине премиягә ТР Журналистлар берлеге тәкъдим итте, һәм шул оешма аша алуга ирештем.

– Бүгенге әдәбият белән танышып барасызмы? Иҗатка дәрт бармы?

Язучылар җыенында.

– Юк, хәзер иҗаттан ераклаштым. Ун еллап инде. Хәер, әсәрләр язмый башлагач, әле тәрҗемәләр белән шөгыльләндем. Хәзер инде гомумән кулга каләм алганым юк. Иҗаттан туктагач, шуны аңладым: кеше яратырлык итеп язу бер дә җиңел эш түгел. Синең китабыңны эзләп табып, мавыгып укысыннар икән, әгәр андый кызыксыну булмаса, димәк, язуның да кирәге юк.

– Иҗат кешесе язмыйча тора аламы?

– Элек тора алмый идем. Басу машинкасына утырыр сәгатьләрне көтеп алганым хәтердә. Баланы, иреңне йоклаткач, рәхәтләнеп эшкә утырасың... Иң бәхетле вакыт иде ул. Ә аннан соң картлык килде. Язучылык эше бик җаваплы, авыр, башны эшләтергә, барысын да йөрәк аша үткәрергә кирәк. Ә болар – сәламәтлек бәрабәренә.


Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис белән. Камал театрында Радио көне.

ИҖАТТАН ТУКТАГАЧ, ШУНЫ АҢЛАДЫМ: КЕШЕ ЯРАТЫРЛЫК ИТЕП ЯЗУ БЕР ДӘ ҖИҢЕЛ ЭШ ТҮГЕЛ. СИНЕҢ КИТАБЫҢНЫ ЭЗЛӘП ТАБЫП, МАВЫГЫП УКЫСЫННАР ИКӘН, ӘГӘР АНДЫЙ КЫЗЫКСЫНУ БУЛМАСА, ДИМӘК, ЯЗУНЫҢ ДА КИРӘГЕ ЮК.

–«Кызыл Хач» җәмгыяте турында Казанда белмәгән кеше калмады.

– Мәдинә апа, сез бит 1990 нчы елларда Бөтентатар «Кызыл Хач» җәмгыятен оештырган кеше дә...

– Әйе, заманына күрә бик дәрәҗәле оешма иде ул. Дөресен генә әйткәндә, алай ук булыр дип уйламаган да идем. Соңрак, безнең оешма турында Казанда белмәгән кеше калмады. 1990 нчы еллар. Илдә тотрыксызлык. Максатым авыр хәлдә калган язучыларга, иҗат кешеләренә булышу иде. Районнарга барам да колхоз җитәкчеләренә керәм. Капчыклап бәрәңге, шикәр комы, ит алып кайтабыз. Анлары шуны мохтаҗрак гаиләләргә бүлеп бирәбез. Тора-бара, ярдәм сорап, ялгыз әби-бабайлар, күп балалы әниләр килә башлады. Хәлдән килгәнчә барысына да ярдәм итәргә тырыштык. 2000 нче елларда документсыз калган кешеләр күбәйде, аларның күбесе элеккеге СССР республикаларыннан иде. Аларга документ ясатырга, яки туган якларына кайтырга ярдәм иттек. Шөкер, күп изге эшләр башкарылды.

Гаиләнең түгәрәк чагы.

– Шәхси тормышыгыз турында да сөйләшсәк иде. Хәләл җефетегез Әхмәт абый Рәшитне соңгы юлга озатканда: «Ул минем өчен туган ир булды», – дип әйттегез. Әхмәт абый белән ничек таныштыгыз? Ике иҗат кешесенә бер түбә астында яшәве авыр булмадымы?

– Әхмәт белән безне әдәбият таныштырды. Ул вакытта язучылар авыллар буенча очрашулар үткәреп күп йөрде. Әнә шундый бер сәфәр вакытында Әхмәт белән якыннан аралаша башладык. Югыйсә бер-беребезне аңа кадәр дә белә идек.

Әхмәт белән кырык биш ел бергә гомер иттек. Күпләр белә инде: бу минем икенче никах. Яхшы яки начар яшәдек, дип әйтә алмыйм, төрле вакыт булды. Гаилә тормышы гел бертөрле генә бара да алмый. Шунысын гына әйтәм: йорт мәшәкатьләре, бала үстерү кебек җаваплылыкны миннән берәү дә алмады.

Әхмәт иҗат өлкәсендә миңа бик кирәк кеше булып чыкты. Мин аңа язасы әсәрләремнең сюжетын сөйли идем, ул бик кызыксынып тыңлый иде. Гомумән, иҗатыма битараф булмады. Һәм шуның өчен мин аңа бик рәхмәтле.

– Мәдинә апа, сезгә 90 яшь тулды. Бик матурлап юбилей кичәсе уздырдыгыз. Нинди хисләр белән утырдыгыз бу күркәм кичәгездә?

– Мин инде анда кунак буларак кына утырдым, барысын да ТР Язучылар берлеге үткәрде. Иң олы рәхмәтем Ркаил Зәйдуллага: үз машинасында килеп алып, озатып куеп, мине ханбикәләрчә йөртте. Хәтта миңа атап бик матур шигырь дә иҗат иткән, юбилей кичәсендә шуны укыды.

Кичә бик матур узды, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры залына хәтта кеше сыймады. Дөресен генә әйткәндә, кеше шулкадәр күп булыр дип уйламадым да.

– Тормышны яңадан үзгәртергә мөмкинлек булса нишләр идегез?

– Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Мин бик бәхетле яшәдем, дип уйлыйм: гомер юлын нәкъ уртасына басып үттем.

– Хәзер иң зур теләгегез, ниятегез нинди?

– Сәламәт булырга язсын, иң мөһиме шул. Әнкәй ун бала тапкан, бишебез исән-имин үскән. Инде аларның да икесе бакыйлыкка күчте. Энебез Чаллы шәһәрендә яши, ә ундүрт яшькә кече сеңлем Ганҗә – көн саен минем янда. Унике яшендә аны Казанга алып килдем, чөнки әткәй үлеп китте. Шул гомердән бирле бер йодрык булып яшәдек. Бәхетемә ул булган, дим, картлык көнемдә сеңелем – зур таяныч. Ни аяныч, Әхмәт белән уртак улыбыз узган ел мәрхүм булды... Олы улым Канадада гаиләсе белән яши. Әйтәм бит, әле ярый янәшәдә сеңелем бар.

игелекле эшләр

мәңгелек

акыллы гамәлләр

кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Хәлил Әбелханов татар тарихында **нинди** эз калдырган

Заһидә Бурнашева язмышы турында **нинди** фикерләр бар

Тинчурин театры артистлары **нәрсәләр** укый

Миңгәрдә **ничә** музей бар

Фото: ТР Милли музее фондларыннан, автордан

ХӘЛИЛ ӘБЕЛХАН: МЕҢНӘРЧӘ МИЛЛӘТ БАЛАСЫНЫҢ МӨГАЛЛИМЕ

Айдар Шәйхин

Әдәбият, матбугат һәм мәгариф дөньясындагы исеме аз билгеле тагын бер затка беренче мәртәбә Яңа Татар зиратында игътибар иттем. Үзәк аллея буйлап барганда, аның кабер ташы юл кырыенда ук кала һәм шунда ук күзгә ташлана. Сәбәбе – үзенчәлекле формасында. Дорик колонна рәвешендә эшләнгән таш хәзер кенотаф вазыйфасын үти: гүр иясенең кабере күптән югалган, әмма исеме язылган ташы сакланган һәм хәзер зират мигъмарияты тарихының бер һәйкәле булып юл читендә басып тора. Үткән һәр кешедән җәсәде бу зиратның кайсыдыр почмагында яткан Хәлил Әбелханга дога кылуны сорый шикелле ул...

МИЛЛИ МАТБАГАНЫ КАЙГЫРТЫП...

Ул кыска гына гомерендә – җир йөзендә 32 ел яшәргә өлгерә – укытучы, публицист һәм балалар язучысы буларак тарихыбызда тирән эз калдыра. Хәлиулла Габделвәли улы Әбелханов 1887 елда Сембер губернасының Буа өязенә кергән Шыгырдан авылында туа. Әйе, даны күп якларга таралган легендар Шыгырдан бу. Хәлиуллага шушы авылда башлангыч белемне алырга, аннары Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм Татар укытучылар мәктәбендә укырга насыйп була. Соңгысын ул 1909 елда тәмамлый һәм шул рәвешле XX гасыр башы татар мөгаллимнәре өчен классик дип саналырлык белемне үзләштерә: укыту программасының тирәнлеге белән аерылып торган җәдиди «Мөхәммәдия» дә, дәүләт каршында абруе булган укытучылар мәктәбе дә ул елларда байтак татар педагогларын әзерләп чыгара.

Мәдрәсәдә укыган елларында ул Фатих Әмирхан җитәкчелегендә эшләп алган «Мәркәз әл-ислах комитеты»на, ягъни реформа өчен көрәшүче шәкертләр оешмасына керә. 1905 елда бу комитеттан яшерен чыга торган «Әл-Ислах» газетасы оеша. Шәкертләр хәрәкәте бу елларда иң көчле ноктасына җитә, алар инкыйлаб вакыйгаларында да катнашалар, үзләренең съездларын да оештыралар. 1907 елда исә алар газетаны рәсми рәвештә чыгарырга карар кылалар. Журналист Вафа Бәхтияров, бу вакыйганы искә алып, болай дип яза:

«Әле һаман дәвам иткән шәкертләр хәрәкәтен, мәдрәсәләргә реформа кертү мәсьәләләрен яктырту өчен, татар телендә легаль газета чыгарырга рөхсәт сорап, Казан губернаторы исеменә гариза яздыру өчен, Хәлил Әбелханов белән берлектә, без хәзерге Тукай урамы 79 йорттагы балалар приютында рус теле укытучы Мөхетдин абый Корбангалиевка бардык. Ул безгә гариза язып бирде һәм шуннан соң губернатор тарафыннан рөхсәт бирелгәч, газетаны чыгарырга керештек».

Димәк, татар демократларының эшчәнлеген яктырткан, Әмирхан, Тукайларның иҗатын һәм идеяләрен үзендә чагылдырган атаклы «Әл-Ислах»ның барлыкка килүендә шәкерт Хәлил Әбелханның да өлеше бар.

ШӘКЕРТЛЕКТӘН – МӨГАЛЛИМЛЕККӘ

Мәдрәсә һәм укытучылар мәктәбен тәмамлап, тиешле дипломнарны алгач, эшле булу мәсьәләсе калкып чыга. Хәлил тиз арада укытучылык вазыйфасын намусы кушканча үти дә башлый. 1910–1912 елларда, мөгаллимлек хезмәтенә тугрылык саклап, ул туган авылыннан да, гыйлем эстәгән Казаныннан да шактый еракта урнашкан якларга килеп эләгә: хәзерге Башкортстанның Кыйгы районына караган Идрис авылының рус-татар мәктәбендә ике ел укытучылык итә. Аннан соң янә ике ел Казан губернасының Тәтеш өязе Ындырчы авылында (хәзерге Апас районы) укыта. Вазыйфасын яратып, чын күңелдән башкара. Мәктәп тормышын тасвирлаган юлларына игътибар итегез:

«Җылы кояшның ялтыраган якты нурларына күз сала-сала, калтыранып, төрлечәгә боргалап сайраган сыерчыкларның колакны ярып керә торган үткен тавышларын тыңлап, Аксу урамы буйлап, балалар

мәктәпкә җыелалар. Алар шатлана-шатлана мәктәпкә керәләр. Яшелгә буяган, тимер түбәле зур яңа мәктәп балаларны ачык йөз белән каршы ала... Тышта якты булса, минем эчемә дә якты; тышта хәзер генә яз булса да, минем эчемдә берөзлексез яз дигән кебек балаларны җыя иде.

Менә сәгать 8 булганда, мәктәп эче гөж итә; уйный, сөйләшә, укый, җырлый торган балалар белән кайный, мәктәп кырмыска оясына яки умартага охшый. Мәктәпкә пакь җанлы, пакь тәнле, ак йөзле «фәрештә валчыкларының» тормышы кайный.

Мөгаен, Хәлил Әбелхан мәктәп-мәдрәсәләрдә укытуын инкыйлабка кадәр дә, аннан соң да дәвам иткән булыр иде. Әмма 1914 ел җитә. Европа илләренең дистә ел буена барган империалистик көндәшлеге аркасында, дөнья сугышы ялкыны кабына. 1915 елда 28 яшьлек Хәлиулла да гомуми мобилизациягә эләгә. Рус телен мәктәптә балаларга өйрәтерлек дәрәҗәдә яхшы белгәнгә күрә, аны гади солдат кына итеп алмыйлар, прапорщиклар мәктәбендә әзерлек үткәрәләр. Сугыш елларында ул «Кояш» газетасының фронттагы хәбәрчесе дә булып тора.

ТАТАР ДЕМОКРАТЛАРЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕН ЯКТЫРТКАН, ӘМИРХАН, ТУКАЙЛАРНЫҢ ИҖАТЫН ҺӘМ ИДЕЯЛӘРЕН ҮЗЕНДӘ ЧАГЫЛДЫРГАН АТАКЛЫ «ӘЛ-ИСЛАХ»НЫҢ ПӘЙДА БУЛУЫНДА ШӘКЕРТ ХӘЛИЛ ӘБЕЛХАННЫҢ ДА ӨЛЕШЕ БАР.

Шулай итеп, Хәлил Әбелханның яшьлек елларына укытучы һөнәрен башкару да, хәрби хезмәттә булу да, ил тарихында иң хәсрәтле сугышларның берсендә катнашу да туры килә. 30 яшен тутырган чагында исә илдә моңарчы тиңе булмаган үзгәрешләр башлана. 1917 елның августында яраланган Хәлил Әбелхан фронттан кайта. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соң, ул Казанда өяз күләмендәге мөселман мәгарифе бүлеге рәисе булып эшли, яңа хөкүмәт шартларында мөгаллимнәр әзерләү һәм мәктәпләр оештыру эшләренә җитәкчелек итә.

1917 елның 29 маенда чыга башлаган «Безнең тавыш» исемле хәрби газетаның редколлегиясенә керүчеләр арасында Хәлил Әбелхан да була.

ҖӘДИТЛӘРНЕ МАКТАВЫ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЛӘВЕ

Хәлил Әбелхан, белем бирү тәҗрибәсен яхшы белгән кеше буларак, шул чор татар мәктәпләренең методикасын камилләштерүгә үз өлешен кертергә омтыла. Чыннан да, мөгаллим мәктәпләрдә җәдит ысулларын гамәлгә кертүне яклый, заманча методиканы популярлаштыра, шул ук вакытта көндәлек тәҗрибәдә очраган кайбер хаталарны да тәнкыйтьли. Җәдитчелек хәрәкәтенең аерым җитешсез якларына багышланган «Ысулы җәдиткә каршы беренче адым» исемле китабы 1911 елда ук басылып чыга.

«Мәктәп» һәм «Мөгаллим» журналларында бастырылган мәкаләләрендә аның бу мәсьәләгә карашы тагын да яхшырак ачыклана. Мәсәлән, ул башлангыч сыйныфларда укырга-язарга өйрәтү белән беррәттән, балаларны табигать белән таныштырырга кирәклеген искәртә. Хәзерге вакытта мәктәп укучылары өйрәнә торган әйләнә-тирә дөнья дәресе турында яза инде ул:

«Безнеңчә, дәрес мөгаллимнең балалар берлә кара-каршы әңгәмәсеннән һәм аларга һәрнәрсәне аңлатып бирүеннән гыйбарәтдер. Башта, әлбәттә, бик кечкенә нәрсәләрдән башларга мөмкин. Берникадәр физически тәҗрибәләр бөтен сыйфныфта җәдит рухын кертергә, балаларда һәрнәрсәне беләсе килү теләген уятырга ярдәм итәчәк».

Әдәбият белән бәйле шәхес буларак, ул мәктәптәге татар теле дәресләренең бер өлешен әдәбиятка багышларга кирәклеген дә әйтә. «Әлбәттә, һәр милләт баласы үз әдәбиятының таралуын яратырга тиеш», – дип әйтә ул 1912 елгы мәкаләсендә. Әмма мәктәптә әдәбият белән танышу эшен дөрес итеп корырга кирәклегенә дә басым ясый, чөнки, аның карашынча, дәрестә укучыга «акыл вә фикер» бирергә кирәк. Димәк, әдәбият уку да теоретик гыйлем бирү генә түгел, әсәрне анализлау, авторның идеяләрен төшенергә омтылудан гыйбарәт булырга тиеш.

Дөрес, Әбелханның тел һәм әдәбият мәсьәләсендә үзенчәлеклерәк карашлары да булган. Галимҗан Ибраһимов, әдәби тел турында барган дискуссияләр турында язган чагында, матбугатта мәкаләләре еш күренгән Хәлилнең бердәм кагыйдәләргә буйсынырга тиешле гомуми татар теле турындагы фикерләрен тәнкыйть итә. Аныңча, Әбелхан бу бердәмлек һәм грамматика төзеклеге турында кайгыртмый.

1913 елда «Мәктәп» журналында басылган «Америкада тәрбия вә тәгълим» исемле мәкаләсендә Хәлил Әбелхан Төньяк Америкада таралган тәрбия системасын анализлый. Соңрак шушы ук темага «Америка мәктәпләрендә хезмәт дәресләре», «Башлангыч белем бирүдә Америка ысулы», «Америка ысулы буенча укырга өйрәтү» исемле мәкаләләре басылып чыга. Моның алдыннан ул бер-

ничә ел дәвамында Америка системасын җентекләп өйрәнә. «Мәсьәләне ике ел кадәр һәр җәһәттән бик нык тикшереп вә өйрәнеп язылган хезмәт – баш ватуның нәтиҗәсе», – дип әйтә ул кереш сүзендә. Шунысы кызык: мәкаләнең башында ул эзләнүләрендә кулланган чыганакларның җентекле исемлеген китерә. Болардан без Әбелханның үз эшенә ничек җаваплы караганын һәм фәнни анализ ысулларыннан файдаланганын аңлыйбыз. Аның игътибарын Америка мәктәпләрендә кабул ителгән укырга өйрәтү методы җәлеп итә, ул аны җәдитләрнең ысулыннан яхшырак дип таба. Шулай ук аңа ул ил мәктәпләрендәге физик тәрбия һәм хезмәт дәресләре тәҗрибәсе отышлы булып күренә. Әмма Әбелхан чит ил белән сокланып кына утырмый, ә бәлки татар мәдрәсәләренең хәлен яхшырту өчен бу методиканы куллану юлларын да эзли. Ул американыларның мәгарифтә уңышын тәрбия системасының өч өлештән торуы белән бәйли: өй тәрбиясе, мәктәп тәрбиясе һәм җәмәгать тәрбиясе. Өч тармак, үзара нык бәйләнешеп, берсе икенчесен дәвам иткәнгә күрә, балалар белән эшләү күркәм нәтиҗәләрен дә бирә. Чыннан да, XX гасыр башы татар педагоглары белем һәм тәрбиянең мәктәп белән генә чикләнмичә, бу эшкә гаиләнең дә, бөтен җәмәгатьчелекнең дә тиешле игътибары кирәклеген кат-кат әйткәннәр. Әбелхан моның мөһимлеген АКШ мисалында күрсәтә алган.

۳ نچی سان. ۲٦ نچی جمادی الآخر ۱۳۳۱ سنه. ۲۰ نچی مای ۱۹۱۳ سنه.

مرحوم شاعربز عبدالله توقايف طوغروسنده.

کوبته توگل، ئه‌لی بوندن آی يارمغنه ئلك، سويکلو شاعر بز عبدالله افندی توقايف بزنك بله‌ن برگه‌ايدی... دوست، اول بيك قاتی آوری ايدی؛ شولای بولسه‌ده ـ بزنك اوچون کوکللی، مانور هم هر کم آکلارلق ايندروب يازغان شعرچيکارن دنياغه چغارودن طوقتامی ايدی. آورو باشن آق مامق ياصدقغه قويغان کيلش، صوکغی صولشلرون آلا ـ آلا اول، بيوك هم سويکلی شاعربز، بزنك اوچون قايغرا، بزگه تورلی شعرلر يازا ايدی.. منه آنك دنياده طورو ساعتی طولدی.. ۲ نچی آپريلده کيچ قرون، سيگز ساعت ۱۵ مينوتده دنيانی تاشلادی هم بزنی، طوغانقايلارم، بار بزنيده يتيم قالدردی.. سويکلو شاعر بز عبدالله افندی توقايف ئولدی... لکن اول، سلامت چاغنده‌غی توسلی، بزگه کوب ياخشی سوزلر ايتوب، کوب مانور هم کوکللی شعرلر يازوب ئولدی. کچره‌کنه بويلی، بينکه يابق، بر کوزی ضعيفره‌ك هم توسکه‌ده بيك مانور توگل ـ شاعر بزنك ـ کوکلی يومشاق، يوزی کوله‌چ، طورا طورغان بولمه‌سينك ايشکی هر کم اوچون آچق ايدی... اول، آق صافاللی قارتنی‌ده، ئوسوب کيله طورغان ياش بالالارنيده برده‌ی سويه ايدی!...

БАЛАЛАР ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ ТУДЫРУЫ

1912 елдан Хәлил Әбелхан атаклы «Шура» журналында, мәгариф-тәрбия эшләренә багышланган «Мәктәп» һәм «Мөгаллим» журналларында, «Йолдыз», «Кояш», «Корылтай» газеталарында актив язышa.

Фәхрелислам Агиев җитәкчелегендә 1913–1916 елларда дөнья күргән балалар өчен «Ак юл» журналының да актив авторы буларак билгеле. Биредә Хәлил Әбелханның балалар өчен җәнлекләр турындагы хикәяләре басыла. Мәсәлән, аның «Туйдыручы ак сакал», «Карт үрмәкүч», «Ак борын», «Киез каз бәбкәсе», «Коткаручылар», «Дуслык бетте», «Яшь бабай» дигән хикәяләре нәкъ менә «Ак юл»да басыла. Журналның гомуми концепциясенә тугры булган бу хикәяләрендә язучы балаларда шәфкатьлелек хисен тәрбияләргә тырыша. Әсәр геройлары булган балалар үзләреннән кечерәк, ярдәмгә мохтаҗ җан ияләренә мәрхәмәт күрсәтә. Шушы мисаллар аша ул журнал укучыларына дөрес үрнәк бирергә тели.

Бу хикәяләр «Ак юл» журналы бастырган әдәби хрестоматияләрдә кабаттан дөнья күрә. 1921 елда исә «Балалар күңеле» сериясендә «Ак борын» хикәясе яңадан бастырыла.

1918 ел ахырында Хәлил Әбелхан каты авырый башлый. Озак та үтми, 1919 елның 6 гыйнварында ул Казанның Шамов хастаханәсендә вафат була. Аның турында некролог «Эш» газетасында 8 гыйнвар санында чыга, башка матбугат чаралары да аның вафаты хакында хәбәр итә.

Замандашларының аңа булган мөнәсәбәте кабер ташындагы язудан күренә. Әле бүген дә иске имляны таныган кеше Хәлил Әбелхан хакында менә бу юлларны укый ала:

«Бөтен гомерен татар милләтен агарту юлында сарыф иткән Хәлил Габделвәли угылы Әбүлхан 1919 елның гыйнвар 6 сында 32 яшьтә вафат. Мәрхүмнең кыскача хаятенең мөндәриҗәсе милләт балаларына тәрбия вә тәгълим һәм алардан тормыш өчен көрәшчеләр җиткерү. Мәрхүмнең калдырган мирасы – гыйлем юлына керткән меңнәрчә милләт балалары».





«ҖӘҺӘННӘМ ГАЗАПЛАРЫ КҮРГӘН БЕР КЫЗЫН ХИМАЙӘГӘ МИЛЛӘТНЕ ЧАКЫРАМ...»

Луиза Янсуар

XX йөз башы вакытлы матбугатында шигырьләре «Гыйффәт туташ» тәхәллүсе белән басылган Заһидә Бурнашева шәхесе вә язмышы гаять үзенчәлекле. Бу язмыш ул чорның феминистик хәрәкәте һәм хатын-кызлар эмансипациясе белән бәйләп киң тарихи полотнода да карала ала, әдәбиятта феноменаль күренеш булып, яңа баш калкыткан шагыйрәләр плеядасы барлыкка килү фокусында да үзенә бер урын тота. Шагыйрә, прозаик, публицист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, аның биографиясе Россия – Татарстан җирлеге генә түгел, ә Урта Азия белән дә бәйле.

Фотолар: ТР Милли музее, ТР Милли китапханәсе, mincult.tatarstan.ru сайтыннан алынды

ДӨНЬЯНЫ ЯУЛАГАН ҺӘМ ТОТКАН ХАТЫН-КЫЗЛАР

Әдәбият аренасына «Гыйффәт туташ» тәхәллүсле шагыйрә килгәндә, татар хатын-кызлары арасында инде мәдрәсәләр, аерым мәктәп-курсларда гына түгел, ә Мәскәү, Петербург, Европаның мәртәбәле уку йортларында чит телләрдә затлы белем алган плеяда формалашып килгән була. Казанда гына да Мәһруй Барудия, Ләбибә Хөсәения, Мәһруй Мозаффария, Фатиха Аитова мәктәпләре эшли. Матбугатта хатын-кызлар мәсьәләсенә кагылышлы мәсьәләләр киң яктыртыла. Хәтта хатын-кыз псевдонимы белән бу темага кагылышлы язмалар белән әсәрләрне бастыру очраклары да күренә. 1913 елның октябреннән «Сөембикә» журналы дөнья күрә башлый.

Хатын-кызлар эмансипациясе бары тик зур калаларны Казан, Җаек, Оренбург, Уфа һ.б.ны гына колачлап калмый, ә милли тормыш кайнап торган төбәкләрдә дә җәелә. Россия картасындагы шундый җирлекләрнең берсе – Рязань губернасы. Биредә татар сәүдәгәрләре һәм зыялы катламы яши, аларның Россия шәһәрләре белән генә түгел, ә Көнчыгыштан алып Көнбатышка хәтле сату-алу бәйләнешләре җайга салынган була. Юкка гына беренче хатын-кыз табиб Разыя Котлыярова, математик Сара Шәкулова да бу яклардан чыкмагандыр, дип фаразлый кайбер тарихчылар. Сүз уңаеннан, Сара Шәкулованы хәтта «Парижны алган беренче татар хатын-кызы» дип тә атыйлар.

Мондый шартларда хатын-кызларның әдәбиятка һәм сәнгатькә килүе табигый, әлбәттә. Мәһруй Мозаффария «Казан мөхбире», «Әл-Ислах», «Сөембикә» белән хезмәттәшлек итә, шигырьләрен, мәкалә-хикәяләрен бастыра. Сания Гыйффәт Уфадагы «Тормыш» газетасында шигырьләре белән даими күренә башлый. Кайберләренең язмышы, яңа «кызыл хәрәкәт»нең иске кануннардан азат булу омтылышы белән кушылып китеп, табигый рәвештә аларны совет системасына яраклаштыра. Шундыйларның берсе – беренче шигырьләре «Ил», «Сүз» газеталарында дөнья күргән, иҗатын шул чор әдипләре дәррәү күтәреп, хуплап каршылаган Заһидә Бурнашева.

«ТУКАЙ АБЫЙ: «ҺАМАН, ҺАМАН АЛГА БАР», – ДИ...»

Без аны әдәбият тарихында Гыйффәт туташ буларак беләбез. «Гыйффәт туташ» тәхәллүсе инкыйлабка кадәрге мохиткә туры килеп, табигый яңгыраса, «яңа тормыш» төзүгә, искелек, буржуазия калдыкларын себереп түгүгә йөз тоткан совет иленә, билгеле, үз исем-фамилиясе кулайрак җайлаша. Совет чоры җыентыклары һәм энциклопедияләрендә ул «совет-татар шагыйрәсе» буларак теркәлеп калган.

Заһидә Бурнашеваны беренче каләм тибрәткән үрнәкләреннән үк «Тукай мәктәбе»нә нисбәтлиләр, ул үзе дә «Тукай оясыннан очып чыккан карлыгачларның берсе» булуын беркайчан да инкарь итми, киресенчә, аның эзеннән баручылардан булуын гел раслый. Бер шигырендә, Тукайга багышлап, мондый юллар да яза:

Тукай абый: «Һаман, һаман алга бар, – ди,-
Юлда манигъ (киртә) күрсәң, тибеп аудар аны,
Яшь шагыйрьгә курку, өркү харам ул», – ди.

ЗАМАНА ГЫЙСЪЯНЫ, ЯКИ ИРЕК СИМВОЛЫ

Гыйффәт туташ 1895 елда Рязань өлкәсенең Әҗе авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Татар сүз сәнгатен яхшы белү өстенә, русча иркен аралашкан кыз чит ил әдәбияты үрнәкләре белән дә таныш була. Матбугатта әсәрләре басылып, чордаш әдипләре белән язышу факты ачыклангач, әти-әнисе аның дәфтәрләре белән китапханәсен яндыра, Заһидәнең үзен өйдә бикләп тота башлый, дус кызлары белән аралашудан тыя. Яңа тормышка омтылу ыргылышы белән әнисенең бәргәләнүләре арасындагы бу каршылыкны соңрак шагыйрә «Әнигә хат» дигән поэтик триптихында тасвирлый:

Беләм, әнкәй, беләм, авыр сиңа.
Миндән күп өмидләр иткәнсең:
Бай йортлардан килгән яучыларны,
Туйларымны өзлеп көткәнсең.
Казан-табак, аш-су тирәсендә
Маугып гомер итәр дигәнсең;
Дин-гадәтләр колы – тыйнак кына
Бер абыстай булыр дигәнсең.

Заһидә әле моннан бер гасыр элек «пиар»ның иң хәтәр дә, бер үк вакытта искиткеч үтемле дә ысулын куллана – гыйсъянга барып, туган шартларны үз файдасына бора. Үз өеннән качып китеп, хәлләрнең ничек булуы хакында үз карашын матбугатта ачыктан-ачык белдерә. Гәрчә әти-әнисе аның качып китү фактын: «Патшага каршы кешеләр оешмасында эшләү өчен, авылдан китә», – дип аңлаткан булса да.

Әлбәттә, күп еллар дәвамында ата-ананың бу шикаяте аларның ни дәрәҗәдә артта калган, кадыйми затлар булуына ишарә итеп, негатив бәяләнеп килде. Үз баласының өстенә яла ягу, аны иске тормыш зинданына ябарга теләү буларак каралды. Әмма шуны да истә тотарга кирәктер: гомер-гомергә сәүдә итеп, тормыш-көнкүрешен билгеле бер эзлеклелектә күрергә ияләшкән Бурнашевлар өчен кыз балаларының туган йорттан җәнҗал ясап чыгып китүе, большевикларга иярүе, коммунистик идеяләргә йөз тотуы,

«Минем гөнаһсызлыгымны, языксызга вә залиманә бер сурәттә түктерелгән күз яшьләремне күрә торып та, минем залимнәр тырнагы арасында чытырдавымны ишетеп тә, миңа Әҗе тарафындан бер мәрхәмәт иясе чыгып, үзенең шәхси мәнфәгатьләрендән, шкурасындан вөҗдан вә инсаниятне артык күрүче табылмагач, үземнең рәнҗетелгән йөрәгемне, мәзлуманә түгелгән яшьләремне матбугат аркылы милләткә аңлатып, үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр җәһәннәм газаплары күргән бер кызын химайәгә милләтне чакырам».

Заһидә Бурнашева, «Мәрхәмәт наменә бер үтенеч»
(«Өмет йолдызлары» китабыннан)

Заһидә Бурнашева авторлыгындагы фәнни җыентык.

үзе тәрбияләнеп үскән җирлекне тулаем инкарь итүе, чынлап та, зур фаҗига булырга мөмкин ләбаса.

Әмма илдә яңа тормыш белән яңа хакимият төзиләр, анда, әлбәттә, иске тормыш элементларына урын юк. Шуңа да Заһидә Бурнашева хакыйкате өстен чыга, ул үзе искелекне, караңгы залим тормышны җиңеп чыгу, ирек символына әверелә. Басмадагы хаты да укылып, ятланып бетә, чор кызлары өчен культ рәвешен ала.

Әнкәсенең: «Ул минем акчаларымны урлап чыга торгандыр!» – дип, бөтенесе алдында тентетүен, приставка жалу биреп, караклыкта гаепләвен, икенче көнне барып: «Кызым Төркиягә, фәхешханәгә кача», – дип, волость идарәсенә язып бирүен дә фаш итә Заһидә. Аңлашыла ки, бу җан авазы берәүне дә битараф калдырмый. Татар дөньясының алдынгы карашлы вәкилләре шагыйрәгә бар җәһәттән, шул исәптән матди яктан да, иҗади планда да ярдәм кулы суза. «Гыйффәт туташ шигырьләре» исеме астында аның бер-бер артлы өч мәҗмугасы дөнья күрә. Шигырьләр тиз арада укучысына барып ирешә, гаять зур популярлык казана.

Әлеге драматик вакыйгаларга үз карашын белдергән галимнәр арасында Тәэминә Биктимерова да бар. Ул мондыйрак фикердә тора:

– Көчләп чукындырулардан интеккән халыкның иманына туры бер вәкиле, ягъни Заһидәнең әнисе кызының күрше авылга йөреп укуына, шигырьләр язуына риза булмый. Урысча укыса, кызы «марҗа» булыр дип курыккан ана гаҗизлектән газиз баласының шәхесенә, намусына тиярдәй каты сүзләр дә әйтә. «Гыйффәт туташ» тәхәллүсен Заһидә нәкъ менә шул хаксыз сүзләргә җавап рәвешендә ала. Бу хакта ул 1915 елның 6 сентябрендә «Вакыт» газетасында басылган ачык хатында әйтә, шул исем белән дөньяга чыга.

Ягъни, «намусым пычранмаган» дип, әнисенә җавабын да ул киң җәмәгатьчелек алдында бирә.

МӘСКӘҮ – ТӨРКЕСТАН – БУА – КАЗАН

1917 елның апрелендә Казан шәһәрендә үткәрелгән Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаена Пермь шәһәрендәге кызлар мәдрәсәсе мөгаллимәсе Гыйффәт туташ танылган шагыйрә буларак чакырыла. Тарихта беренче тапкыр үткәрелгән бу мәртәбәле мәҗлестә ул докладлар буенча фикер алышуларда катнаша, хатын-кызларның гаиләдә тоткан урыны, юридик хокуклары хакында карарлар чыгару өчен төзелгән комиссиягә сайлана. Мәскәүдә җыелган I Бөтенроссия мөселманнары съездында да чыгыш ясап, Казанда үткән Мөслимәләр мәҗлесенең карарларын мөнбәрдән җиткерә. Нәкъ менә биредә язмышын төптән

Урта Азиядә эшләгән чор.

үзгәрткән вакыйга була. Корылтайда Төркестан вәкиле татарлардан мәгариф өлкәсендә ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Заһидә, бу мөрәҗәгатьне кабул итеп, үз теләге белән Төркестанга китә.

1918 елдан ул Сәмәркандтә үзбәк телендә чыга торган «Хезмәт ияләре тавышы» («Мехнаткашлар говуши») исемле газетада мөхәррир булып эшли. Соңрак аны Каттакурган өязенә җибәрәләр, анда 1919 елга кадәр халык мәгарифе бүлеге мөдире урынбасары вазыйфасын башкара. 1919 елда Төркестан коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты каршындагы хатын-кызлар бүлеге, оештыру сәләтен һәм белемен исәптә тотып, Заһидә Бурнашеваны Ташкентка күчерә. Ул Иске Ташкент шәһәрендә беренче хатын-кызлар мәктәбен ача, хатын-кызлар өчен оештырылган төбәк педагогика курсларын җитәкли. Тора-бара курслар Хатын-кызлар мәгариф институты булып үзгәртелә.

Заһидә Төркестан халыкларының телләрен үстерүгә, хатын-кызларның тормыш шартларын яхшыртуга күп көч куя. Аның тырышлыгы белән мәктәпләрдә ярдәм атналары оештырыла. 1920 елда Төркестан хатын-кызларының I корылтаенда Төркестан фронты командующие Михаил Фрунзе чыгышын үзбәк теленә тәрҗемә итү аңа йөкләнә. Ул ТКП ҮКның хатын-кызлар бүлеге мөдире, РКП (б) ҮКның хатын-кызлар бүлеге инструкторы булып эшли, партиянең Төрекмәнстан өлкә комитеты каршындагы хатын-кызлар бүлекләрендә төрле вазыйфалар башкара.

Утыз яшенә дә җитмәгән кызның җаваплы эшләре моннан кала да әйтеп бетергесез: Ташкентта Урта Азия коммунистик университет лекторы, хатын-кызлар институтының укыту эшләре мөдире, Урта Азия ефәк сәнәгате техникумы директоры, Үзбәкстан дәүләт нәшриятының сәяси мөхәррире... Бу елларда ул Мәскәүдәге юридик институтта читтән торып белем ала. Диплом алгач, Кыргызстанга күчә. 1933 елдан 1951 елга кадәр Кыргызстанда партиянең җаваплы вазыйфаларында хезмәт куя.

Инструкторлар Урта Азия җирлегендә хатын-кызлар арасында зур пропаганда эшчәнлеге алып бара. Аларның көнкүреш шартларын яхшырту, белемнәрен арттыру, мәктәпләр өчен әсбаплар, методичкалар эшләп чыгару, хезмәт урыны белән тәэмин итү h.б. Нәтиҗәдә, биредә менә дигән кадрлар үсеп чыга, педагогика, әдәбият, сәнгать, фән өлкәсендә алгарыш барлыкка килә. Идел һәм Урал буеннан ачлыктан коткару өчен күчерелгән кешеләргә дә актив ярдәм оештырыла, балалар йортлары белән интернатларны кайгыртуга зур игътибар бирелә.

1951 елда Заһидә Бурнашева кире Татарстанга әйләнеп кайта. Башта ул Казанда түгел, ә Буада төпләнә. Тәрбиягә алган кызын да үзе белән ияртеп алып кайта. 1956 елда Казанга күченә. Гомере буена хыяллан-ган, тик җаваплы эшләрдә эшләп гел кулы җитмәгән язмасына тотына – татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихын бәян итәргә керешә. Ул хезмәт 1971 елда дөнья күрә.

Заһидә Бурнашева шигырьләре.

Заһидә Бурнашева Урта Азиядә җаваплы вазыйфалар башкарган елларында «Гыйффәт туташ» исеме әдәби-мәдәни дөньядан югалып тора. Шигырьләр бастырмый, партия эшен башкарганда, үзен шагыйрь буларак билгеләми. Әмма кайбер әдәбият галимнәре фикеренчә, асылда, Заһидә Бурнашева иҗаттан беркайчан да туктамаган.

– Заһидә Бурнашева революциягә кадәр язган шигырьләрен, туган ягына әйләнеп кайткач, бигрәк тә Казанда яңадан төпләнгәч, заманга яраклаштырып үзгәртергә дә тырышкан, – ди әдәбият галиме, текстолог Зөфәр Рәмиев. – Бүген безгә аларны үзара чагыштырып өйрәнү, Гыйффәт туташ фигурасына заман күзлегеннән яңача караш ташлау бик кирәк...

Бу җәһәттән шагыйрьнең яшьлек максимализмы белән өретелгән тагын бер шигыре искә килеп төшә:

Ялтырачы күктә, өмид йолдызым,
Сиңа бит төбәлгән минем күңлем күзе.
Кайгыларымны тараттырган да син,
Алга рух берлән караттырган да син.
Ялтыра, дим, миңа күрсәт тугъры юл,
Алга бастыр – син миңа ярдәмче бул!

Яшьлегендә үзе эзләгән әнә шул «өмид йолдызы» миссиясен, асылда, гомере буена бик күпләр өчен үзе үтәп яши Заһидә Бурнашева. Безгә, һичшиксез, аның язмышын әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе.

«ӘДӘБИЯТ, ТЕАТР, ЖУРНАЛИСТИКА – ХАЛЫК БЕЛӘН ЭШЛӘҮДӘ БИК КӨЧЛЕ ӨЧ КОРАЛ»

Фото: Резедә Сәлахова һәм Артём Пискунов архивыннан

Тинчурин театры яңа биналы булып, бу матур пар артистлар «яңа йорттагы» премьераларда төп рольдә тамашачысын куандырган чорда, форсаттан файдаланып, гәпләшеп алдык. Резедә Сәлахова белән Артём Пискунов күп укый, әдәби әсәрләрне тавышландыра, татар кино сәнгатендә милли классикада экран тота.

Луиза Янсуар

– Балачак китапларыгыз нинди?

Резедә Сәлахова: Гаиләдә 4 яшькә олырак апам Миләүшә белән үстек. Әни күбрәк кызларга кагылышлы китаплар ала иде: «Энциклопедия для девочек», мультгеройлар төшерелгән «Энциклопедия кухни». География, биология, астрономия энциклопедияләренә нигезләнеп, рефератлар язарга ярата идем. Шулай берсендә китапханәче апа, урамга куып чыгарырга кыенсынып: «Ярар, рефератыңны язуыңны дәвам ит, бала, мин төшке ашка кайтып килəм», – дип, китапханәдә утыртып, бикләп калдырды. «Әбүгалисина мәгарәсе» кебек булды ул миңа.

Артём Пискунов: Иң исемдә калганы – «Я познаю мир» күптомлы энциклопедиясе. Анда җәнлекләр, галәм, илләр, машиналар һ.б. бик күп нәрсәләр турында иде. Бик кызыксынучан бала булсам да, баштарак матур әдәбиятны укырга яратмадым. Югыйсә укытучы баласы. Чын-чынлап матур әдәбиятны укырга рус теле, әдәбияты укытучым Надежда Михайловна Юмагулова өйрәтте. Китапка мәхәббәт тәрбияләгән икенче остазым – Рәшит Заһидуллин. «Аңгыра артистны сәхнәдә бер километрдан ук күреп аласың», – ди иде. Бик күп китаплар биреп укытты. Беренче кулга тоттырган китабы – Гарсиа Маркесның «Сто лет одиночества» әсәре.

– Иң беренче хәтерләгән китабыгыз?

Резедә Сәлахова: Укырга 6 яшемдә кердем, аңа кадәр әни: «Әйдә, кызым, «Әлифба»ны өйрәнә башлыйбыз», – дияргә кереште. Бу процесстан гел качу ягын карый идем. Юклык заманасы, бөтен акча өй төзергә кереп бара. Шунда әни сорады: «Кызым, «Әлифба»ны өйрәнер өчен, сиңа нинди стимул кирәк?» Әйтеп салганмын: «Сез миңа Барби да алып бирмәдегез әле!» Шуннан аягы-кулы бөкләнә торган Барби алып кайттылар. «Әлифба»ны һәр кичне берәр бит укый башладык. Апам белән Киров районының 4 нче татар гимназиясенә укырга бардык. 1 сыйныфка укый белеп кердем.

Артём Пискунов: «Кот в сапогах» дигән китап: аны ачып җибәрәсең... сарайлар калкып чыга, геройлар аягүрә торып баса. Театр кебек китап иде ул!

– Сезне нинди китап формалаштырды?

Резедә Сәлахова: Һәр укыган китап – ошыймы-юкмы – сине үзгәртә. Ошамаса, сайларга өйрәтә, зәвыгыңны яхшырта. Ошаса, дөньяга карашыңны формалаштыра.

Артем Пискунов: Бөтен укыган китаплар да, мөгаен. Нинди генә китапны укысам да, үзем өчен яңа мәгълүмат алып, күңелгә киртләп куям.

– Иң зур тетрәнү китергән китап?

Резедә Сәлахова: Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте. 6 сыйныф баласы идем. Мин аны курка-курка, үкси-үкси укыдым.

Артём Пискунов: Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» һәм Варлам Шаламовның «Колымские рассказы». Параллель укыдым. Алар кичкән газап-михнәтләрне йөрәгем аша уздырып, бик тетрәндем. Заман язучыларыннан Халед Хоссейниның «Бегущий за ветром», «Тысяча сияющих солнц» әсәрләре.



– Китап уку өчен сезгә аерым бер халәт, көйләнеш кирәкме? Бәлки, урын?

Резедә Сәлахова: Юк, кирәкми, әмма тынычлыкта укуы рәхәтрәк инде.

Артём Пискунов: Нишләргә белмәсәм, күңелемне кая куярга урын тапмасам, берәр китап алып укыйсы килә башлый. Вакыт заяга уза кебек тоелганда да – шулай.

– Милли классика һәм заман әдәбиятыннан кемнәрне югары бәялисез?

Резедә Сәлахова: Прозаиклардан – Гаяз Исхакый, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев. Шагыйрьләрдән – Хәсән Туфан, Фәнис Яруллин. Бүгенге заман әдипләренә килсәк, шагыйрьләрдән – Рәдиф Гаташ, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Луиза Янсуар, Гөлүсә Батталова; прозаиклардан – Марат Әмирханов, Рөстәм Галиуллин, Ландыш Әбүдарова.

Артём Пискунов: Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах... Берсен дә төшереп калдырып, аерып куясы килми, әлбәттә. Әмма шулай да, иң яраткан язучым ул – Нурихан Фәттах, аның тарихи романнары. Хәзергеләрдән Зөлфәт Хәким, Марат Кәбиров әсәрләрен яратам.

– Дөнья әдәбиятын күзәтеп барасызмы?

Резедә Сәлахова: Заманында, театр училищесы белән КФУда укыганда, чит ил классикасы һәм рус әдәбияты шактый укылды. Шулай да күбрәк татарча әсәрләр укырга яратам. Башка телдә укыганда, китап ул кадәр бөтереп эченә алып кереп китми, үз телемдә уку – җайлырак та, ләззәтлерәк тә, тәмлерәк тә.

Артём Пискунов: Аерып кына күзәтеп бармыйм. Әгәр берәрсе, миңа бу китап кызык, дип әйтә икән, табып алам, укыйм, билгеле. Кайчак үзем дә яхшы китапка юлыгам.

– Әдәбиятның милли йөзебезне, менталитетыбызны саклаучы булуы белән килешәсезме? Ул үзенә, чынлап та, мондый вазыйфаны алырга тиешме?

Резедә Сәлахова: Һичшиксез! Гомумән, әдәбият, театр, журналистика – халык белән эшләүдә бик көчле өч корал. Әдәбиятта затлылык булсын, сәхнәгә теләсә нинди әсәрләр менмәсен, телевидение, радио һәм басма матбугатны чүп-чар басмасын өчен, даими тырышу, аларны үстерү кирәк. Камил тел һәм фикер йөртү булсын, милли үзаңыбыз алга китсен, дисәк, әлеге коралларны дөрес итеп куллана алырга тиешбез.

Артём Пискунов: Әдәбият милли йөзебезне, менталитетыбызны саклый алсын өчен, әсәрләре дә бик көчле булырга тиеш. Төрле язучылар бар бит, «сабын куыгы»

тудыручылар да җитәрлек. Язучылар булган мираска гына таянырга, бездә инде шулай урнашкан, дип язарга түгел, ә каршылыкларны кичеп, яңа офыкларга алып чыгарга омтылырга тиеш, дип саныйм. Бу сәнгатьнең бөтен өлкәләрендә дә шулай. Үз сүзен әйтә алган, урнашкан вазгыятькә, шартларга каршы торырга курыкмаган авторларның әсәрләре кызыклы миңа.

– Сез бөтенләй кабул итә алмаган авторлар, китаплар бармы?

Резедә Сәлахова: «Трусик-майка» темасына язучылар кызык түгел. Аның ише прозаны бөтенләй кабул итә алмыйм. Еш кына аудиокитапларны тавышландырырга чакырыла торган диктор буларак, «билдән түбән проза» тәкъдим итмәүләрен сорыйм. Тәкъдим итсәләр, баш тартам.

Артём Пискунов: Юк, нәрсәдер ошамый икән, үземне көчләп укымыйм.

– Кәгазь китапмы, электрон форматмы?

Резедә Сәлахова: Һичшиксез, кәгазь китап. Өч сәбәбе бар: 1) кәгазь китапны алып, тотып, иснәп карап була; 2) укылган битләр артып, укыласы битләр кимеп барганда, күңелгә рәхәтлек иңә; 3) электрон вариант күзләргә зыян сала.

Артём Пискунов: Һичшиксез, кәгазь китап.

– Хәзерге вакытта (бәлки, һәрвакыт) өстәл китабыгыз?

Резедә Сәлахова: Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары». Күңелле чакта укысаң да, җанга рәхәт, бик авыр, сагышлы чакта укысаң да, юаныч. Авыр чакта укысаң, әй Аллам, мин бит әле бик бәхетле, бу проблемалар проблемамыни дип, шөкер итәсең. Юмор белән сугарылган моментлары иң төшенкелеккә бирелгән чакта да елмайтып җибәрә.

Артём Пискунов: Муса Җәлилнең шигырьләр җыентыгы машина бардачогында ук йөри. Рәфыйк Юнысның интервьюларын укыйм хәзер, бик кызык. Аны да үзем белән йөртәм.

– «Китап ул – минем өчен...» – бу фразаны ничек тәмамлар идегез?

Резедә Сәлахова: ...белем, яңа мәгълүмат чыганагы.

Артём Пискунов: ...зур иҗат чыганагы. Идеяләр, фикерләр бирә, тормыш-яшәеш җәһәтеннән дә күп кенә сорауларга китаплардан җавап табам.



МИҢГӘР: МОГҖИЗАЛАР ИЛЕНДӘ

Фото: Лилиана Вәлитова

МИҢГӘР

Саба районының Миңгәр авылын белмәгән кеше юктыр. Сабан туен карарга дип, бөтен республика халкы җыела анда. Бүген исә Миңгәргә ял итәр, сәламәтләнү өчен дә киләләр. Республикадан гына түгел, Россиянең башка төбәкләреннән, чит илләрдән дә кунаклары биредә еш була.

Без дә Миңгәргә барырга уйладык. Ял итәр өчен, сәламәтләнү өчен түгел, максат авылның гади халкы белән аралашу иде. Мондый игътибарга алар сөенәме, әллә киресенчә, көенәме икән?

Руфия Фазылова

«БАЛА ҮЗ АВЫЛЫНДА УКЫРГА ТИЕШ!»

Миңгәр әллә ни зур авыл түгел: 114 хуҗалык бар, 209 кеше яши. Тимершык авылы җирлегенә керә ул. Биредә хәтта тыкрыкларга да асфальт юл салынган. Гомумән, бик төзек авыл. Миңгәрнең иң зур үзенчәлеге – биредә Сөембикә манарасы (!) бар. Әйе, әйе, нәкъ менә Казандагы тарихи бинаның күчермәсе ул! Аңа караганда да биегрәк тә әле. Казандагы Сөембикә манарасының биеклеге 58 метр булса, Миңгәрнеке – 66 метр! Ләкин бу хакта соңрак...

Авылда башлангыч мәктәп, музейлар (бер түгел, ә өч музей эшли), клуб, мәчет, ФАП бар, ә менә кибет юк. Шулай да атнага ике тапкыр автолавка килә икән. Һәм шул җитә, чөнки күпләр машинада йөри – кирәк-ярак әйберләрне ала кайталар. Миңгәр Сабага терәлеп диярлек тора: сигез генә чакрым. Әлбәттә, район үзәгенә якын авыллар бәхетлерәк: эш урыннарына кытлык булмый. Кагыйдә буларак, андый авылларда кеше саны кимеми, йортлар ябылмый. Миңгәр дә искәрмә түгел:

быел гына да дәүләт программасы ярдәмендә алты йорт салынган. Ул йортлар авылга эшкә килгән яшь белгечләргә бирелә икән.

Урынлы бер сорау туа: димәк, мәктәпкә ябылу куркынычы янамый? Тик... Миңгәр башлангыч мәктәбендә бары тугыз бала укый. Аннан соң балалар күрше Тимершык урта мәктәбенә бара. Биредә исә 163 укучы белем ала, диделәр.

– Урта мәктәптә укучы саны күп икән, – дидем Тимершык авыл җирлеге башлыгына.

– Әле тагын да күбрәк булыр иде, ата-аналар балаларын Сабага, Шәмәрдәнгә йөртә. Махсус санадым: 31 балабыз читкә барып белем ала. Инде авыл җыелышларында гел әйтәм: сез дә бит шушы мәктәпләрдә укыган кешеләр. Күбегез югары белемле, бер дигән яшисез. Ә балаларыгызны читкә йөртәсез. Сабада укыган балага Миңгәр дә, Тимершык та кирәкми, шуны уйлагыз дип, кат-кат аңлатам.

Миңгәр башлангыч мәктәбе белән танышып чыктык. Ремонттан соң эшләп киткән ул, үзе якты, бик иркен. Тугыз бала өчен монда чын хөррият! Классларны икегә кушып, ике укытучы укыта икән. Кызганыч, балалар белән танышып булмады, көзге каникул чорына туры килдек.

Миңгәр башлангыч мәктәбендә тугыз бала укый.



Сөембикә манарасының биеклеге 58 метр булса, Миңгәрнеке – 66 метр

– Миңгәр башлангыч мәктәбенең базасы бик нык, югары әзерлекле балалар килә, – диде Тимершык урта мәктәбе директоры Айдар Карамов. – Инглиз теле, физкультура дәресләрен Тимершык мәктәбеннән барып укыталар, чөнки алар безнең филиал булып тора. Кызганыч, Миңгәр мәктәбендә укучылар саны кимүгә бара. Мисал өчен, биш ел элек кенә дә монда унбишләп бала иде, хәзер тугызга калды. Миңгәрдә балалар бакчасы да ябылды. Югыйсә бер дигән бакча. Капиталь ремонтка туктагач, ата-аналар балаларны Тимершыкка илттеләр дә шуннан кире күчерергә теләмәделәр. Хәзер бит сайлау мөмкинлеге бар: телисең икән Сабага йөрт, телисең икән – башка җиргә. Безгә шулай җайлырак дип, ата-аналар балаларын үзләре белән район үзәгенә алып китә, чөнки шунда эшлиләр. Кайтканда ала кайталар. Казанда ата-аналар балаларын әллә кайларга йөртеп укыта бит, бездә дә шулайрак хәзер.

«ЗАКАЗГА ТОРТЛАР ПЕШЕРӘМ»

Тимершык авыл җирлеге башлыгы Айдар Хаҗиев белән бер матур йортка тукталдык. Биредә бик уңган гаилә яши, диде җирлек башлыгы. Хуҗабикә Роза Булатова елмаеп каршыга чыкты.

– Сез килә дип ашыгып эштән кайттым. Кичә махсус сезгә дип торт та пешереп куйдым.

– Ай, рәхмәт. Ә кайда эшлисез?

– Җәүдәт абый Миңнәхмәтовның эшчеләр өчен ашханәсе бар, шунда төп пешекче мин.

Ул да түгел, Роза апа суыткычыннан ясаган тортын чыгарды. Бик затлы: чын профессионалларча эшләнгән!

– Заказга да эшлисезме?

– Ә тортлар ясарга ничек өйрәндегез? Үзегезгә генә түгел, заказга да эшлисез бит, – дим.

– Дүрт ел элек оныкның туган көненә тортка заказ бирдек. Шуңа өч мең сум акча түләдек. Шуннан уйладым: «Соң, Роза, моны бит инде үзең дә пешерә аласың». Туган көннән кайткач, интернеттан карап беренче тортымны пешереп карадым. Башта бик әйбәт чыкмады. Бисквитны белеп кенә пешерергә кирәк: газ плитәсенең капкачын ачсаң, кабарганы төшеп китә, вакытын исәптә тотарга, мичнең җылылыгын карарга кирәк. Шуннан икенчесен пешереп карадым, өченчесен... Бер төшенгәч, авырлыгы юк. Танышлар күреп, заказ бирә башлады. Даими клиентларым бар. Соңыннан бик мактап, рәхмәт сүзләре язалар.

– Атнасына, ким дигәндә, ике-өч торт ясыйм, – дип сөйләде Роза Булатова.

– Әйе, эшлим. Атнасына, ким дигәндә, ике-өч торт ясыйм. Бәлешләр дә пешерәм. Акчасыннан бигрәк, кешегә «юк» дип әйтә алмыйм, шуның өчен заказлар алам. Икенче яктан, торт ясаган арада онытылып торам. Егерме сигез яшендә улыбыз үлеп китте. Шуннан бирле төнлә начар йоклыйм. И, соңгы елларда югалтулар күп булды... Оныгымны җирләдек, каенанам, абыем бакыйлыкка күчте. Ике ай элек кенә каенатам да үлеп китте. Шушы нигездә, зур бер гаилә булып, барыбыз бергә тату яши идек, бик сагынам шул чакларны.

Роза апа бүген җәмәгате Илдус абый белән яши. Өч ул үстергәннәр, аңлашылганча, берсе мәрхүм инде. Каенанасы белән – 22 ел, каенатасы белән аннан да күбрәк яшәгән. Сабыр, уңган ханым. Һөнәре буенча тегүче икән. Ләкин соңгы унбиш-уналты елда – пешекче вазыйфасында. Үзе әйтүенчә, һөнәрен бик ярата.

ШӘЛ БӘЙЛӘП САТТЫК

Авылның тагын бер уңган апасы белән таныштык: Нәкыя апа Шәрипова ялгызы яши икән. Күптән түгел 75 яшен тутырган. Тумышы белән Миңгәрнеке. Егерме яшендә кияүгә чыгып, утыз ел Чаллы шәһәрендә гомер иткән. Җәмәгате фаҗигале төстә вафат булгач, 2000 елны әнисе янына кайта. Шуннан бирле туган нигезендә яши..

– Әнине, карап, соңгы юлга озаттым, – диде Нәкыя апа. – Шөкер, әнинең васыятен үтәп яшим: туганнарны каршы алам, озатып

– Кул эшеннән башка тора алмыйм, җәен дә, кышын да бәйлим, – диде Нәкыя Шәрипова.

җибәрәм. 2006 елны барыбыз бергә җыелышып яңа йорт салдык. Җиде туган үстек, бүгенге көндә бишебез исән. Балалар да кайтып йөри, барысына да зур рәхмәт.

Нәкыя апа башлангыч мәктәпне Миңгәрдә тәмамлаган. Дүртенче сыйныфны унбер бала бетереп чыкканнар. Сигез классны Тимершык мәктәбендә укыган, шуннан инде колхозда сыер сава башлаган.

– Ул чакта бөтен кеше колхозда эшкә калды, – диде Нәкыя апа. – Безнең колхоз башка авыллар белән чагыштырганда үрнәк иде. Яхшы машиналар кайтты. Сарык, сыер фермалары гөрләп эшләде. Яшелчәләр дә үстерделәр, алма бакчаларына кадәр бар иде. 1965 елда колхозга СССРның Күчмә Кызыл байрагын тапшырдылар. Сугыштан соң әти үзе дә колхоз рәисе, авыл советы рәисе булып эшләде. Фин сугышы, Бөек Ватан сугышыннан исән-имин әйләнеп кайткан кеше иде ул.

Нәкыя апаның өендә борынгы тегү машинасы бар – әнисеннән калган ул. Әнисе гомер буе тегү теккән, колхоз эшчеләренә бияләйләр, телогрейкалар тегеп биргән.

– Бу тегү машинасына йөз генә ел түгел, – диде Нәкыя апа. – Хәзер аның белән мин тегәм. Безнең гаиләдә гомер буе кул эше булды: дүрт-биш яшемнән шәл бәйләргә өйрәндем. Сеңелләрем дә бик бәләкәй чагыннан кулына энә тотты. Хәер, без генә түгел, ул чагында Миңгәрдә хатын-кызлар шәл бәйләде, ир-атлар итек басты. Аны үзләре күрше районнарга алып барып сатты да. Безнең авыл начар яшәмәде.

Кәсепчелек Нәкыя апаның канына сеңгән. Ул бүген дә мунчалалар, йон башмаклар бәйләп сата. Үзе әйтүенчә, сорау бар икән.

– Мин кул эшеннән башка тора алмыйм, җөен дә, кышын да бәйлим, – диде Нәкыя апа. – Хәзер яшьләр бәйләү эшен онытып бара, ә менә без башкача тәрбияләнгән буын...

УН КЛАССТАШ БЕРГӘ ГАИЛӘ КОРГАН

Миңгәрнең яшь гаиләләре белән дә таныштык. Гөлинә һәм Риназ Закировлар 2018 елда Миңгәрдә йорт салып чыккан. Гаилә башлыгы – Миңгәр егете, Гөлинә исә – Тимершык кызы. Курчак кебек ике кыз үстерәләр. Риназ Сабада машина йөртүче булып эшли, Гөлинә исә Кызыл Мишәдә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар интернат-мәктәбендә хезмәт куя.

– Гаилә коргач та, Сабадан социаль ипотекага фатир алдык, – диде Риназ. – Әмма өч-дүрт ел яшәгәч, авылга күченик дигән карарга килдек. Бу нигездә иске генә өй иде, Сабадагы фатирны сатып, биредә йорт салдык. Әтиәниләр дә янәшәдә генә, бик җайлы.

Авылда яшьләр өчен күңелсез, дип зарлана яшь гаиләләр. Әмма Миңгәрдә мондый проблема юк. Әйткәнебезчә, авыл район үзәгенә бик якын. Аннан соң, Миңгәрдә ял итү урыннары бик күп. Тимершык җирлегендә яшь гаиләләр шактый, еш кына алар очрашып, бәйрәмнәр оештыралар икән.

Миңгәрдә яшәүче яшь гаиләләрнең берсе – Закировлар.

– Без Риназ белән бер сыйныфта укыдык, – диде Гөлинә Закирова. – Ләкин мәктәптә чакта дусларча гына аралаша идек. Мин Казанда укыганда гына Риназ игътибар күрсәтә башлады. Аннан соң гаилә кордык. Безнең сыйныф бик үзенчәлекле: ундүрт укучы идек, шуннан биш гаилә барлыкка килде. Хәзер сыйныфташлар очрашуына ирле-хатынлы йөрибез. Ә иң кызыгы – биш гаилә дә авылда калды. Бүген балаларыбыз бер сыйныфта укый, туганнар кебек яшибез.

Гөлинә, башка авылдашлары белән бергә, махсус хәрби операциядәге егетләр өчен сеткалар үрә, аш-су кирәк-яраклары әзерли. Йөзендә генә түгел, күңелендә дә бер яктылык, нур бар аның. Авылда мондый яшьләр булуы, әлбәттә, зур сөенеч!

МИҢГӘР – МАТУРЛЫККА ТАРТЫЛУ

Гадәттә авыллар турында язганда, урман-күлләр уратып алган, дибез. Миңгәргә ул аеруча туры килә: гектар-гектар урман, унсигез ясалма күл, илле чакрымлы җәяүлеләр юлы... Әйтерсең, берәр Европа илендә йөрисең!

Боларның барысын да шушы авыл егете, «Татарстанның газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәре үсеше» дәүләт учреждениесе генераль директоры Җәүдәт Миңнәхмәтов эшләткән. Биредә заманча спа-үзәк, затлы кунакханә дә бар. Гади халык шунда ял итәме, диярсез. Юк, итми, нигездә Миңгәргә Казаннан, башка

Миңгәр: әйтерсең, берәр Европа илендә йөрисең!



шәһәрләрдән киләләр. Ләкин гади халык барыбер сөенә – аларга эш урыннары булган.

– Хәзер бездә мәктәптә, башка дәүләт оешмаларында эшләргә кеше табу авыр. Ни өчен дигәндә, күбесе әнә шул атаклы ял үзәгендә эшләргә китә, чөнки анда хезмәт хаклары югары, – диде авыл җирлеге башлыгы.

...Миңгәрдәге Сөембикә манарасының иң югары катына күтәрелдек. Мондагы манзарадан күзләр камаша. 400 урынлы концерт залына кадәр төзелеп ята. Агач йортлар тезелеп киткән: ял итү базасы икән. Шунда ук мунча керергә, балык тотарга да була.

– Җәй көне әлеге йортларның берсе дә буш булмый, – диде безгә шушы комплекс буенча экскурсия ясаучы Фәйзрахман Камал. – Район-авыллардан да киләләр. Мондагы матурлык кайда тагын бар?

Фәйзрахман абый үзе дә гади генә кеше түгел: Санкт-Петербургта яшәп, эшләп кайткан рәссам. Тумышы белән Башкортстан якларыннан, бүгенге көндә Миңгәрдә төпләнгән. Үзенчәлекле, түгәрәк йорт салып ята. Тагын әле ул авыл музей-остаханәсен җитәкли.

– Ә Миңгәргә ничек килеп чыктыгыз? – дим.

– Җәүдәт Мидхәтович бер проектны эшләргә чакырган иде. Шуннан Миңгәргә гашыйк булдым. Әле бер хыялым бар – авылда балалар өчен сәнгать мәктәбе ачу. Бүген дә музей-остаханәдә балалар шөгыльләнә: балчыктан төрле савыт-саба, сыннар ясыйбыз, рәсем сәнгате серләрен аңлатам. Авылга кунакка килгән кешеләр дә музей-остаханәгә килә, – диде рәссам.

ШӘҮКӘТЛЕ АВЫЛ...

Әйткәнемчә, авылда өч музей бар. Алар Саба районы туристик маршрутына да кертелгән. Аңлашылганча, беренчесе – музей-остаханә. Икенчесе – Миңнәхмәтовлар нәселенең музей-йорты. Җәүдәт Мидхәтович тарих яратучы, нәсел-ыруына зур ихтирам белән карачы кеше буларак, туган йортын музей иткән. Музейның өченчесе – яраткан «Әлмәндәр»ебез, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровныкы. Ул, китапханә каршында эшли торган музей, дип атала, 2014 елда ачылган. Җылы, җанлы үзәк.

– Шәүкәт абый үзе исән вакытында туган авылына еш кайтып йөри иде, – диде Миңгәр китапханәсе мөдире Алия Мөбәрәкова. – Шәүкәт абыйның нигезе – күрше урамда, бүген анда кызы Гүзәл апа җәмәгате белән яши. Музейга күп экспонатларны Гүзәлападан алдык. Шәүкәт абыйның шәхси әйберләре, сәхнә киемнәре – барысы да бездә саклана. Хәтта Биктимеровлар нәселенә караган предметлар да бар. Шәүкәт абый атаклы нәселдән була, бабасы – Сатыш мәдрәсәсен тәмамлаган мулла. Миңгәргә аны халыкка дини белем бирү өчен җибәрәләр. Шәүкәт абый өч яшеннән әнисез калган бала. Ләкин әтисе Хәсән, әбибабасы аңа ныклы тәрбия, белем бирә.

...Менә шулай яшәп яталар Миңгәрдә. Үз бәясен белгән, зыялы халык яши биредә. Юлсызлык, эшсезлек проблемалары алар өчен ят. Һәм алар моны шулай тиеш дип саный кебек, чөнки авыл гомергә начар яшәмәгән. Әйткәнемчә, шәл бәйләп, итек басып сатканнар. Бүген дә алар заманнан калышмыйча, горур гына көн итәләр, чөнки бу инде канга сеңгән... Т

Фәйзрахман Камал гади генә кеше түгел: Санкт-Петербургта яшәп, эшләп кайткан рәссам.

– Шәүкәт абый үзе исән вакытында туган авылына еш кайтып йөри иде, – ди Алия Мөбәрәкова.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– «Миңгәр» атамасының килеп чыгышына бәйле төрле фикерләр бар. Галим Марсель Әхмәтҗанов аны борынгы төрки «меңнәр» яисә «мең ир» кабиләсенә нисбәтле. Икенче галим Гомәр Саттаров, Мәхмүт Кашгарыйның XI гасырлы борынгы төрки сүзлегенә таянып, «чыганак, чишмә» мәгънәсенә ия төшенчә буларак аңлата.
Миңгәр авылының тарихы XVI гасырларга барып тоташа.

2017 елда Миңгәр турында басылган китаптан

«NOMAD: BLACK & WHITE»* (0+)

Казахстанның бүгенге популяр рәссам-графигы Батухан Байменның эшләре киң колачлы булуы һәм гаҗәеп экспрессиясе белән җәлеп итә. Заман сәнгатендәге алдынгы, яңа тенденцияләр тарафдары буларак, ул, асылда, борынгы бабаларының әле күчмә тормыш белән яшәгән дәверләре мәдәниятеннән илһам ала. «Хәзинә»дә ачылган күргәзмәдә рәссамның хәзерге чор иҗатына кагылышлы эшләре урын алган. Биредә сез зур форматтагы әсәрләр белән таныша алачаксыз, алар графика сәнгате өчен бик үк стандарт булмаган материалга – тукымага ясалган. Көнчыгыш фәлсәфәсе белән сугарылган шәхси уйланулары белән дә уртаклаша алар аша рәссам.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (пәнҗешәмбе – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне. ТР ДССМ ның «Хәзинә» милли сәнгать галереясы, Казан Кремле, 1, 80 нче корпус

* «Күчмә тормыш: ак белән кара»

афиша

ОНЫТЫЛЫР, ДИМӘ! (6+)

Татар дәүләт филармониясендә яңа ел Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Хәния Фәрхине искә алу концерты белән башланып китә. Яраткан артистыбызга багышланган кичәдә аның репертуарына кергән «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә», «Онытылыр, димә!», «Кышкы чия», «Дусларга», «Авыл киче», «Карлыгач кара була» һәм башка популяр җырлары яңгыраячак. Аларны халыкара конкурслар лауреаты Алинә Кәримова башкара. Кичәдә яңартылган «Бәйрәм» ансамбле дә чыгыш ясаячак.

2026 елның 2 гыйнвары, 18:00
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

ЧУЛПАН ИСЕМЛЕ ЙОЛДЫЗ (12+)

Хыяллар канат куя, диләр. Яшь төзүче Хәйдәр авылдан Казанга килә, ул хыялдагы йолдызына таба очарга да әзер, кечкенәдән галәмгә очарга омтыла торган булган. Әмма бервакыт шәһәр ыгы-зыгысы уртасында ул Мәскәү рәссамы Чулпанны очрата. Шул мизгелдә аның күккә ашкан хыяллары җирдәге мәхәббәткә әверелә. «Хыял артыннан» – дуслык, ихлас хисләр һәм хыялның тормышны хәрәкәткә китерә торган көчкә әйләнүе турындагы музыкаль спектакль. Сәхнәдә 60 нчы еллар атмосферасы җанлана: дәртле биюләр, җырлар, юмор һәм дулкынландыргыч драматик мизгелләр.

28 ноябрь, 18:30, Зур зал. К. Тинчурин исем.
Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Татарстан ур., 1

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, tatfil.ru

КНЯЗЬ ЙОСЫПОВЛАР МИРАСЫ (0+)

XVIII–XIX гасырлардагы рус аксөякләре атмосферасына күмелер өчен, Россиядәге иң кыйммәтле һәм затлы коллекцияләрнең берсен күрергә киңәш итәбез. Ул князь Йосыповлар династиясенеке. Йосыповлар нәселе Сөембикә ханбикәнең этисе, нугай йорты хакиме Йосыф морзага барып тоташа, аларда татар тамырлары бар. Идел буе Болгарстаны белән Казан ханлыгы варисы булган тарихи Казан гасырлар буена Көнбатыш белән Көнчыгышны тоташтыручы үзәк була. Шуңа да бу күргәзмәнең мәгънәсе тагын да тирәнәя төшә.

Экспозициядә Көнбатыш Европа һәм рус сынлы сәнгате, графикасы тәкъдим ителгән. Биредә сез шулай ук өч буын княгиня Йосыповаларның гардероб элементларын күрә аласыз, алар – Петербург һәм Европа мода йортлары, тегүче осталарының иң югары дәрәҗәдәге махирлыгын, ә аксөяк ханымнарның искиткеч зәвыген раслап тора.

Көн саен: 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне. «Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат;
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы»

МИЛЛИ МОҢНАР (6+)

Матур костюмнар, дәртле биюләр, күңелгә үтеп керә торган халык көйләре... Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге ТР Фольклор музыкасы ансамбле тарафыннан әзерләнгән яңа концерт программасы берәүне дә битараф калдырмый. Ансамбль үзе музыка өлкәсендәге уникаль күренеш булып тора – коллективның барлык әгъзалары профессиональ дәрәҗәдә җырлый, бии, берничә уен коралында уйный. Аларның кулларында гармун, курай, кубыз һәм гөслә, саз, думбра, ятаган, җәя кебек борынгы уен кораллары да гаҗәеп моңлы яңгырый. Бик тәфсилләп тупланган һәм җентекләп өйрәнелгән фольклорны, татар халкының бай музыкаль мирасын ансамбль тамашачыларга мавыктыргыч тамаша рәвешендә тәкъдим итә. Концерт «Филармониада» XVIII Халыкара сәнгать фестивале кысаларында оештырыла.

6 декабрь, 18:00
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

МӘҢГЕЛЕК СУЛЫШЫ (0+)

Аның сәнгате тын, дикъкать таләп итә, әмма нәкъ менә шушы тынлыкта мәңгелек сулышы ишетелә дә инде. Тәнкыйтьчеләр Юрий Купер иҗатын шулай бәяли, ә аның эшләрен дөньяның иң эре музейларында күрергә була. Рәссамның эшләре куелган «СФУМАТО» күргәзмәсенең аталышы безне Яңарыш чорына алып кайта, ә димәк ки – буяуларның йомшак кына, бер җайга яткан күчешенә, формаларның, әйтерсең, һавада эреп үтәкүренмәле булып эверелешенә. Сфумато алымын үз дәверендә мастерларча бөек рәссамнар кулланган – Леонардо да Винчи, Корреджо. Алар үз әсәрләрендә моңарчы булмаган тирәнлек белән серлелекне чагылдыра алган. Купер өчен бу техника булудан бигрәк, метафора, билгеле: вакыт турында уйланырга чакыру, яшәешнең бик нәзберек икәнлегенә ишарә итү.

Рәссамның иҗат биографиясе Париж, Лондон, Нью-Йорк, Токио, Флоренция, Мәскәү һәм Санкт-Петербургта узган 150 дән артык шәхси күргәзмәне үз эченә ала. Аларның һәрберсе төрле илләрдәге мәдәни тормышның әһәмиятле вакыйгасы булып эверелгән.

Көн саен: 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне.
Кабул итү урыннары Күргәзмә заллары; «Казан Кремле» музей-тыюлыгы



МУХШЫ ОЛЫСЫ СЕРЛӘРЕ (0+)

XIV гасырдагы Алтын Урда шәһәренә «барып кайтасыгыз», анда яшәүчеләрнең көнкүреше һәм үзенчәлекле архитектурасы белән танышасыгыз, сәүдә элемтәләре һәм акча сугу эшчәнлеге турында беләсегез килсә, «Мухшы Олысы. Алтын Урда патшалыгының олыс шәһәре данлыклы булган...» күргәзмәсенә барыгыз. Күргәзмәдәге раритетлар алты гасыр элек булган чорга карый. Алар борынгы Наровчат (Наручат) шәһәре урнашкан урында табылган, элек бу шәһәр «Мохши, яки Нуриҗан» исеме белән дә билгеле булган. Бүген ул – археологик мирасның уникаль объекты, федераль дәрәҗәдәге тарих һәм мәдәният ядкәре.

Көн саен: 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне. Татарстан Республикасы
һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее,
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Башкалабыз Казанда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл затлары белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.



«ОҖМАХНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕ»: ПЕЧНИКОВЛАР ЙОРТЫ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Ульянов-Ленин урамының иң азагында урнашкан агач йорт – Казанда инде бик сирәк сакланып калган ядкәрләрнең берсе. Дөресен генә әйткәндә, аңа зур игътибарны «Том Сойер Фест» җәлеп итте. Чөнки ул нәкъ менә шушы йорт ишегалдыннан башланып китте. Йортның тагын бер гаҗәеп кадерле дә, сөенечле дә үзенчәлеге – илдә нинди генә вазгыять булмасын, менә инде дүрт буын дәвамында дворян Печниковлар нәселе биредә үз нигезендә яши. Аларның йөрәге йорт йөрәге һәм гасыр пульсы белән бербөтен.

Фото: Александр Ефремов

Шуңа да биредә җанлы тарих пыяла артына яшерелмәгән, табличкаларга язып беркетелмәгән. Гаилә альбомнарындагы сурәтләр дә сакланып калган, аларны йорт хуҗалары хәзер дә актарып карый, барлый һәм хәтерендә саклый.

Йортның фасады матур нәкышле, ишеге тимердән эшләнгән энә карагы фигуралары белән бизәлгән. «Том Сойер Фест» фестивале кысаларында беренчеләрдән булып аның фасад өлеше яңартылды.

КОБЕЛЬКОВЛАР ҺӘМ ПЕЧНИКОВЛАР

Йорт 1880 елда төзелә. Аны алпавыт Колантаевадан 1912 елда 14 мең сумга заманында Казанда бик тә билгеле булган врач-венеролог Николай Печников сатып ала. Табиб Казандагы гаять абруйлы кеше – Казан округы судының гражданнар бүлеге башлыгы, статский советник Георгий Кобельковның кызына өйләнә. Киң күңелле, кунакчыл яңа хуҗа, хатынының сеңелләрен, туган-тумачасын да үз канаты астына алып, гомер буе аларны кайгыртып яши.

Кобельковлар нәселеннән булган Екатерина Николаевна – бу йорт тарихы белән генә түгел, ә Казанның, Россиянең мәдәни барышы белән дә бәйле шәхес. Ул – үз чорының күренекле опера җырчысы, ТАССРның атказанган артисты. Заманында Мәскәү, Санкт-Петербург театрларында чыгыш ясаган, Федор Шаляпин белән бергә сәхнә тоткан Екатерина Ковелькова буларак беләбез без аны. Танылып киткәч, афиша-буклетларда язылышы, игълан иткәндә яңгырашы матуррак булсын өчен, «Кобелькова» фамилиясен «Ковелькова» дип үзгәртә.



ЯШЕРЕН «СЕРЛӘР»

Бүгенге көндә йортның хуҗасы – юрист, Социаль һәм гуманитар белемнәр институты профессоры, РФ югары белем бирү буенча почетлы хезмәткәре Вадим Николаевич Печников.

20 нче елларда йортны Печниковлардан тартып алырга тырышып караганнар, әмма тимәскә карар кылганнар. Монда Николай Печниковның абруе һәм НКВД җитәкчелеген дә дәвалавы, күп кенә түрәләрнең «серләрен» белүе зур роль уйнаган, диләр. Казан венерологы аларны яшерен генә үз өендә дә кабул итә торган булган. 1944 елда атаклы табиб, каты авырып, ачлы-туклы калып дөнья куя. Печниковның балалары да – табиблар, икенче кызы Вера Николаевна Бөек Ватан сугышын башыннан азагына кадәр уза.

Сугыш елларында йортта эвакуацияләнгән РСФСРның сәламәтлек саклау наркомы ярдәмчесе Кузнецов, аның кызы Люда яши. Чарлакта – шулай ук эвакуацияләнгән фән эшлеклеләре, физиклар.

ВАРИСЛАРГА – ЯДКӘР

Вадим Николевич табиблар династиясе чылбырын дәвам итмичә, башка һөнәр сайлаган. Дөресрәге, карт бабасы эзләре буенча киткән, шулай булгач, нәсел традицияләренә барыбер дә тугры калган. Ул – сәнгатькә гашыйк зат, саксофонда уйный, берара музыкаль грампластинкалар яздыру белән мавыккан. 1959 елда ТАССРдагы музыкаль фестивальдә лауреат исеме дә яулаган. Гомумән, гаиләдә музыкаль традицияләр буыннан-буынга күчеп саклана.

Дөньялар имин торса, йорт үзе дә әле яңа варисларга күчәчәк, дип өметләник. Вадим Николаевич моны зур горурлык дип саный. Ә нигезләре турында болай ди: «Бакчага чыгам да, Ходаем, син безгә оҗмахның бер өлешен биргәнсең бит, мең рәхмәт!»

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Рәссам Л. Гамбургер эше. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru

t.me/pro_tatarstan

vk.com/protatarstann

Реклама 16+

ТАТАРСТАН

журналын кайдан сатып алырга:

ВЕНДИНГ АППАРАТЛАРЫНДА

«Мегастрой»
Гаврилов ур., 5
тәүлек буе

Казан-2 тимер юл вокзалы,
көтү залы.
Воровский ур., 33
тәүлек буе

«Тукай мәйданы» метро станциясе
6:00 дән 00:00 гә кадәр

Аэропорт терминал 1
тәүлек буе

«Дубравная» метро станциясе
(Зорге урамына чыгу)
6:00 дән 00:00 гә кадәр

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

РЕКЛАМА. 16+